ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем.
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ЛИНГВИСТИК ТЕРМИННАРНЫҢ
# РУСЧА-ТАТАРЧА
# АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ

Якынча 2250 сүз

КАЗАН • 2016

АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
им. Г. ИБРАГИМОВА

# РУССКО-ТАТАРСКИЙ ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ ЛИНГВИСТИЧЕСКИХ ТЕРМИНОВ

Около 2250 слов

КАЗАНЬ • 2016

**УДК 81′374.822**
**ББК 81.2Тат-4**
**Р 88**

*Печатается решением Ученого совета*
*Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

Издается в рамках Государственной программы РТ
«Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014 – 2020 годы»

Составители:
канд. филол. наук О.Н. Галимова,
канд. филол. наук И.И. Сабитова, Р.Р. Абдуллина,
канд. филол. наук Ф.Ф. Гаффарова, канд. филол. наук Ф.И. Тагирова,
канд. филол. наук Ф.К. Сагдеева

Научные редакторы:
канд. филол. наук **Ф.И. Тагирова,**
канд. филол. наук **Ф.Ф. Гаффарова**

Рецензенты:
доктор филологических наук, профессор **Ф.М. Хисамова,**
доктор филологических наук, профессор **А.Г. Шайхуллов**

**Р 88** Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов / под ред. Ф.И. Тагировой и Ф.Ф. Гаффаровой. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – 248 с.
ISBN 978-5-93091-204-3

Словарь разработан в качестве справочного пособия для преподавателей, студентов филологических вузов, особенно отделений татарской филологии. Он также может быть полезен учёным-языковедам. Основу словаря составляют термины, отобранные из специальных словарей и грамматик. Цель составителей заключалась в сборе и систематизации имеющейся и разработке новой лингвистической терминологии на татарском языке и их объяснение в виде кратких толкований для облегчения усвоения материала.

Словарь содержит около 2250 лингвистических терминов и аналитических названий.

**ISBN 978-5-93091-204-3**

© ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2016

## ПРЕДИСЛОВИЕ

Лингвистика, как и всякая другая наука, находится в состоянии непрерывного развития. Постоянно расширяется круг исследований, вследствие чего появляются новые направления и целые отрасли науки. Терминологический аппарат непрерывно пополняется новыми понятиями. Для полноценного развития того или иного направления науки новая терминология должна осваиваться не только в теоретическом плане, но и в плане лексикографическом. Наличие терминологического словаря свидетельствует об общем уровне развития данной отрасли. Татарская лингвистика за последние десятилетия также значительно продвинулась вперёд, соответственно обогатив свою терминологию, которая требует целенаправленной фиксации, систематизации и лексикографической обработки. До настоящего времени татарский язык не имел словаря, сколь-нибудь полно отражающего лингвистическую терминологию татарского языка. Между тем, как учёные-языковеды, так и преподаватели и студенты языковых специальностей постоянно испытывает насущную потребность в более полном, объёмном справочном издании. Изданные до настоящего времени лингвистические словари, хотя и изменили ситуацию в лучшую сторону, из-за ограниченности объёма и тиража, не смогли полностью удовлетворить потребность в такой публикации. Предлагаемый «Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов» в значительной мере соответствует требованиям современной лексикографии.

Структура Словаря довольно проста и удобна для пользователя. Принцип подачи материала – алфавитный. Для удобства поиска словарь снабжен алфавитным указателем, таким образом, можно одинаково быстро найти как русский, так и татарский варианты термина. За исходный берётся русский язык. Татарская часть содержит соответствия слова на татарском языке в виде его перевода, кальки или нескольких вариантов. Далее идут толкования, которые также даны на татарском языке, абсолютно ко всем заглавным словам. Наличие и толкований, и переводов терминов, делает Словарь предельно насыщенным специальной информацией, что выгодно отличает его от других подобных изданий. В алфавитный указатель включены только термины, соответствующие вокабулам, хотя в Словаре термины представлены также внутри толкований.

При составлении словника Словаря авторы стремились наиболее широко и полно отразить существующую терминологию, и традиционно устоявшуюся на данный момент, и новую, и устаревшую.

Над составлением словаря работал следующий коллектив авторов: О.Н. Галимова (буквы А, Й, О, Т, Ф, Щ), И.И. Сабитова (буквы Б, С, У, Ч, Я), Р.Р. Абдуллина (буквы В, Г, Е, И, Р, Э), Ф.Ф. Гаффарова (буквы Д, З, Л, М, Н, Х), Ф.И. Тагирова (буквы К, П, Ц, Ш, Ю), Ф.К. Сагдеева (Ж).

# СПИСОК ИСПОЛЬЗОВАННОЙ ЛИТЕРАТУРЫ


Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. – М.: Сов. энциклопедия, 1966. – 607 с.

Вендина Т.И. Введение в языкознание: учеб. пособие для педагогических вузов. – М.: Высш. шк., 2001. – 288 с.

Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен д-лек. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.

Исаев М.И. Словарь этнолингвистических понятий и терминов. – М.: Флинта: Наука, 2003. – 200 с.

Культура русской речи: Энциклопедический словарь-справочник / под ред. Л.Ю. Иванова, А.Г. Сковородникова, Е.Н. Ширяева [и др.]. – М.: Флинта, Наука, 2003. – 840 с.

Лингвистический энциклопедический словарь / гл. ред. В.Н. Ярцева. – М.: Сов. энциклопедия, 1990 – 685 с.

Матвеева Т.В. Учебный словарь, русский язык, культура речи, стилистика, риторика. – М.: Флинта: Наука, 2003. – 432 с.

Нелюбин Л.Л. Толковый переводоведческий словарь. – М.: Флинта, Наука, 2003. – 318 с.

Розенталь Д.Э., Теленкова М.А. Словарь-справочник лингвистических терминов: пособие для учителей. – 2-е изд-е, испр. и доп. – М.: Просвещение, 1976. – 543 с.

Русский язык. Энциклопедия / гл. ред. Ф.Г. Филин. – М.: Сов. энциклопедия, 1979. – 431 с.

Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча тел белеме терминнары сүзлеге. – Казан: Хәтер. 1998. – 127 б.

Сәлимов Х.Х. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 143 б.

Современный русский язык: учеб. для студентов вузов, обучающихся по спец. «Филология» / П.А. Лекант, Е.И. Диброва, Л.Л. Касаткин [и др.]; под ред. П.А. Леканта. – 4-е изд., стереотип. – М.: Дрофа, 2007. – 557 с.

Татар теле грамматикасы: 3 томда. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 1998. – Т. 1. – 510 б.; 2002. – Т. 2. – 447 б.; 1999. Т. 3. – 512 б.

Тел белеме буенча терминнар һәм әйтелмәләр сүзлеге / төз. Ш. Рамазанов, Р. Шакирова, Л. Җәләй; ред. Р. Шакирова. – Казан: Татгосиздат, 1953. – 76 б.

Учебный словарь. Русский язык, культура речи, стилистика, риторика. – М.: Флинта, Наука, 2003. – 431 с.

Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен д-лек. – Казан: Мәгариф, 2006. – 334 б.

Языкознание: большой энциклопедический словарь / гл. ред. В.Н. Ярцева. – 2-е изд. – М.: Большая Российская энциклопедия, 1998. – 685 с.

## РУССКИЙ АЛФАВИТ

| | | | |
|---|---|---|---|
| Аа | Зз | Пп | Чч |
| Бб | Ии | Рр | Шш |
| Вв | Йй | Сс | Щщ |
| Гг | Кк | Тт | ъ |
| Дд | Лл | Уу | Ыы |
| Ее | Мм | Фф | ь |
| Ёё | Нн | Хх | Ээ |
| Жж | Оо | Цц | Юю |
| Яя | | | |

## ТАТАРСКИЙ АЛФАВИТ

| | | | |
|---|---|---|---|
| Аа | Зз | Пп | Чч |
| Әә | Ии | Рр | Шш |
| Бб | Йй | Сс | Щщ |
| Вв | Кк | Тт | ъ |
| Гг | Лл | Уу | Ыы |
| Дд | Мм | Үү | ь |
| Ее | Нн | Фф | Ээ |
| Ёё | ң | Хх | Юю |
| Жж | Оо | Һһ | Яя |
| Җҗ | Өө | Цц | |

# А

**АББРЕВИАТУРА** АББРЕВИАТУРА, КЫСКАРТЫЛМА СҮЗ 1) Сүзтезмә составындагы сүзләрнең баш хәрефләре атамаларын яки беренче авазларын кушып ясалган сүз (мәс., *БМО – БыМыО, АКШ*, *ЮХИДИ*); 2) Сүзтезмәләрнең яки тезмә сүзләрнең беренче иҗекләрен кушып яки беренче компонентларын кыскартып, икенчесен тулысынча алып ясалган сүз (*татфак, драмтүгәрәк*)

**АББРЕВИАЦИЯ** АББРЕВИАЦИЯ Кыскартылма сүзләр ясалышы

**АБЕССИВ** АБЕССИВ Килешнең берәр нәрсәнең юклыгын, нәрсәдәндер читтә булуын белдергән категориаль формасы

**АБЗАЦ** АБЗАЦ Язма сөйләмнең бер кызыл юлдан икенчесенә кадәрге өлеше

**АБЛАТИВ** АБЛАТИВ Кайбер телләрдә чыгыш, ераклашу һәм юкка чыгу мәгънәләрен белдергән категориаль килеш формасы. Рус телендә *из, от* предлоглы родительный һәм творительный килешләргә туры килә

**АБЛАУТ** АБЛАУТ Эчке флексия ролен үти торган морфонологик чиратлашу (мәс., *посылать – послать – посол*)

**АБСОЛЮТНОЕ ВРЕМЯ** АБСОЛЮТ ВАКЫТ Фигыльнең җөмләдәге башка вакыт формаларына бәйләнмичә, сөйләү моменты белән билгеләнә торган вакыт формасы

**АБОЛЮТНОЕ ОПРЕДЕЛЕНИЕ** АБСОЛЮТ АЕРГЫЧ Баш килештәге исемнең постпозитив позициядә аергыч функциясендә кулланылышы

**АБСОЛЮТНЫЕ СИНОНИМЫ** АБСОЛЮТ СИНОНИМНАР Мәгънәсе тулысынча тәңгәл килгән, сөйләмдә бер-берсен алыштыра алган синонимнар

**АБСОЛЮТНЫЕ ПРОКЛИТИКА И ЭНКЛИТИКА** АБСОЛЮТ ПРОКЛИТИКА ҺӘМ ЭНКЛИТИКА Басымсыз сүзнең, басымлы сүз белән килгәндә, аның белән фонетик яктан бербөтен сүз булып китүе (мәс., *до са́да* [*доса́да*])

**АБСОРБЦИЯ** АБСОРБЦИЯ 1) Сонант белән янәшә килгәндә сузык авазның төшеп калуы; 2) Иҗекнең төшеп калуы; 3) Интервокаль позициядә йомык тартыкларның төшеп калуы

**АБСТРАКТНАЯ ЛЕКСИКА** АБСТРАКТ ЛЕКСИКА Сүзнең предметтан тыш мәгънәсен белдерә торган сүзләр; фикерләү аша гына аңлашылган төшенчәләрне, предметлаштырылган билгеләрне, эш-хәлләрне атаган сүзләр (мәс., *матурлык, яңалык*)

**АБСТРАКТНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** АБСТРАКТ ҖӨМЛӘ Гомуми фикер яки вакытка мөнәсәбәте булмаган раслауны белдергән җөмлә

**АВСТРОАЗИАТСКАЯ СЕМЬЯ ЯЗЫКОВ** АВСТРОАЗИЯ ТЕЛЛӘРЕ СЕМЬЯЛЫГЫ Күп кенә диалектлары булган телләрнең сигез төркемен берләштергән семьялык

**АВСТРОНЕЗИЙСКАЯ СЕМЬЯ ЯЗЫКОВ** АВСТРОНЕЗИЯ ТЕЛЛӘРЕ СЕМЬЯЛЫГЫ Һинд һәм Тын океан регионнарында таралган телләрнең дүрт төркемен (индонезия, полинезия, меланезия, микронезия) берләштергән семьялык

**АВТОЛОГИЯ** АВТОЛОГИЯ Күчерелмә мәгънәле сүзләр кулланылмаган сөйләм

**АВТОМАТИЗИРОВАННЫЙ ЭЛЕМЕНТ** АВТОМАТЛАШТЫРЫЛГАН ЭЛЕМЕНТ *к.* **фразеологизм**

**АВТОМАТИЧЕСКИЙ ПЕРЕВОД** АВТОМАТИК ТӘРҖЕМӘ Бер телдә язылган текстны икенче телгә эчтәлеге белән эквивалент булырлык итеп ЭВМда күчерү; шул күчерү нәтиҗәсе

**АВТОНОМНЫЕ СЛОВА** АВТОНОМ СҮЗЛӘР *к.* **знаменательные слова**

**АВТОРСКАЯ ПУНКТУАЦИЯ** АВТОР ПУНКТУАЦИЯСЕ Пунктуацион кагыйдәләр буенча куелмаган, автор билгеле бер мәгънә салган тыныш билгеләре

**АВТОРСКАЯ РЕЧЬ** АВТОР СӨЙЛӘМЕ Әдәби әсәрдә авторның хикәяләве ягъни әсәрнең персонажлар сөйләменнән тыш өлеше

**АВТОРСКИЕ СЛОВА** АВТОР СҮЗЛӘРЕ Туры сөйләмне кертә торган сүз яки җөмләләр

**АВТОСЕМАНТИЧЕСКИЙ** АВТОСЕМАНТИК Мөстәкыйль мәгънәсе булган

**АГГЛЮТИНАЦИЯ** АГГЛЮТИНАЦИЯ Тамырга яки нигезгә аффиксларның бер-бер артлы ялганып килүе

**АГГЛЮТИНИРУЮЩИЕ (АГГЛЮТИНАТИВНЫЕ) ЯЗЫКИ** АГГЛЮТИНАТИВ ТЕЛЛӘР Тамыры гаять тотрыклы, сүзләр агглютинация юлы белән ясала һәм төрләнә торган телләр (мәс., төрки телләр, фин-угыр телләре)

**АГЕНС** АГЕНС Һинд-европа телләрендә актив конструкцияләрдә баш килеш, пассив конструкцияләрдә кыек килеш формалары белән белдерелә торган эш-хәрәкәт чыганагы, ягъни субъект

**АГЕНТИВНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** АГЕНТИВ МӘГЪНӘ Эшне башкаручыны белдерә торган мәгънә

**АГОГИКА РЕЧИ** СӨЙЛӘМ АГОГИКАСЫ Әйтелгән, укылганнарның эмоциональ, интеллектуаль эчтәлеген игътибар үзәгенә алган сөйләм темпы, ягъни ритмик төзелеше турындагы өйрәтмә

**АДВЕРБИАЛИЗАЦИЯ** АДВЕРБИАЛИЗАЦИЯ, РӘВЕШЛӘШҮ Башка сүз төркемнәренә караган сүзләрнең рәвешкә күчүе

**АДВЕРСАТИВНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** АДВЕРСАТИВ МӘГЪНӘ, КАРШЫ КУЮ МӘГЪНӘСЕ Адверсатив сүзләр белән белдерелгән синтаксик мәгънә

**АДЕССИВ** АДЕССИВ Корал, урын, тартым (принадлежность) мәгънәләрен белдерә торган категориаль килеш формасы

**АДИТИВ** АДИТИВ Баск телендә хәрәкәтнең юнәлешен белдерә торган категориаль килеш формасы

**АДМЕРАТИВ** АДМЕРАТИВ Албан телендә көтелмәгән хәлгә ис китүне аңлата торган наклонение төре (фигыль төркемчәсе)

**АДСТРАТ** АДСТРАТ 1) Күрше тел буларак сакланып калган, аборигеннар теленә йогынты ясаган, милли азчылыкны тәшкил иткән күчеп килүчеләр теле; 2) Бер территориядә озак еллар дәвамында берничә тел яшәп килү белән бәйле икетеллелек

**АДРЕСАТ РЕЧИ** СӨЙЛӘМ АДРЕСАТЫ Сөйләм юнәлтелгән зат

**АДЪЕКТИВ** АДЪЕКТИВ *к.* **прилагательное**

**АДЪЕКТИВАЦИЯ** АДЪЕКТИВЛАШУ, СЫЙФАТЛАШУ Башка сүз төркемнәренә караган сүзләрнең сыйфатка күчүе

**АЗБУКА** ӘЛИФБА *к.* **алфавит**

**АКАНЬЕ** АЛАШТЫРУ Басымлы иҗектәге [*о*] авазына басымсыз иҗектә [*а*] авазы туры килү (рус әдәби теле һәм көньяк рус сөйләшләренә, белорус теленә хас)

**АККОМОДАЦИЯ** АККОМОДАЦИЯ Сузык һәм тартык авазларның бер-берсенә җайлашуы (мәс., *дау* сүзендә [*д*] авазының [*у*] га җайлашып каты, *дәү* сүзендә [*д*] авазының [*ү*] гә җайлашып нечкә әйтелеше)

**АККУЗАТИВ** АККУЗАТИВ *к.* **винительный падеж**

**АККУМУЛЯТИВНАЯ ФУНКЦИЯ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ АККУМУЛЯТИВ ФУНКЦИЯСЕ Телнең белемнәрне туплау һәм аларны чагылдыру функциясе

**АКРОНИМ** АКРОНИМ *к.* **аббревиатура** (*1 мәгъ.*)

**АКСИОНАЛ** АКСИОНАЛ Аспектуаль фигыль семантемасы

**АКСИОНАЛЬНАЯ КОММУНИКАЦИЯ** АКСИОНАЛЬ КОММУНИКАЦИЯ Адресаты һәм адресанты төгәл билгеләнгән аралашу процессы

**АКТАНТЫ** АКТАНТЛАР Фигыль белән бәйләнешкә кергән сүзләр

**АКТИВНАЯ ЛЕКСИКА** АКТИВ ЛЕКСИКА Көндәлек тормышта, сөйләмдә еш кулланыла торган, искергәнлек билгеләре дә, яңалык төсмере дә булмаган сүзләр

**АКТИВНЫЕ ОРГАНЫ** АКТИВ ОРГАННАР Артикуляция процессында хәрәкәтләнә торган органнар (мәс., тел, йомшак аңкау, иреннәр)

**АКТИВНЫЙ СЛОВАРЬ** АКТИВ СҮЗЛЕК 1) Шушы тел өчен мөһим төшенчәләрне белдергән һәм еш кулланыла торган сүзләр җыелмасы; 2) Психолингвистикада: сөйләүче тарафыннан спонтан сөйләмдә тоткарлыксыз кулланыла торган лексик берәмлекләр; 3) Лексикография теориясендә: сүзләрне сайлап алу һәм идиоматик куллануны җиңеләйтә торган лексикографик ярдәмлек (Л.В. Щерба)

**АКТУАЛИЗАЦИЯ** АКТУАЛЬЛӘШҮ Тел элементлары сөйләмдә реализацияләнү, заман, вакыт таләпләренә яраклашу

**АКТУАЛЬНОЕ ЧЛЕНЕНИЕ** АКТУАЛЬ КИСӘКЛӘРГӘ БҮЛЕНЕШ Җөмләнең конкрет эчтәлеген анализлаудан чыгып мәгънәви бүленеше; *к.* **тема, рема**

**АКТУАЛЬНЫЕ ЧЛЕНЫ** АКТУАЛЬ КИСӘКЛӘР Сөйләм предметын һәм сөйләм яңалыгын белдергән сүзләр

**АКТУМ** АКТУМ Кайбер Һинд-европа телләрендә объектны белдергән килеш төре

**АКУСТИЧЕСКАЯ АССИМИЛЯЦИЯ** АКУСТИК АССИМИЛЯЦИЯ Тартыкларның әйтелештә яңгыраулык-саңгыраулыкта охшашлануы (мәс., *тозсыз* – [*тŏссŏс*])

**АКУСТИЧЕСКАЯ ФОНЕТИКА** АКУСТИК ФОНЕТИКА Фонетиканың авазларны акустик яктан өйрәнә торган тармагы

**АКУСТИЧЕСКИЕ КОМПОНЕНТЫ ИНТОНАЦИИ** ИНТОНАЦИЯНЕҢ АКУСТИК КОМПОНЕНТЛАРЫ Интонацияне барлыкка китерә торган компонентлар: мелодика, интенсивлык, озынлык, темп, пауза, тембр, басым

**АКУСТИЧЕСКИЙ АСПЕКТ** АКУСТИК АСПЕКТ Фонетикада авазларны физик (акустик) күренеш, ягъни тавыш дулкыннары тирбәнеше буларак караган аспект

**АКЦЕНТ** АКЦЕНТ 1) Басым; 2) Чит телдә сөйләшкәндә авазларны туган телдәгечә итеп әйтү

**АКЦЕНТОЛОГИЯ** АКЦЕНТОЛОГИЯ Тел белеменең басымны (табигатен, типларын, функцияләрен) өйрәнә торган тармагы

**АЛЛАТИВ** АЛЛАТИВ Эш юнәлгән объектны белдерә торган категориаль килеш формасы

**АЛЛЕГОРИЯ** АЛЛЕГОРИЯ Абстракт төшенчәләрне конкрет, тормышчан образлар аша бирүдән гыйбарәт троп

**АЛЛИТЕРАЦИЯ** АЛЛИТЕРАЦИЯ Бер үк тартык авазларны яки авазлар кушылмасын кабатлаудан гыйбарәт стилистик алым

**АЛЛОЛЕКСА** АЛЛОЛЕКСА Билгеле бер сөйләм актында глосса, лексеманың төре, варианты буларак сүз

**АЛЛОЛОГ** АЛЛОЛОГ 1) Сүзнең варианты; 2) Эллиптик сүзтезмәләрдә сүзнең нуль варианты

**АЛЛОМОРФЫ** АЛЛОМОРФЛАР Мәгънәләре белән тәңгәл, кулланышлары сүз формасындагы позицияләренә бәйле булган морфема вариантлары (мәс., -*чик*/-*щик*)

**АЛЛОСЕМА** АЛЛОСЕМА Сема варианты

**АЛЛОФОН** АЛЛОФОН Бер үк фонеманың төрле шартларда төрлечә реальләшүе

**АЛОГИЗМ** АЛОГИЗМ 1) Логика сакланмаган күренеш; 2) Комиклык, ирония тудыру максатыннан логик бәйләнешләрне таркату алымы (стилистик алымнарның берсе)

**АЛТАЙСКИЕ ЯЗЫКИ** АЛТАЙ ТЕЛЛӘРЕ Төрки-монгол, тунгус-маньчжур, япон-корея телләре макрогаиләсенең гомуми атамасы

**АЛФАВИТ** ӘЛИФБА, АЛФАВИТ Бер телнең авазлар системасын чагылдырган, телне язуда беркетү өчен кабул ителгән график билгеләр системасы

**АЛЬВЕОЛА** АЛЬВЕОЛА Өске теш казналары. Кайбер авазларны әйтүдә катнаша торган пассив сөйләм органы

**АЛЬВЕОЛЯРНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** АЛЬВЕОЛЯР ТАРТЫКЛАР Тел очын альвеолаларга тидереп ясала торган тартыклар

**АЛЬТЕРНАЦИЯ** АЛЬТЕРНАЦИЯ Авазларның бер үк нигезле сүзләрдә законлы чиратлашулары (мәс., *вак* – *вагы*)

**АМАЛЬГАМИРУЮЩИЕ ЯЗЫКИ** АМАЛЬГАМАЛАУЧЫ ТЕЛЛӘР *к.* **флективные языки**

**АМЕРИКАНИЗМЫ** АМЕРИКАНИЗМНАР Инглиз теленең Америка вариантыннан алынмалар

**АМОРФНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** АМОРФ ҖӨМЛӘ Җөмлә кисәкләрен канонлашканча аерып күрсәтеп булмый торган җөмлә

**АМОРФНЫЕ СЛОВА** АМОРФ СҮЗЛӘР Морфологик категорияләргә ия булмаган, шуңа да нинди дә булса сүз төркеменә кертеп булмый торган сүзләр (мәс., рус телендә *есть, нет* сүзләре)

**АМОРФНЫЕ ЯЗЫКИ** АМОРФ ТЕЛЛӘР Аффикслары булмаган, грамматик мәгънәләр сүзләрне бер-берсенә ялгау яисә ярдәмлек сүзләр белән белдерелә торган телләр (мәс., кытай теле)

**АМПЛИТУДА** АМПЛИТУДА Авазларны әйткәндә физик матдәнең тирбәнү интенсивлыгы, төп ноктадан читкә китү дәрәҗәсе

**АМПЛИФИКАЦИЯ** АМПЛИФИКАЦИЯ 1) Тәэсирлелек көче үсә бару тәртибендә тупланган синонимнар җыелмасыннан гыйбарәт сөйләм фигурасы; күбесенчә гиперболик чагыштыручыларда кулланыла; 2) Бер телдән икенче телгә күчергәндә текстның киңәюе

**АМРЕДИТА** АМРЕДИТА Нигезне кабатлау юлы белән барлыкка килгән кушма сүз төре

**АМФИБОЛИЯ** АМФИБОЛИЯ Сүзләр фикерне ике төрле аңларга мөмкин булырлык итеп кулланылган сөйләм фигурасы

**АНАГРАММА** АНАГРАММА Криптографик алым, стилистик чара буларак башка сүз яки сүзтезмәдәге хәрефләрне урыннарын алыштырып кую нәтиҗәсендә барлыкка килгән сүз яки сүзтезмә (мәс., *сон - нос, ток – кот, шат – таш* һ.б.)

**АНАКОЛУФ** АНАКОЛУФ Кешеләрнең телне белмәүләре яисә стилистик алым буларак кулланылу нәтиҗәсендә җөмлә кисәкләренең граматик яктан үзара ярашмаулары

**АНАЛИТИЗМ** АНАЛИТИКЛЫК, АНАЛИТИЗМ Телдә сүзнең төп (лексик) һәм өстәмә (грамматик, сүзьясалыш) мәгънәләрен аерым белдерүдә күренә торган типологик үзлеге

**АНАЛИТИЧЕСКАЯ ФОРМА** АНАЛИТИК ФОРМА Сүзнең грамматик формасы буларак кулланылган мөстәкыйль һәм ярдәмче сүзләрдән гыйбарәт тезмә форма

**АНАЛИТИЧЕСКИЕ ГЛАГОЛЫ** АНАЛИТИК ФИГЫЛЬЛӘР Мөстәкыйль сүздән һәм ярдәмче фигыльдән торган фигыльләр (мәс., *тәэмин итү, укып бару*)

**АНАЛИТИЧЕСКИЕ СРЕДСТВА** АНАЛИТИК ЧАРАЛАР Грамматик мәгънәләрне сүзнең тышында торган чаралар ярдәмендә (сүз тәртибе, ярдәмлек сүзләр) белдерә торган чаралар

**АНАЛИТИЧЕСКИЕ ЯЗЫКИ** АНАЛИТИК ТЕЛЛӘР Грамматик мәгънәләр синтетик чаралар (сүз формалары) белән түгел, ә аналитик чаралар, ягъни ярдәмлек сүзләр, сүз тәртибе, интонация белән белдерелә торган телләр (мәс., инглиз, испан телләре)

**АНАЛИТИЧЕСКОЕ СЛОВО** АНАЛИТИК СҮЗ *к.* **сложное слово**

**АНАЛИТИЧЕСКОЕ СЛОЖНОПОДЧИНЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** АНАЛИТИК ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ Ияргчен җөмләсе баш җөмләгә аналитик чаралар белән бәйләнгән кушма җөмлә

**АНАЛОГИЧЕСКИЕ ЯЗЫКИ** АНАЛОГИК ТЕЛЛӘР Җөмләдә сүзләрнең логик, калыплаштырылган тәртибе урнашкан телләр

**АНАЛОГИЯ** АНАЛОГИЯ Телдә бердәй охшаш, тәңгәл туры килә торган күренеш, продуктив күренешләр таралу тенденциясе

**АНАТОЛИЙСКАЯ ГРУППА ЯЗЫКОВ** АНАТОЛИЯ ТЕЛЛӘРЕ ГРУППАСЫ Һинд-Европа телләре семьялыгының хетт, лувия, ликия һ.б. үле телләр төркеме

**АНАФОРА** АНАФОРА Һәр параллель рәтнең (шигырьдә, строфада, прозада) башында бер үк элементларны кабатлаудан гыйбарәт стилистик фигура

**АНГЛИЦИЗМ** АНГЛИЦИЗМ Инглиз теленнән алынган сүз яки телнең башка бер элементы

**АНДРОНИМ** АНДРОНИМ Ир-ат фамилиясеннән ясалган хатын-кыз фамилиясе (мәс., *Кучера – Кучерова* )

**АНТЕВОКАЛЬНЫЙ** АНТЕВОКАЛЬ Сузык алдында килгән (мәс., *аэроплан*)

**АНТИТЕЗА** АНТИТЕЗА Фикерләрне, образларны капма-каршы куюдан гыйбарәт парлы стилистик фигура

**АНТОНИМ** АНТОНИМ Капма-каршы мәгънәле сүзләр (мәс., *матур – ямьсез*, *бирү – алу*)

**АНТОНИМИЯ** АНТОНИМИЯ Сүзләрнең капма-каршы мәгънәдә булуы

**АНТРОПОЛОГИЧЕСКАЯ ЛИНГВИСТИКА** АНТРОПОЛОГИК ЛИНГВИСТИКА Тел белеменең язулары булмаган телләрне өйрәнә торган тармагы

**АНТРОПОНИМЫ** АНТОРОПОНИМНАР Кеше исемнәре, фамилияләр, кушаматларны белдерә торган сүзләр

**АНТРОПОНИМИКА** АНТРОПОНИМИКА Лексикологиянең кеше исемнәрен өйрәнә торган тармагы

**АНТРОПОЦЕНТРИЧЕСКАЯ ПАРАДИГМА** АНТРОПОЦЕНТРИК ПАРАДИГМА Лингвистикада барлык тел күренешләре дә кеше белән бәйләп тикшерелә торган фәнни парадигма

**АОРИСТ** АОРИСТ Тулысынча үткән заманга караган, озак бармаган эш-процессның тулылыгын һәм үсешен күрсәтми торган һинд-европа телләрендәге фигыль формасы

**АПЕЛЛЯТИВ** АПЕЛЛЯТИВ, УРТАКЛЫК ИСЕМ Бер төрдән булган барлык предметлар өчен уртак исем

**АПИКАЛЬНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** АПИКАЛЬ ТАРТЫКЛАР Тел алды тартыкларының бер төре (мондый тартыклар ясалганда тел очы тешләргә һәм альвеолаларга күтәрелә)

**АПОДОЗИС** АПОДОЗИС Иярченле кушма җөмләнең икенче өлеше

**АПОКОЙНУ** АПОКОЙНУ Бер үк кисәккә караган ике тиңдәш булмаган тәмамлыклы конструкция

**АПОКОПА** АПОКОПА Сүз ахырында басымсыз сузыкның төшеп калу күренеше (мәс., *квартира – квартир*)

**АПОСТРОФ** АПОСТРОФ Өске өтер; язу юлыннан өскәрәк куела һәм төрле телләрдә төрле мәгънә (1) ялгызлык исемнәрдә аерылып

торган кисәкне; 2) транскрипциядә тартыкның палатальләшүен (нечкәрүен); 3) сузыкның кыскарган урынын) белдерә торган тамга

**АППЛИКАЦИЯ** АППЛИКАЦИЯ Бер морфема авазларының икенчесе белән өлешчә керешүе, берсе өстенә икенчесе туры килү (мәс., *лиловатый* сүзендә *ов* аваз тезмәсе белән тамыр төгәлләнә һәм суффикс башланып китә; суффиксның бер өлеше тамыр белән өлешчә керешә)

**АППОЗИТИВНОЕ ОТНОШЕНИЕ** АППОЗИТИВ МӨНӘСӘБӘТ Ачыкланучы сүз һәм өстәмә сүз арасындагы мөнәсәбәт

**АРГО** АРГО Аерым социаль төркемнәр тарафыннан башкалар аңламасын өчен махсус уйлап табылган шартлы тел

**АРГОТИЗМЫ** АРГОТИЗМНАР Арго сүзләр һәм әйтелмәләр

**АРЕАЛ** АРЕАЛ Теге яки бу фонетик, лексик, грамматик күренешләрнең таралу өлкәсе

**АРЕАЛЬНАЯ ЛИНГВИСТИКА** АРЕАЛЬ ЛИНГВИСТИКА Лингвистик география методларын кулланып, лингвистик ареалларны өйрәнә торган тел белеме тармагы

**АРТИКЛЬ** АРТИКЛЬ Кайбер телләрдә исем сүз төркеме алдында килеп, аңа билгелелек һәм билгесезлек, род, сан һ.б. мәгънәләр өстәп килә торган дейктик ярдәмлек сүз төркеме

**АРТИКУЛЯЦИОННАЯ БАЗА** АРТИКУЛЯЦИОН БАЗА, АРТИКУЛЯЦИЯ БАЗАСЫ Сөйләм органнарының теге яки бу телдә сөйләшү өчен типик торышлары җыелмасы

**АРТИКУЛЯЦИОННАЯ КЛАССИФИКАЦИЯ ГЛАСНЫХ** СУЗЫК АВАЗЛАРНЫҢ АРТИКУЛЯЦИЯЛӘРЕ БУЕНЧА КЛАССИФИКАЦИЯСЕ Телнең күтәрелү дәрәҗәсе, алда яки артта булуына, иреннәрнең, йомшак аңкауның торышына карап, сузык авазларны төркемләү

**АРТИКУЛЯЦИОННАЯ ФОНЕТИКА** АРТИКУЛЯЦИОН ФОНЕТИКА Фонетиканың сөйләм органнарының авазларны әйткәндәге эшчәнлеген өйрәнә торган тармагы

**АРТИКУЛЯЦИОННЫЕ НАВЫКИ** АРТИКУЛЯЦИОН КҮНЕКМӘЛӘР Аерым бер телнең артикуляцион базасын үзләштерү дәрәҗәсе

**АРТИКУЛЯЦИЯ** АРТИКУЛЯЦИЯ Сөйләм органнарының нинди дә булса авазны әйткәндәге эшчәнлеге

**АРХАИЗМ** АРХАИЗМ Телдә актив булган синонимнары белән алмаштырылган, кулланылыштан төшереп калдырылган искергән сүз, әйтелмә яки элемент

**АРХЕТИП** АРХЕТИП Соңрак чорларда барлыкка килгән формалар өчен чыганак форма

**АРХИСЕМЕМА** АРХИСЕМЕМА Билгеле бер класс берәмлекләренең барысына да хас, аларның уртак категориаль билгеләрен чагылдыра торган ыруг башы, интеграцияли торган семема

**АРХИФОНЕМА, СЛАБАЯ ФОНЕМА** АРХИФОНЕМА, КӨЧСЕЗ ФОНЕМА Аңа туры килгән парлы фонемаларга караганда дифференциаль үзенчәлекләре азрак булган фонема (мәс., *т* – саңгырау тартык, *д* – яңгырау тартык, *т-д* архифонемасының андый билгесе юк)

**АСЕМАНТИЧЕСКИЙ** АСЕМАНТИК Мәгънәгә ия булмаган функция башкара торган (тел берәмлеге)

**АСИНДЕТОН** АСИНДЕТОН Теркәгечсез бәйләнеш

**АСПЕКТНЫЕ СЛОВАРИ** АСПЕКТЛЫ СҮЗЛЕКЛӘР Сүзнең парадигматикасы (синонимик, антонимик һ.б. сүзлекләр), грамматик үзлекләре (морфемалар, сүзьясалыш сүзлеге), тарихы (этимологик, тарихи сүзлекләр), дөрес язылышы (орфографик) һәм әйтелеше (орфоэпик), аерым территорияләрдә таралышы (диалектологик сүзлекләр) турында мәгълүматлар бирелгән сүзлекләр

**АСПИРАТЫ** АСПИРАТЛАР, АСПИРАТ ТАРТЫКЛАР Ярыаралары мускулатурасы киеренке хәлгә килмичә генә тарайганда, һаваның тавыш ярыларына ышкылуы нәтиҗәсендә барлыкка килә торган тартыклар; җиңелчә сулышлы тартыклар (мәс., *h*)

**АССИМИЛЯЦИЯ** АССИМИЛЯЦИЯ Авазларның әйтелеш һәм яңгыраш ягыннан бер-берсенә охшашлануы (мәс., *төнлә* – [*төннә*])

**АССОНАНС** АССОНАНС Стилистик чара буларак охшаш яңгырашлы яки бер үк авазларны куллану

**АСТРОНИМИКА** АСТРОНИМИКА Ономастиканың күк җисемнәре атамаларын өйрәнә торган тармагы

**АТРИБУТ** АТРИБУТ *к.* **определение**

**АТРИБУТИВНОЕ ОТНОШЕНИЕ** АТРИБУТИВ МӨНӘСӘБӘТ Предмет һәм аның билгесен белдергән сүзләрдән торган сүзтезмәдә ачыклау бәйләнеше булган яки җөмләдә аергыч белән аерылмыш арасындагы мөнәсәбәт

**АТРИБУТИВНО-ПРЕДИКАТИВНЫЙ** АТРИБУТИВ ҺӘМ ПРЕДИКАТИВ Атрибутив функцияләре дә, предикатив функцияләре дә булган

**АТРИБУТИВНЫЕ ФОРМЫ ГЛАГОЛА** ФИГЫЛЬНЕҢ АТРИБУТИВ ФОРМАЛАРЫ *к.* **причастие** и **деепричастие**

**АТТРАКЦИЯ** АТТРАКЦИЯ Мәгълүм грамматик форманың үз синтаксик мәгънәсеннән күчеп, икенче бер форма мәгънәсенә таркалуы

**АУГМЕНТ** АУГМЕНТ Арттыру, авазлар өстәү күренеше

**АУДИРОВАНИЕ** АУДИРОВАНИЕ Чит тел өйрәтү методикасында: өйрәнү, аңлау максатыннан яңгыраган сөйләмне тыңлау

**АФЕЗА** АФЕЗА Сүзнең, сүзтезмәнең тарихи үзгәрешләр нәтиҗәсендә бер өлеше төшеп калу

**АФРАЗИЙСКИЕ ЯЗЫКИ** СЕМИТ-ХАМИТ ТЕЛЛӘРЕ Семит тармагына кергән гарәп, мехри, сокороти, эххили, махар, тигре, ассирия, хамит тармагына караган шельх, туарег, кабил, мазигт һәм ассирия-вавилон, хананей, финикия, арамей, гёз, ливия, нумидия, гетул үле телләре гаиләсенең гомуми атамасы

**АФФЕКТИВНАЯ ЛЕКСИКА** АФФЕКТИВ ЛЕКСИКА Ачу, ярсу, курку вакытында әйтелә торган сүзләр

**АФФИКС** АФФИКС Тамырны лексик һәм грамматик яктан үзгәртә яисә җөмләдә сүзләр арасындагы мөнәсәбәтләрне белдерә торган морфема

**АФФИКСАЛЬНЫЕ ДЕРИВАТЫ** АФФИКСАЛЬ ДЕРИВАТЛАР Нигездән яңа сүз ясагыч суффикслар, префикслар, постфикслар һәм циркумфикслар (аффикслар комбинациясе) (мәс., *уку**чы**, **пра**язык, кто-**нибудь**, **под**окон**ник***)

**АФФИКСАЛЬНЫЕ СПОСОБЫ СЛОВООБРАЗОВАНИЯ** СҮЗ ЯСАЛЫШЫНЫҢ АФФИКСАЛЬ ЫСУЛЛАРЫ Сүзләрнең суффикслар, префикслар, постфикслар һәм циркумфикслар ярдәмендә ясалуы

**АФФИКСАЦИЯ** АФФИКСАЦИЯ Тамыр яки нигезгә аффикслар ялгаудан гыйбарәт морфологик процесс

**АФФИКСОИД** АФФИКСОИД Аффикс функциясендәге тамыр морфема

**АФФИЛИАЦИЯ** АФФИЛИАЦИЯ Нигез телнең аннан үсеп чыккан телләр белән генетик бәйләнеше

**АФФРИКАТА** АФФРИКАТА Бер үк урында ясала торган йомык һәм өрелмәле тартыкларның кушылуыннан барлыкка килгән тартык аваз (мәс., [$^{т}$*ч*])

**АХЛАУТ** АХЛАУТ Тирән тел арты фарингаль яңгырау тартык

## Б

**БАЛКАНИЗМ** БАЛКАНИЗМ Теге я бу телгә балкан телләренең берсеннән кергән сүз яки тәгъбир

**БАЛКАНИСТИКА** БАЛКАНИСТИКА Балкан ярымутравында яшәгән халыкларның телләре, әдәбияты, тарихы, мәдәниятын өйрәнә торган фән

**БАЛКАНСКИЙ ЯЗЫКОВОЙ СОЮЗ (БАЛКАНСКИЕ ЯЗЫКИ)** БАЛКАН ТЕЛЛӘРЕ БЕРЛЕГЕ (БАЛКАН ТЕЛЛӘРЕ) Төрле системага караган болгар, македон, аромун, албан, яңа грек, серб, хорват, словен, көньяк серб, роман телләре берлеге; *к.* **языковой союз**

**БАЛТИЙСКИЙ ЯЗЫКОВОЙ СОЮЗ** БАЛТИКА ТЕЛЛӘРЕ БЕРЛЕГЕ Латыш, литва, эстон, норвег, швед телләре һәм кайбер төньяк немец диалектлары кергән телләр берлеге

**БАЛТИЙСКИЕ ЯЗЫКИ** БАЛТИКА ТЕЛЛӘРЕ Һинд-европа телләре гаиләсенә кергән латыш, литва, прусс телләре

**БАЛТИСТИКА** БАЛТИСТИКА Балтика телләре, әдәбияты, мәдәнияте, тарихын өйрәнә торган фән

**БАНТУ ЯЗЫКИ** БАНТУ ТЕЛЛӘРЕ Африканың көньяк һәм үзәк өлкәләрендәге кардәш телләр группасының исеме (суахили, лингала, килуба һәм чилуба, луганда һ.б. телләр)

**БЕЗЛИЧНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ИЯСЕЗ ҖӨМЛӘ Аерым сүз яки сүзтезмә белән белдерелгән бер составлы җөмлә; хәбәрнең эчтәлегеннән башкаручы затны билгеләп булмый торган җөмлә. Ике төргә бүленә: билгеле үтәүчеле һәм билгесез үтәүчеле җөмлә

**БЕЗЛИЧНЫЕ ГЛАГОЛЫ** ЗАТЛАНЫШСЫЗ ФИГЫЛЬЛӘР Затта төрләнми торган фигыльләр: исем фигыль *(уйлау, сикерү, бару),* сыйфат фигыль *(өзелгән чәчәк, җыелган сулар, туар көн),* хәл фигыль *(сугып-сугып, көлә-көлә, килеп),* инфинитив *(язарга, туктарга, ташламаска, сөйләмәскә)*

**БЕСПИСЬМЕННЫЕ ЯЗЫКИ** ЯЗУСЫЗ ТЕЛЛӘР Борынгыдан килгән язма әдәбияты, үз язулары, алфавитлары булмаган телләр

**БЕССОЮЗНАЯ СВЯЗЬ** ТЕРКӘГЕЧСЕЗ БӘЙЛӘНЕШ Кушма җөмләләрдә аерым җөмләләрнең үзара теркәгечләрсез, бары интонация (санау, каршы кую, көттерү паузалары) ярдәмендә генә бәйләнеше

**БЕССОЮЗНОЕ СЛОЖНОСОЧИНЁННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ТЕРКӘГЕЧСЕЗ ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘ Аерым җөмләләре үзара санау, каршы кую интонациясе аша бәйләнгән тезмә кушма җөмлә

**БИЛИНГВ** БИЛИНГВ Ике телдә дә бертигез дәрәҗәдә аралаша-аңлаша ала торган кеше

**БИЛИНГВИЗМ** БИЛИНГВИЗМ, ИКЕТЕЛЛЕЛЕК Нинди дә булса бер территориядә, дәүләттә яшәүче халыкның туган тел белән бергә икенче телне дә белүе, ике телдә иркен сөйләшүе; ике телдә сөйләшүчелек (мәс., *рус-татар икетеллелеге*); *к.* **двуязычие**

**БИОЛОГИЧЕСКИЙ АСПЕКТ ЗВУКОВ РЕЧИ** СӨЙЛӘМ АВАЗЛАРЫНЫҢ БИОЛОГИК АСПЕКТЫ Фонетикада авазларны өйрәнүнең бер аспекты; авазлар, кешенең биологик функци-

ясе буларак, сөйләм органнарының эшчәнлек нәтиҗәсе буларак каралалар. Сөйләм органнары һәм аларның катнашы тикшерелә

**БЛАТНОЙ ЯЗЫК** КАРАКЛАР (ҖИНАЯТЬЧЕЛӘР) ТЕЛЕ Җинаятьчеләр арасында гына кулланыла торган үзенчәлекле сүзләрдән һәм символлардан торган тел

**БОКОВОЙ ЗВУК** ЯН АВАЗ *к.* **боковой согласный**

**БОКОВОЙ СОГЛАСНЫЙ** ЯН ТАРТЫК *к.* **латеральный согласный**

**БОКОВОЙ СОНАНТ** ЯН СОНАНТ *к.* **боковой согласный**

**БУДУЩЕЕ ВРЕМЯ** КИЛӘЧӘК ЗАМАН Эшнең сөйләү моментыннан соң булачагын белдерә торган хикәя һәм сыйфат фигыльләрнең бер категориясе

**БУДУЩЕЕ КАТЕГОРИЧЕСКОЕ ВРЕМЯ** КАТЕГОРИК КИЛӘЧӘК ЗАМАН, КАТГЫЙ КИЛӘЧӘК ЗАМАН Эш-хәлнең сөйләү моментыннан соң тәгаен булачагын катгыйлык төсмере белән белдерә торган заман формасы (мәс., *алачакбыз, бирәчәк, көтәчәкләр, сагыначакмын, сикерә алмаячак* һ.б.)

**БУДУЩЕЕ НЕОПРЕДЕЛЁННОЕ ВРЕМЯ** БИЛГЕСЕЗ КИЛӘЧӘК ЗАМАН Эш-хәлнең сөйләү моментыннан соң булу ихтималын белдерә торган заман формасы (мәс., *китәрләр, алыр, эрер, беленер, барырсыз, язарбыз* һ.б.ш.)

**БУДУЩЕЕ-ПРОШЕДШЕЕ ВРЕМЯ** КИЛӘЧӘК ҮТКӘН ЗАМАН Киләчәктә үтәлергә тиеш булган эшне үткән заманга күчерә торган фигыль формасы (мәс., *алачак идем, бирәчәк идең, китерәчәк түгел иде, бармаячак идек, сокланачак идегез* һ.б.)

**БУКВА** ХӘРЕФ Тел системасында авазларның алфавит тәртибендә бирелә торган график тамгасы

**БУКВЕННОЕ ПИСЬМО** ХӘРЕФЛЕ ЯЗУ Бер билге бер авазга (фонемага) туры килгән язу. Фонетик язуның бер төре

**БЫТОВАЯ (ОБИХОДНАЯ) ЛЕКСИКА** КӨНКҮРЕШ ЛЕКСИКАСЫ Көндәлек тормышта, көнкүрештә кулланыла торган сүзләр: йорт кирәк-яраклары, гореф-гадәт, кием-салым, азык-төлек, йорт хайваннары һ.б. атамалар (мәс., *кашык, туй, күлмәк, коймак, песи* һ.б.)

# В

**ВАЛЕНТНОСТЬ** ВАЛЕНТЛЫК Тулы мәгънәле сүзнең җөмләдә башка сүзләр белән мәгънәви, грамматик, синтаксик бәйләнешкә керү, сүзтезмәләр барлыкка китерә алу сәләте

**ВАЛЕНТНОСТЬ ГЛАГОЛА** ФИГЫЛЬНЕҢ ВАЛЕНТЛЫГЫ Фигыльнең төрле сүзләр белән мөнәсәбәткә керү мөмкинлеге (мәс., *әни килә:* субъект → фигыль. Бер валентлы. *Бала китап укый*: субъект → фигыль → объект. Ике валентлы)

**ВАРВАРИЗМ** ВАРВАРИЗМ Башка тел үрнәгендә ясалган һәм әдәби тел нормаларына, законнарына ярашмый торган сүз яки сүзтезмәләре

**ВАРИАНТ МОРФЕМЫ** МОРФЕМА ВАРИАНТЫ *к.* **алломорфы**

**ВАРИАНТ ФОНЕМЫ** ФОНЕМА ВАРИАНТЫ *к.* **аллофоны**

**ВАРИАНТ ЯЗЫКА** ТЕЛ ВАРИАНТЫ Тел яшәешенең параллель кулланыла торган формасы

**ВАРИАНТЫ** ВАРИАНТЛАР Бер үк тел берәмлегенең сөйләмдә төрле позициядә, стилистик һәм сөйләүченең максатларына бәйлелектә төрле кулланылышы

**ВАРИАНТЫ СЛОВА** СҮЗНЕҢ ВАРИАНТЛАРЫ Бер үк сүзнең орфоэпик, фонетик, морфологик яктан үзгә, әмма бер үк мәгънәне белдерә торган төрләре

**ВАРИАНТЫ СЛОВА АКЦЕНТОЛОГИЧЕСКИЕ** СҮЗНЕҢ БАСЫМЛЫ ВАРИАНТЛАРЫ Сүзнең басым белән аерылып торган вариантлары (мәс., *ба'ржа - баржа'*)

**ВАРИАНТЫ СЛОВА ОРФОЭПИЧЕСКИЕ** СҮЗНЕҢ ОРФОЭПИК ВАРИАНТЛАРЫ Бер үк сүзнең әйтелеше белән аерылып торган төрләре; *к.* **варианты слова**

**ВАРИАНТЫ СЛОВА ФОНЕТИЧЕСКИЕ** СҮЗНЕҢ ФОНЕТИК ВАРИАНТЛАРЫ Бер үк сүзнең фонетик яктан аерылып торган төрләре; *к.* **варианты слова**

**ВАРИАНТЫ СЛОВОФОРМ** СҮЗ ФОРМАЛАРЫНЫҢ ВАРИАНТЛАРЫ Вариантлар хасил итә торган формантларның берсен алган лексемалар (мәс., *экранизировать – экранизовать*)

**ВАРИАНТЫ ФЛЕКСИИ** ФЛЕКСИЯ ВАРИАНТЛАРЫ Төп флексияләр белән бергә кулланыла торган флексияләр (мәс., *Чашка ча**ю**. – Чашка ча**я***)

**ВАРИАНТЫ ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИХ ЕДИНИЦ** ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ ВАРИАНТЛАРЫ Бер үк мәгънә белдерә торган, әмма компонентлары лексик, грамматик яктан аерылып торган фразеологик берәмлекләр

**ВАРИАНТЫ ЯЗЫКОВЫХ ЕДИНИЦ** ТЕЛ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕНЕҢ ВАРИАНТЛАРЫ Бер үк тел берәмлегенең аваз составы белән генә аерылып торган формаль төрләре

**ВВЕДЕНИЕ** КЕРЕШ, КЕРЕШ ӨЛЕШ Сөйләмнең, текстның башлангыч өлеше, төп өлешкә кадәр булган кисәк

**ВВЕДЕНИЕ В ЯЗЫКОЗНАНИЕ** ТЕЛ БЕЛЕМЕНӘ КЕРЕШ Телнең табигатен, асылын ачыклый, иҗтимагый характерын тикшерә торган тел белеме курсы

**ВВОДНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** КЕРЕШ ҖӨМЛӘ Кереш сүзләр кебек үк функция башкара торган, бер кисәгенә дә граматик бәйләнмәгән җөмлә эчендәге җөмлә

**ВВОДНОЕ СЛОВО** КЕРЕШ СҮЗ Грамматик яктан җөмлә кисәкләренә бәйләнмәгән һәм үзе дә җөмлә кисәге булмаган, бары сөйләүченең объектив чынбарлыкка, сөйләмгә мөнәсәбәтен белдерә торган сүз яки сүзтезмә (мәс., *минемчә, шулай итеп, беренчедән*)

**ВЕЛЯРИЗАЦИЯ** ВЕЛЯРЛАШУ Телнең арткы өлеше йомшак аңкауга тию сәбәпле, тон һәм шауны кисәк төшереп, тартык авазның калын әйтелүенә китерә торган өстәмә артикуляция

**ВЕРБОИДЫ** ВЕРБОИДЛАР Семантик яктан процесс, эшхәл мәгънәсен саклаган хәлдә аны өлешчә предметлаштырып атап яки билге булып килә торган фигыль формалары (инфинитив, исем фигыль, масдар, супин, причастие, деепричастие)

**ВЕРСИЯ** ВЕРСИЯ Чынбарлыкның субъектка яки кыек объектка мөнәсәбәтен белдерә торган грамматик категория (кавказ, семит, кайбер һинд-европа телләренә хас)

**ВЕТВЬ ЯЗЫКОВАЯ** ТЕЛ ТАРМАГЫ Телләр семьялыгында генетик якынлыкларыннан чыгып берләштерелгән телләр төркеме

**ВЗАИМНО-ВОЗВРАТНЫЙ ЗАЛОГ** УРТАКЛЫК ЮНӘЛЕШЕ Эшкә берничә үтәүче катнашуны белдерә торган фигыль формасы

**ВЗАИМОВЛИЯНИЕ ЯЗЫКОВ** ТЕЛЛӘРНЕҢ ҮЗАРА ТӘЭСИР ИТЕШҮЕ Престиж потенциалы бердәй яки бик үк аерылып тормаган ике яки аннан да күбрәк телләрнең аралашу барышында бер-берсенә йогынтысы

**ВЗРЫВНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ШАРТЛАУЛЫ ТАРТЫКЛАР Артикуляцион органнар алдан тоташкан хәлдә булып, авазларны әйткәндә кисәк ачылып китү сәбәпле хасил булган тартыклар (мәс., [*п*], [*б*], [*д*])

**ВИБРАНТЫ** ВИБРАНТЛАР *к.* **дрожащие согласные**

**ВИД** ВИД Рус телендә фигыльдә совершенный (эш-процессның төгәлләнүен) һәм несовершенный вид (эш-процессның төгәлләнмәвен) грамматик классларын капма-каршы куя һәм процессуаль билге характерындагы аерымлыкларны күрсәтә торган морфологик категория

**ВИДОВЫЕ ПАРЫ ГЛАГОЛОВ** ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ ВИД ЯГЫННАН ПАРЛАРЫ Лексик-семантик яктан тәңгәл килгән совершенный һәм несовершенный видларда каршы куелган ике фигыль (мәс., *переписать – переписывать, усвоить – усваивать*)

**ВИНИТЕЛЬНЫЙ ПАДЕЖ** ТӨШЕМ КИЛЕШЕ Эшнең туры объектын белдерә торган килеш формасы

**ВИСЯЧИЙ ДЕФИС** АСЫЛМА ДЕФИС Бер үк компонентка караган кисәкләре булган кушма сүзнең икенче өлешендә түгел, ә беренчесендә куела торган дефис (мәс., *радио- һәм телепрограммалар, шести- и семилетние дети*)

**ВИТАЛЬНОСТЬ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ ВИТАЛЬЛЕГЕ Төрле этнолингвистик факторларга (язуның булуы һәм борынгылыгы,

телдә сөйләшүчеләр саны, милли телнең яшәү үзенчәлекләре) бәйле рәвештә телнең тотрыклылыгы, яшәргә сәләтле булуы

**ВНЕЛИТЕРАТУРНАЯ ЛЕКСИКА** ӘДӘБИ БУЛМАГАН ЛЕКСИКА Әдәби телгә кермәгән, әдәби тел нормаларына сыймаган сүзләр (диалектизмнар, арготизмнар, жаргонизмнар, вульгаризмнар)

**ВНЕШНЯЯ РЕЧЬ** ТЫШКЫ СӨЙЛӘМ Тыңлаучы яки укучы булуын күздә тоткан сөйләм

**ВНУТРЕННЯЯ РЕЧЬ** ЭЧКЕ СӨЙЛӘМ 1) Сөйләмне аңда планлаштыру һәм контрольләү; 2) Эчтән генә әйтеп карау; 3) Сөйләм тууның фазасы буларак эчтән программалауның бер этабы

**ВНУТРЕННЯЯ ФЛЕКСИЯ** ЭЧКЕ ФЛЕКСИЯ Грамматик форма ясау өчен сүзнең тамырына авазлар өстәлү яки сүзнең тамырындагы авазлар үзгәрү күренеше (мәс., гарәп телендә: *китап – кәтиб, мәктәп – мәктүб*)

**ВНУТРЕННЯЯ ФОРМА СЛОВА** СҮЗНЕҢ ЭЧКЕ ФОРМАСЫ Ясалма сүз номинациясенә салынган билге

**ВОЗВРАТНЫЕ ГЛАГОЛЫ** КАЙТЫМЛЫ ФИГЫЛЬЛӘР Рус телендә -ся постфикслы күчемсез фигыльләрнең лексик-грамматик төркеме

**ВОЗВРАТНЫЙ ЗАЛОГ** КАЙТЫМ ЮНӘЛЕШЕ Эш-хәрәкәтнең башкаручының үзенә кайтуын (төп мәгънәсе), шулай ук эшнең күчемсезлеген, ихтыярсыздан башкарылган эшне, процессның кабатлануын, төшем юнәлеше мәгънәсен белдерә торган фигыльләргә хас грамматик категория

**ВОКАБУЛА** ВОКАБУЛА Лексикология һәм лексикография объекты буларак аерым сүз

**ВОКАЛ** ВОКАЛ Сузык аваз һәм шуны белдергән хәреф

**ВОКАЛИЗАЦИЯ** ВОКАЛИЗАЦИЯ Тартык авазның сузыкка күчүе

**ВОКАЛИЗМ** ВОКАЛИЗМ 1) Аерым телдәге сузык авазлар системасы; 2) Сузык авазларның билгеләре һәм алар арасындагы мөнәсәбәт

**ВОКАТИВ** ВОКАТИВ Формаль яктан җөмләгә карамаган, сөйләүче мөрәҗәгать иткән затның игътибарын тарту өчен әйтелгән эндәшү сүзләре, эндәшү формалары

**ВОКАТИВНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ВОКАТИВ ҖӨМЛӘ Тойгылы интонация белән әйтелә торган һәм бердән-бер баш кисәге исем белән генә белдерелгән җөмлә

**ВОЛЖСКО-ФИНСКИЕ ЯЗЫКИ** ИДЕЛ БУЕ ФИН ТЕЛЛӘРЕ Фин-угор телләренә караган мордва, мари телләренең шартлы классификациясе

**ВОПРОС** СОРАУ 1) Сөйләүче тарафыннан сөйләм адресатыннан билгеле бер мәгълүмат алу максаты белән әйтелгән сүз, җөмлә; 2) *к.* **вопросительный знак**

**ВОПРОСИТЕЛЬНАЯ ИНТОНАЦИЯ** СОРАУ ИНТОНАЦИЯСЕ Ниндидер мәгълүмат кирәклеген, сорауны белдергән, төрле просодик чаралар ярдәмендә башкарыла торган интонация

**ВОПРОСИТЕЛЬНАЯ ЧАСТИЦА** СОРАУ КИСӘКЧӘСЕ Үзе бәйләнеп килгән сүзгә сорау мәгънәсе бирә торган кисәкчә (мәс., *качкын**мы**, җен**ме***?)

**ВОПРОСИТЕЛЬНОЕ МЕСТОИМЕНИЕ** СОРАУ АЛМАШЛЫГЫ Әйберне, затны, билгене, рәвешне, саннарны ачыклау өчен кулланыла торган алмашлыклар (мәс., *кем, нәрсә, кайсы, каян, кайчан*)

**ВОПРОСИТЕЛЬНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** СОРАУ ҖӨМЛӘ *к.* **вопрос** (*1 мәгъ.*)

**ВОПРОСИТЕЛЬНЫЙ ЗНАК** СОРАУ БИЛГЕСЕ Язуда сорау интонациясе белән әйтелгән җөмләнең ахырына куела торган тыныш билгесе (?) (мәс., *Син бүген Казанга китәсеңме?*)

**ВОПРОСНО-ОТВЕТНОЕ ЕДИНСТВО** СОРАУ-ҖАВАП БЕРДӘМЛЕГЕ Берсендә сорау икенчесендә шул сорауга мөнәсәбәт белдерелгән ике яки аннан да күбрәк информацион репликалардан тора торган диалог фрагменты

**ВОСКЛИЦАНИЕ** ӨНДӘҮ Җөмләне яки аның бер өлешен көчле хис-тойгы (дулкынлану, шатлык, ачу һ.б.) белән әйтү

**ВОСКЛИЦАТЕЛЬНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ӨНДӘҮ ҖӨМЛӘ Көчле хис, тойгы белән әйтелгән җөмлә

**ВОСКЛИЦАТЕЛЬНЫЙ ЗНАК** ӨНДӘҮ БИЛГЕСЕ Язуда көчле хисне, тойгыны белдергән интонация белән әйтелгән җөмлә ахырында, эндәш сүзләрдән, ымлыклар, кисәкчәләрдән соң, цитата эчендә авторның фикергә мөнәсәбәтен белдерү өчен куела торган тыныш билгесе (!)

**ВОСТОЧНО-КАВКАЗСКАЯ СЕМЬЯ ЯЗЫКОВ** КӨНЧЫГЫШ КАВКАЗ ТЕЛЛӘРЕ СЕМЬЯЛЫГЫ Территориаль яктан Чечня, Ингушетия, Дагстан, Грузия һәм Азәрбайҗанның төньягында таралган һәм биш төркемгә берләштерелгән телләр (чечен, ингуш, авар, лак, даргин, лезгин) семьялыгы

**ВОСТОЧНО-СЛАВЯНСКАЯ ЛЕКСИКА** КӨНЧЫГЫШ СЛАВЯН ЛЕКСИКАСЫ Көнчыгыш славян телләренең берлеге чорыннан сакланып калган, ягъни борынгы рус лексикасы

**ВОСТОЧНО-СЛАВЯНСКИЕ ЯЗЫКИ** КӨНЧЫГЫШ СЛАВЯН ТЕЛЛӘРЕ Славян телләренең рус, украин, белорус телләрен берләштергән төркеме

**ВОСТОЧНЫЙ ДИАЛЕКТ** КӨНЧЫГЫШ ДИАЛЕКТ Татар теленең тубыл-иртыш, бараба, том сөйләшләрен берләштергән себер татарлары диалекты

**ВОСХОДЯЩИЙ ДИФТОНГ** КҮТӘРЕЛМӘ ДИФТОНГ Чын дифтонг булмаган телләрдә башта тартык аннан сузык аваз килеп ясалган дифтонг (мәс, *йа, wa* ); *к.* **дифтонг**

**ВРЕМЕННАЯ КАТЕГОРИЯ** ЗАМАН КАТЕГОРИЯСЕ Объектив заманның телдәге чагылышы

**ВРЕМЕННОЕ ИЗМЕНЕНИЕ** ЗАМАН БЕЛӘН ТӨРЛӘНЕШ Фигыльләрнең заман белән төрләнүе

**ВРЕМЯ (глагола)** ЗАМАН (фигыльдә) Эш яки хәлнең сөйләм моментына үтәлү вакытын мөнәсәбәттә белдерә торган фигыльләргә хас грамматик категория (хәзерге, киләчәк, үткән заман)

**ВСЕОБЩИЙ ЯЗЫК** ГОМУМИ ТЕЛ Интерлингвистикада: төрле милләт кешеләре аралашканда кулланырга мөмкин булган тел

**ВСПОМОГАТЕЛЬНЫЕ СЛОВА** ЯРДӘМЛЕК СҮЗЛӘР Аерым лексик мәгънә белдерми, сөйләмдә төрле сүзләр арасындагы мөнәсәбәтләрне оештыруда кулланыла торган сүзләр (бәйлекләр, теркәгечләр)

**ВСПОМОГАТЕЛЬНЫЙ ГЛАГОЛ** ЯРДӘМЧЕ ФИГЫЛЬ Төп фигыльгә ияреп аңа үзгә мәгънә төсмере өсти торган фигыль; аналитик фигыль составында грамматик функция үти торган фигыль

**ВСПОМОГАТЕЛЬНЫЙ ЯЗЫК** ЯРДӘМЧЕ ТЕЛ Аралашу процессында ярдәмче роль үти торган аралашу чарасы (тел)

**ВСТАВКА** ӨСТӘМӘ *к.* **эпентеза**

**ВСТАВКА АСЕМАНТИЧЕСКОЙ ФОНЕМЫ** АСЕМАНТИК ФОНЕМА ЯЛГАНУ Мәгънәгә ия булмаган функция башкара торган, мәгънәви эчтәлеге булмаган фонема ялгану; морфонологик күренеш (мәс., *ике + ш + әр* һ.б.)

**ВСТАВНЫЕ КОНСТРУКЦИИ** ӨСТӘМӘ КОНСТРУКЦИЯЛӘР Җөмлә структурасына керми торган, бары өстәмә аңлатмалар, төгәллек бирү характерындагы, ләкин җөмлә белән тыгыз бәйләнгән, конкрет эчтәлек белдерә торган конструкцияләр

**ВТОРИЧНЫЙ ТЕКСТ** ИКЕНЧЕЛ ТЕКСТ Башка текст базасында аның төп эчтәлеген саклаган хәлдә төзелгән текст

**ВТОРОЙ ЯЗЫК** ИКЕНЧЕ ТЕЛ Индивид яки халыкның туган тел белән бер дәрәҗәдә кулланган теле

**ВТОРОСТЕПЕННОЕ УДАРЕНИЕ** ӨСТӘМӘ БАСЫМ Төп басымга ияреп килә торган көчсез басым; гадәттә кушма сүзләргә хас (мәс., *башбаштаклыклар* сүзендә *-лар* иҗегенә беренче дәрәҗә басым, *-так-* иҗегенә икенче дәрәҗә басым төшә)

**ВТОРОСТЕПЕННЫЕ ЧЛЕНЫ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘНЕҢ ИЯРЧЕН КИСӘКЛӘРЕ Баш кисәкләргә яки үзара берберсенә ияреп, килгән җөмлә кисәкләре: аергыч, тәмамлык, хәл, аныклагыч

**ВУЛЬГАРИЗМ** ВУЛЬГАРИЗМ Әдәбиятта, сөйләм телендә очрый, әмма әдәби тел нормаларына туры килми торган, әдәпсез сүз яки гыйбарә

**ВУЛЬГАРНЫЙ ЯЗЫК** ВУЛЬГАР ТЕЛ Тупас, әдәпсез, бозык тел

**ВЫБОР ЯЗЫКА** ТЕЛНЕ САЙЛАУ Аралашуда теге яки бу телгә яисә телнең теге яки бу яшәеш формасына өстенлек бирү

**ВЫЖИВАЕМОСТЬ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ ЯШӘРГӘ СӘЛӘТЛЕЛЕГЕ *к.* **витальность языка**

**ВЫМИРАЮЩИЙ ЯЗЫК** ҮЛЕП БАРГАН ТЕЛ Онытылып барган, шул телдә сөйләшүчеләрнең күпчелеге тарафыннан кулланылмый башлаган тел

**ВЫПАДЕНИЕ ЗВУКА** АВАЗ ТӨШЕП КАЛУ Бер группадагы берәр авазның язмада сакланган хәлдә сөйләмдә ассимиляция нигезендә бөтенләй әйтелмәве яки көчсезрәк әйтелеше

**ВЫПАДЕНИЕ СЛОГА** ИҖЕК ТӨШЕП КАЛУ Тарихи процесста ике сүз кушылганда кайбер иҗекләрнең төшеп калуы (мәс., *беләзек* > *белә<u>к</u>* + *<u>йө</u>зек* )

**ВЫСОКИЙ СТИЛЬ** ЮГАРЫ СТИЛЬ Әдәби телдән килгән традицияләргә таяна һәм тормыш-көнкүренешнең интеллектуаль өлкәләрендә, гадәттә, югары белемле кешеләр тарафыннан кулланыла торган стиль

**ВЫСОТА ЗВУКА** АВАЗ ЮГАРЫЛЫГЫ Авазның тизлеге, ягъни тавыш ярыларының вакыт эчендәге тирбәнү санына бәйле ешлыгы: интонацияне билгеләү, кайбер телләрдә басымлы һәм басымсыз иҗекләрне аеру өчен хезмәт итә

**ВЫСОТА ТОНА** ТОН ЮГАРЫЛЫГЫ Тавыш ярыларының билгеле бер вакыт эчендә селкенүенә, шулай ук тавыш бөрмәләренең (складкаларының) массасы һәм озынлыгына бәйле тавыш үзенчәлеге

**ВЫТЕСНЕНИЕ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ КЫСРЫКЛАНУЫ Теге яки бу милләтнең туган теле икенче тел белән алмашыну

**ВЫСШИЕ ЕДИНИЦЫ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ ЮГАРЫ ДӘРӘҖӘДӘГЕ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ Фонемалардан аермалы буларак, билгеле бер мәгънәгә ия берәмлекләр (мәс., сүз, сүзтезмә, фразеологик берәмлек)

# Г

**ГАЗЕТНО-ПУБЛИЦИСТИЧЕСКИЙ СТИЛЬ** ГАЗЕТА-ПУБЛИЦИСТИКА СТИЛЕ Әдәби телнең функциональ-стилистик төре; актуаль мәсьәләләр белән массакүләм таныштыру өлкәсенең тел чаралары

**ГАМЗА** ҺӘМЗӘ Гарәп телендә, шулай ук татар теленә кергән кайбер гарәп алынмаларында йомык шартлаулы тартык аваз һәм шул авазны белдергән тамга – бугаз тартыгы билгесе [ۂ]

**ГАПЛОЛОГИЯ** ГАПЛОЛОГИЯ Сүздә морфемалар, нигез һәм суффикс чигендә ике бер төрле иҗекнең берсе төшеп калуы белән характерлана торган комбинатор үзгәреш (мәс., *знаменосец* > *знаме<u>но</u> + носец, минералогия* > *минера<u>ло</u> + логия* )

**ГАРМОНИЯ** ГАРМОНИЯ, ЯРАШУ Билгеле бер авазларның үзара ярашуы, төзек яңгырашы (мәс., рәт гармониясе, ирен гармонясе); *к.* **сингармонизм**

**ГАРМОНИЯ ГЛАСНЫХ** СУЗЫКЛАР ГАРМОНИЯСЕ Сүздәге сузыкларның беренче иҗектәге сузыкка рәте буена ярашуы; әгәр беренче иҗектәге сузык алгы рәт (нечкә) сузык икән, калган иҗекләрдәге сузыклар да алгы рәт сузыклары була яки киресенчә (мәс., *әбиләр*, *бабайлар*)

**ГАРМОНИЯ СОГЛАСНЫХ** ТАРТЫКЛАР ГАРМОНИЯСЕ Тартыкларның дистактлы ассимиляциясе

**ГЕНЕАЛОГИЧЕСКАЯ КЛАССИФИКАЦИЯ ЯЗЫКОВ** ТЕЛЛӘРНЕҢ ГЕНЕАЛОГИК КЛАССИФИКАЦИЯСЕ Чагыштырмача-тарихи метод ярдәмендә дәлилләнгән уртак тамырлар, формалар табылуга карап, телләрне кардәшлек ягыннан классларга бүлү

**ГЕНЕРАТИВНАЯ ЛИНГВИСТИКА** ГЕНЕРАТИВ ЛИНГВИСТИКА Лингвистикада телне билгеле бер типтагы формаль модельләр буларак тасвирлап бирү механизмнарын өйрәнә торган юнәлешләрнең берсе

**ГЕНЕРАТИВНЫЙ СИНТАКСИС** ГЕНЕРАТИВ СИНТАКСИС *к.* **структурный синтаксис**

**ГЕНЕТИЧЕСКАЯ ПАРАДИГМА** ГЕНЕТИК ПАРАДИГМА Уртак семантик билгеләргә ия сүзләрнең хронологик берләшүе

**ГЕНЕТИЧЕСКОЕ РОДСТВО ЯЗЫКОВ** ТЕЛЛӘРНЕҢ ГЕНЕТИК КАРДӘШЛЕГЕ Телләрнең килеп чыгу буенча кардәшлеге (беренче чиратта тамырлар уртаклыгы буенча билгеләнә)

**ГЕНИТИВ** ГЕНИТИВ *к.* **родительный падеж**

**ГЕОГРАФИЧЕСКАЯ ЛИНГВИСТИКА** ГЕОГРАФИК ЛИНГВИСТИКА *к.* **ареальная лингвистика**

**ГЕОГРАФИЯ ЯЗЫКОВАЯ** ТЕЛЛӘР ГЕОГРАФИЯСЕ Телнең географик таралышы

**ГЕРМАНИЗМ** ГЕРМАНИЗМ Герман телләреннән алынма

**ГЕРМАНИСТИКА** ГЕРМАНИСТИКА Герман телләре һәм әдәбиятлары турындагы фән

**ГЕРМАНСКИЕ ЯЗЫКИ** ГЕРМАН ТЕЛЛӘРЕ Һинд-европа телләре семьялыгының төньяк (швед, норвег, дат, исланд), көнбатыш (инглиз, алман, голланд, идиш), көнчыгыш (үле телләр: вестгот, остгот) төркемчәләре булган көнбатыш ареал төркеме

**ГЕРУНДИЙ** ГЕРУНДИЙ 1) Латин телендә -nd- суффикслы исем фигыль; 2) Инглиз телендә исем, фигыль билгеләре булган -ing ка беткән формалар

**ГЕРЦ** ГЕРЦ Бер секундта ясалган тирбәлешләр саны белән билгеләнгән тавыш югарылыгын үлчәү берәмлеге

**ГИДРОНИМ** ГИДРОНИМ Су һәм сулыкларның исеме

**ГИДРОНИМИЯ** ГИДРОНИМИЯ Топонимикада сулыкларның исемнәрен өйрәнә торган тармак

**ГИПЕРДИАЛЕКТИЗМ** ГИПЕРДИАЛЕКТИЗМ Сөйләмдә диалектизмнарны күп куллану күренеше

**ГИПЕРО-ГИПОНИМИЧЕСКАЯ (РОДО-ВИДОВАЯ) ПАРАДИГМА** ГИПЕР-ГИПОНИМИК (ГОМУМ-ТӨР) ПАРАДИГМА Сүзнең гомуми чыганагын һәм аерым төрен күрсәтә торган парадигма

**ГИПЕРОНИМ** ГИПЕРОНИМ Гипер-гипонимик мөнәсәбәтләрдә гомум мәгънәдәге, ыруг төшенчәсен белдерә торган сүз

**ГИПЕРСЕМА** ГИПЕРСЕМА Объектларның классын күрсәтә торган сема

**ГИПЕРТРОФИЯ ИНОСТРАННЫХ СЛОВ** ЧИТ ТЕЛ СҮЗЛӘРЕНЕҢ ГИПЕРТРОФИЯСЕ Чит телләрдән кергән сүзләрнең, формаларның артык күбәюе, теге яки бу телдә артык күп кулланылуы

**ГИПЕРУРБАНИЗМ** ГИПЕРУРБАНИЗМ Дөрес һәм матур сөйләм белән артык мавыгу

**ГИПОНИМ** ГИПОНИМ Гипер-гипонимик мөнәсәбәтләрдә төгәл төр мәгънәсен белдерә торган сүз

**ГИПОНИМИЯ** ГИПОНИМИЯ Лексикада системалы мөнәсәбәтләр төре; сүзләрнең «гомуми һәм хосусый» мәгънәдә бәйләнеше, чынбарлыктагы предметлар, күренешләр арасындагы ыруг-төр мөнәсәбәтләренең чагылышы

**ГИПОСЕМА** ГИПОСЕМА Конкрет характердагы, предмет-хәрәкәтнең дифференциаль билгеләрен белдерә, шул рәвешчә бер класска караган предметларны бер-берсеннән аерып күрсәтә торган сема

**ГИПОСТАЗИС** ГИПОСТАЗИС Бер сүз төркеменең икенчесенә конверсия (киң мәгънәсендә) буенча күчеше

**ГИПОТАКСИС** ГИПОТАКСИС Җөмләләрнең берсе икенчесенә ияртү юлы белән кушылулары

**ГЛАВНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** БАШ ҖӨМЛӘ Иярченле, катнаш, катлаулы кушма җөмләләрнең бәйсез предикатив өлеше; башка кисәкләр синтаксик яктан аңа бәйле була

**ГЛАВНОЕ УДАРЕНИЕ** ТӨП БАСЫМ Кушма сүзләрдә бер нигезне мәгънәви һәм ритмик яктан аера торган басым

**ГЛАВНЫЕ ЧЛЕНЫ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘНЕҢ БАШ КИСӘКЛӘРЕ Ике составлы җөмләнең нигезен тәшкил итә, үзара предикатив мөнәсәбәттә торган җөмлә кисәкләре: җөмләнең иясе һәм хәбәре

**ГЛАГОЛ** ФИГЫЛЬ Лексик-семантик яктан эш, хәл, хәрәкәтне үтәлү, процессында белдерә, морфологик яктан барлык-юклык, юнәлеш, дәрәҗә, наклонение, зат-сан, заман белән төрләнә, синтаксик яктан җөмләдә, нигездә, хәбәр булып килә торган сүз төркеме

**ГЛАГОЛИЦА** ГЛАГОЛИЦА Алфавит составы хәрефләрнең урнашу тәртибе, авазларны белдерүе белән кириллицага бөтенләй диярлек тәңгәл килгән, әмма хәрефләрнең формасы белән аерылып торган әлифба; X–XI йөзләрдә иске славян язуындагы иң беренче иске әлифбаның берсе

**ГЛАГОЛЬНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ФИГЫЛЬ ҖӨМЛӘ Баш кисәге фигыль белән белдерелгән бер составлы җөмлә

**ГЛАГОЛЬНОЕ СКАЗУЕМОЕ** ФИГЫЛЬ ХӘБӘР Фигыль белән белдерелгән хәбәр

**ГЛАГОЛЫ В ЛИЧНОЙ ФОРМЕ** ЗАТЛАНЫШЛЫ ФИГЫЛЬЛӘР Зат белән төрләнә торган фигыльләр: хикәя, боерык, шарт, теләк фигыльләр

**ГЛАГОЛЬНЫЕ СЛОВА** ФИГЫЛЬЛЕКЛЕ СҮЗЛӘР Заманга бәйләнешле эшне, хәлне аңлата торган сүзләр

**ГЛАСНЫЕ ЗВУКИ** СУЗЫК АВАЗЛАР Акустик яктан бары тавыштан гына торган, әйткән вакытта һава агымы сөйләм аппараты аша тоткарлыксыз гына үтеп китеп ясала торган, иҗек төзи ала торган авазлар

**ГЛАСНЫЕ ВЕРХНЕГО ПОДЪЕМА** ЮГАРЫ КҮТӘРЕЛЕШЛЕ СУЗЫКЛАР Артикуляцияләре вакытында тел авыз куышлыгында иң өске урынны алып, йомшак аңкауга таба күтәрелгәндә ясалган сузыклар

**ГЛАСНЫЕ ЗАДНЕГО РЯДА** АРТКЫ РӘТ СУЗЫКЛАР Авыз куышлыгының арткы өлешендә ясала торган сузыклар; калын сузыклар (мәс., [*а*], [*у*], [*о*])

**ГЛАСНЫЕ НИЖНЕГО ПОДЪЕМА** ТҮБӘН КҮТӘРЕЛЕШЛЕ СУЗЫКЛАР Артикуляцияләре вакытында аскы казналык бик аска төшеп ясалган сузыклар

**ГЛАСНЫЕ ПЕРЕДНЕГО РЯДА** АЛГЫ РӘТ СУЗЫКЛАРЫ Авыз куышлыгының алгы өлешендә ясала торган сузыклар; нечкә сузыклар (мәс., [*ә*], [*ү*], [*ө*])

**ГЛАСНЫЕ СРЕДНЕГО ПОДЪЕМА** УРТА КҮТӘРЕЛЕШЛЕ СУЗЫКЛАР Артикуляцияләре вакытында аскы казналык уртача позициядә булганда ясалган сузыклар

**ГЛАСНЫЕ СРЕДНЕГО РЯДА** УРТА РӘТ СУЗЫКЛАРЫ Тел авыз куышлыгының уртасындарак торганда ясала торган сузыклар (мәс., рус телендәге [*а*], [*ы*])

**ГЛОССА** ГЛОССА Аңлашылмаган, искергән, диалекталь сүз яки әйтелмәнең аның өстендә яисә кулъязма, китап поляларында бирелгән тәрҗемәсе я аңлатмасы

**ГЛОССАРИЙ** ГЛОССАРИЙ *к.* **словарь**

**ГЛОССЕМАНТИКА** ГЛОССЕМАНТИКА Телне реаль мәгънәләрдән һәм реаль яңгырашлардан бәйсез булган мөнәсәбәтләр системасы буларак кына карый торган лингвистик теория; структурализмның бер юнәлеше

**ГЛОТОЧНЫЙ СОГЛАСНЫЙ** ЙОТКЫЛЫК ТАРТЫГЫ Йоткылык стеналары тараеп, шул ярыктан һава өрелеп чыгу юлы белән ясала торган тартыклар (мәс., [*h*]); *к.* **фарингальный согласный**

**ГЛОТТОХРОНОЛОГИЯ** ГЛОТТОХРОНОЛОГИЯ Телдәге үзгәрешләрнең тизлеген өйрәнә торган чагыштырма-тарихи тел белеме өлкәсе

**ГЛУБОКО ЗАДНЕЯЗЫЧНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ТИРӘН ТЕЛ АРТЫ ТАРТЫКЛАРЫ Кече тел катнашында ясала торган тартыклар (мәс., [*ғ*], [*ķ*]); *к.* **увулярные согласные**

**ГЛУХИЕ СОГЛАСНЫЕ** САҢГЫРАУ ТАРТЫКЛАР Артикуляцияләре вакытында тавыш ярылары хәрәкәтләнми һәм шуңа тавыштан башка, шау ярдәмендә генә әйтелә торган тартык авазлар (мәс., [*п*], [*ф*], [*к*])

**ГНЕЗДО СЛОВ** СҮЗЛӘР ОЯСЫ Бер төркемгә тупланган тамырдаш сүзләр

**ГОВОР** СӨЙЛӘШ Халык теленең зур булмаган территориядә таралган төре, диалектның бер өлеше (мәс., Казан арты сөйләше, Минзәлә сөйләше)

**ГОЛОС** ТАВЫШ Сөйләшкәндә, җырлаганда, кычкырганда һава агымы басымы белән киеренке хәлдәге тавыш ярылары калтыравы белән барлыкка килә торган аваз

**ГОЛОСОВЫЕ СВЯЗКИ** ТАВЫШ ЯРЫЛАРЫ Үпкәдән килә торган һава агымы тәэсирендә тибрәнеп, сузык авазлар һәм яңгырау тартыкларны ясау өчен кирәкле тавыш (тон) хасил итә торган актив сөйләм органы

**ГОРТАННЫЕ СОГЛАСНЫЕ** БУГАЗ ТАРТЫКЛАРЫ Бугазда тавыш ярыларының йомылуы һәм кисәк ачылып китүе нәтиҗәсендә ясала торган тартык авазлар; ларингаль тартыклар (мәс., татар телендә - һәмзә [ʔ] тартыгы)

**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ЯЗЫК** ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ Билгеле бер дәүләттә закон нигезендә сөйләшү-аралашу чарасы һәм рәсми тел буларак кабул ителгән тел

**ГРАММАТИКА** ГРАММАТИКА 1) Телнең төзелеше, ягъни морфологик категорияләр һәм формалар, синтаксик категорияләр һәм конструкцияләр, сүз ясалу ысуллары системасы; 2) Тел гыйлеменең сүз һәм җөмлә төзелешен өйрәнә торган тармагы; морфология, сүзьясалышы һәм синтаксис бүлекләреннән тора

**ГРАММАТИКО-СЕМАНТИЧЕСКИЕ КАТЕГОРИИ СЛОВ** СҮЗЛӘРНЕҢ ГРАММАТИК-СЕМАНТИК КАТЕГОРИЯЛӘРЕ *к.* **части речи**

**ГРАММАТИЧЕСКАЯ АБСТРАКЦИЯ** ГРАММАТИК АБСТРАКЦИЯ Лексик эчтәлектән читкә китеп, грамматик билгеләрне һәм мөнәсәбәтләрне аерып күрсәтү

**ГРАММАТИЧЕСКАЯ АНАЛОГИЯ** ГРАММАТИК АНАЛОГИЯ Бер сүзнең формасын икенче сүз формасына охшатып ясау

**ГРАММАТИЧЕСКАЯ КАТЕГОРИЯ** ГРАММАТИК КАТЕГОРИЯ Грамматик мәгънә һәм грамматик форма берлеге; бертөрле грамматик мәгънәләр җыелмасы (заман, зат, сан, род, тартым, килеш һ.б.)

**ГРАММАТИЧЕСКАЯ СТИЛИСТИКА** ГРАММАТИК СТИЛИСТИКА Синтаксик конструкцияләрнең стилистик мөмкинлекләре, телнең грамматик чараларын сөйләмдә максатка ярашлы итеп сайлау турындагы өйрәтмә

**ГРАММАТИЧЕСКАЯ ФОРМА СЛОВА** СҮЗНЕҢ ГРАММАТИК ФОРМАСЫ Морфологик чара ярдәмендә ясалган сүз формасы; грамматик мәгънә белән грамматик чара берлеге

**ГРАММАТИЧЕСКИЕ ЕДИНИЦЫ** ГРАММАТИК БЕРӘМЛЕКЛӘР Гомумиләштерелгән грамматик билгеләрне йөртүче буларак сүз, сүз формасы, синтаксик конструкцияләр шулай ук ярдәмче морфемалар һәм аларның җыелмасы, ярдәмче сүзләр

**ГРАММАТИЧЕСКИЕ ОМОНИМЫ** ГРАММАТИК ОМОНИМНАР *к.* **омоформы**

**ГРАММАТИЧЕСКИЕ СИНОНИМЫ** ГРАММАТИК СИНОНИМНАР Мәгънәләре тәңгәл яки якын булган, бәйләүче чаралары белән аерылып торган синонимнар (мәс., *буран булганга – буран булу сәбәпле – буран аркасында*)

**ГРАММАТИЧЕСКИЙ СТРОЙ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ ГРАММАТИК ТӨЗЕЛЕШЕ Билгеле бер телгә хас сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләр төзелеше

**ГРАММАТИЧЕСКИЙ ЭЛЕМЕНТ** ГРАММАТИК ЭЛЕМЕНТ *к.* **аффикс**

**ГРАММАТИЧЕСКОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ГРАММАТИК МӘГЪНӘ Сүзнең лексик мәгънәсенә бәйле булмаган, җөмләдә сүзләр арасында төрле мөнәсәбәтләрне белдерә торган мәгънә

**ГРАММАТИЧЕСКОЕ СРЕДСТВО** ГРАММАТИК ЧАРА Грамматик мәгънә белдерә торган тел чаралары: аффиксация, кабатлаулар, басым, сүз тәртибе һ.б.

**ГРАММЕМА** ГРАММЕМА Мәгънәсе буенча ыруг мәгънәсендәге грамматик категориягә карата төр төшенчәсен белдергән грамматик категория компоненты (мәс., берлек һәм күплек сан граммемалары)

**ГРАФЕМА** ГРАФЕМА Авазның язмасы, графикасы; авазның язылма-күрелмә билгесе

**ГРАФИКА** ГРАФИКА 1) Нинди дә булса телнең язу чаралары (графемалар, тыныш билгеләре, басымнар һ.б.) җыелмасы; 2) Авазлар һәм хәрефләр арасындагы мөнәсәбәтләрне өйрәнә торган тел гыйлеме бүлеге

**ГРАФИЧЕСКИЙ ПРИНЦИП** ГРАФИК ПРИНЦИП Алынма сүзләрнең тамыр һәм нигез өлешләрен чыганак телдәгечә язуга нигезләнгән орфографик принцип

**ГРАФИЧЕСКОЕ ИЗОБРАЖЕНИЕ ЗВУКА** АВАЗНЫҢ ГРАФИК БИЛГЕСЕ Теге яки бу авазның шартлы билгесе, символы; язу стиленә, сүздәге урынына бәйле рәвештә төрле вариантларда булырга мөмкин (мәс., бер авазның баш, юл, курсив һ.б. вариантлардагы графикасы)

**ГРУППА** ГРУППА, ТӨРКЕМ 1) Сөйләмнең фонетик, синтаксик, семантик яссылыкларда таркату берәмлеге; 2) Тел берәмлекләрен семантик, структур, этимологик яктан берләштерү, туплау берәмлеге; 3) Телләрнең, диалектларның генетик, типологик һ.б. яктан бергәлеге

**ГУБНАЯ ГАРМОНИЯ** ИРЕН ГАРМОНИЯСЕ *к.* **сингармонизм**

**ГУБНО-ГУБНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ИРЕН-ИРЕН ТАРТЫКЛАРЫ Аскы һәм өске иреннәрнең бер-берсенә тиюе яки якынаюы белән ясала торган тартык авазлар (мәс., [*б*], [*п*], [*м*], [*w*])

**ГУБНО-ЗУБНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ИРЕН-ТЕШ ТАРТЫКЛАРЫ Аскы ирен белән өске кискеч тешләрнең бер-берсенә якынаюы белән ясала торган тартыклар; *к.* **лабиадентальные согласные** (мәс, [*в*], [*ф*])

**ГУБНЫЕ ГЛАСНЫЕ** ИРЕНЛӘШКӘН СУЗЫКЛАР *к.* **лабиализованные гласные**

**ГУБНЫЕ ЗВУКИ** ИРЕНЛӘШКӘН АВАЗЛАР *к.* **лабиализованные звуки**

# Д

**ДАВНОПРОШЕДШЕЕ ВРЕМЯ** КҮПТӘН ҮТКӘН ЗАМАН; ПЛЮСКВАМПЕРФЕКТ Сөйләү моменты белән бәйләнешле үткәннән алда булган, төгәлләнгән яки икенче бер эшкә кадәр башкарылган эш-хәлләрне белдергән фигыль формасы (татар телендә грамматик күрсәткече *-ган* кушымчасы һәм *иде* ярдәмлек фигыле: *килгән иде, кайткан иде, уйлаган иде*)

**ДАЛЬНЕВОСТОЧНЫЙ ЯЗЫКОВОЙ СОЮЗ** ЕРАК КӨНЧЫГЫШ ТЕЛ БЕРЛЕГЕ Төрле системага караган кытай, япон, бирма, таити, вьетнам телләре берлеге; *к.* **языковой союз**

**ДАЛЯ ЗАКОН** ДАЛЬ ЗАКОНЫ Беренче булып Э. Даль тарафыннан күрсәтелгән, банту телләренең күбесенә хас булган ике янәшә иҗекләрдәге тартык авазларның диссимиляциясе күренеше

**ДАТЕЛЬНЫЙ ПАДЕЖ** ДАТИВ Җөмләдә исемнең башка сүзләргә субъект һәм объект мөнәсәбәтен белдерә торган килеш формасы (мәс., *сыну 20 лет, студентам весело, верить другу, передать брату* һ.б.)

**ДВАНДВА** ДВАНДВА Компонентлары арасында тезүле бәйләнеш булган кушма сүз (мәс., *егет-җилән, кыз-кыркын* һ.б.)

**ДВОЕТОЧИЕ** ИКЕ НОКТА Тиңдәш кисәкләрне берләштергән гомумиләштерүче сүзне аерып, бәйләү чарасы интонация булган кушма җөмләләрдә баш җөмләне аерып, туры сөйләм алдыннан автор сөйләмен аерып куела торган тыныш билгесе (:)

**ДВОЙСТВЕННОЕ ЧИСЛО** ИКЕЛЕК САНЫ Кайбер телләрдә ике предметның бердәмлеген, парлы булуын белдерә торган грамматик форма (мәс., *гарәп, борынгы славян телендә*)

**ДВУВИДОВЫЕ ГЛАГОЛЫ** ИКЕ ВИДЛЫ ФИГЫЛЬЛӘР Рус теленә хас совершенный һәм несовершенный видларның мәгънәләрен үзендә берьюлы туплаган, контекст эчендә генә аеру мөмкин булган фигыльләр (мәс., *казнить, исследовать, обещать* һ.б.)

**ДВУЗНАЧНОСТЬ** ИКЕМӘГЪНӘЛЕЛЕК Сүзнең яки фразаның ике төрле мәгънәгә ия булуы

**ДВУСОСТАВНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ИКЕ СОСТАВЛЫ ҖӨМЛӘ Ике баш кисәге дә – субъекты һәм предикаты аерым сүзләр белән белдерелгән җөмлә (мәс., *җил көньякка авышты; алмагачлар чәчәк атты* һ.б.)

**ДВУХФОКУСНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ИКЕ ФОКУСЛЫ ТАРТЫКЛАР Әйткәндә үпкәдән килгән һава агымы ике урында тоткарлыкка очрап ясала торган тартыклар (мәс., *ш* авазын әйткәндә телнең очында һәм телнең арткы өлешендә һава агымына тоткарлык ясала)

**ДВУЯЗЫЧИЕ** ИКЕТЕЛЛЕЛЕК, БИЛИНГВИЗМ 1) Төрле системадагы (кардәш һәм кардәш булмаган) ике телне берьюлы яхшы белү һәм шул ике телдә дә яхшы сөйләшү; 2) Бер үк халыкның төрле семьялыкларга караган (кардәш һәм кардәш булмаган) ике телдән дә тигез дәрәҗәдә берьюлы файдалану күренеше

**ДЕВАНАГАРИ** ДЕВАНАГАРИ Күбесенчә индус буддистлар куллана торган иске һинд язуы

**ДЕЕПРИЧАСТИЕ** ХӘЛ ФИГЫЛЬ Фигыль һәм рәвеш билгеләренә ия булган затланышсыз фигыль формасы (мәс., татар телендә 4 төрле кушымча белән ясалган төре бар: 1) *-ып/-еп; шаулап, җилкенеп;* 2) *-а/-ә, -ый/-и; кайта-китә, барышлый;* 3) *-гач/-гәч, -кач/-кәч; яктыргач, күргәч;* 4) *-ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче; талганчы, әйткәнче, язганчы*)

**ДЕЕПРИЧАСТНЫЙ ОБОРОТ** ХӘЛ ФИГЫЛЬ ӘЙЛӘНМӘСЕ Җөмлә эчендә баш кисәге хәл фигыль формасында булган аерымланган ярымпредикат әйләнмә

**ДЕЙКСИС** ДЕЙКСИС Күбесенчә алмашлыкларга хас булган лексик яки грамматик чаралар ярдәмендә белдерелә торган тел берәмлекләренең күрсәтү функциясе яки мәгънәсе

**ДЕЙКТИЧЕСКОЕ МЕСТОИМЕНИЕ** ДЕЙКТИК АЛМАШЛЫК. *к.* **указательное местоимение**

**ДЕЙСТВИТЕЛЬНЫЙ ЗАЛОГ** ТӨП ЮНӘЛЕШ Эш-хәл, процессның субъект тарафыннан башкарылуын күрсәтә торган,

юнәлеш категориясенә кагылышлы өстәмә кушымча алмаган фигыль формасы (мәс., *сөйли, пешерә, укый* һ.б.)

**ДЕЛАБИАЛИЗАЦИЯ** ДЕЛАБИАЛИЗАЦИЯ Иренләшү югалу, аваз артикуляциясендә иреннәр катнашмый башлау

**ДЕЛАТИВ** ДЕЛАТИВ Һинд-европа группасына карамаган телләрдә нинди дә булса ноктадан түбәнгә таба хәрәкәтне белдерә торган килеш формасы

**ДЕЛОВАЯ ЛЕКСИКА** ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕ ЛЕКСИКАСЫ Рәсми эш кәгазьләре – дәүләт актларында – законнар, боерыклар, килешүләр, устав, административ-канцелярия документлары, рәсми язма аралашу текстларында кулланыла торган лексика

**ДЕМАРКАЦИЯ** ДЕМАРКАЦИЯ Иҗек аеру өчен кулланыла торган фонетик чара тамгасы

**ДЕМИНУТИВ** ДЕМИНУТИВ Сүзнең кечерәйтү-иркәләү формасы (мәс., *флажок, ручка, йолдызчык*)

**ДЕНОТАТ, ДЕНОТАТИВНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ДЕНОТАТ, ДЕНОТАТИВ МӘГЪНӘ Бер сериядәге предметларны гомумиләштереп, типик күзаллап белдерелә торган конкрет төшенчә, аңдагы сүзнең предметка тәңгәл килгән гомуми образын белдергән мәгънәсе

**ДЕНОТАЦИЯ** ДЕНОТАЦИЯ Коннотациядән аермалы буларак, тел берәмлегенең өстәмә мәгънәләреннән тыш, сүзнең үз эчтәлегенә салынган беренчел төп мәгънәсе

**ДЕНТАЛИЗАЦИЯ** ДЕНТАЛИЗАЦИЯ Тартык авазлар артикуляциясендә теш катнашу барлыкка килү (мәс., ассимиляция нәтиҗәсендә)

**ДЕНТО-ЛАБИАЛЬНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ИРЕН-ТЕШ ТАРТЫКЛАРЫ *к.* **лабиадентальные согласные**

**ДЕРИВАТ** ДЕРИВАТ Ясалма сүз

**ДЕРИВАТОР** ДЕРИВАТОР Сүз ясау чаралары элементы

**ДЕРИВАЦИОННОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ДЕРИВАЦИОН МӘГЪНӘ Өстәмә билгеләрне белдерә торган сүзьясагыч аффиксларның мәгънәләре

**ДЕРИВАЦИОННЫЕ МОРФЕМЫ** ДЕРИВАЦИОН МОРФЕМАЛАР Тамыр морфемаларга ялганып, аның нигезенә салынган мәгънәне киңәйтеп, яңа сүз барлыкка китерә, телдә мөстәкыйль кулланылмый торган морфемалар – сүзьясагыч кушымчалар

**ДЕРИВАЦИЯ** ДЕРИВАЦИЯ Аерым телгә хас булган сүзьясагыч чаралар ярдәмендә, сүз ясалыш модельләренә нигезләнеп яңа сүзләр ясау

**ДЕСЕМАНТИЗАЦИЯ** ДЕСЕМАНТИЗАЦИЯ Сүзнең эчтәлегенә салынган мәгънәсе югалу күренеше (мәс., *эшләп йөри, яшәп ята, укып бара* тезмә фигыльләрендә *йөри, ята, бара* фигыльләренең төп лексик мәгънәсе югалып, ярдәмче фигыльгә күчүе)

**ДЕСИГНАТ** ДЕСИГНАТ Тел берәмлегенең эчке эчтәлек ягы белдергән чынбарлыкның аңдагы чагылышы (нинди дә булса предмет, күренеш яки вакыйга һ.б.)

**ДЕСКРИПТИВНАЯ ЛИНГВИСТИКА** ДЕСКРИПТИВ ЛИНГВИСТИКА, ТАСВИРЛАМА ТЕЛ БЕЛЕМЕ Фактларны регистрацияләүгә нигезләнгән, тел структурасының формаль элементлары мәгънәләрен ачыклауны максат итеп куймаган тасвири лингвистика – структурализмның бер төре (XX гасырның 30–50 елларында язулары да булмаган Америка индеецларының телләрен өйрәнү процессында барлыкка килә; тарафдары – Л. Блумфилд)

**ДЕТЕРМИНАН**Т ДЕТЕРМИНАНТ Аерым бер җөмлә кисәгенә карамыйча, бөтен җөмлә составына караган һәм аны җәенкеләндерә торган ачыклагыч кисәк

**ДЕТЕРМИНАТИВ** ДЕТЕРМИНАТИВ 1) Сүзнең нигезен барлыкка китерә торган элемент; 2) Аерым бер семантик кырга караган беренчел мәгънәсе булган иероглиф элементы; хәзерге вакытта мәгънәсен өлешчә генә саклаган булырга да мөмкин

**ДЕТЕРМИНАЦИЯ** ДЕТЕРМИНАЦИЯ Глоссематикада: ике формаль-логик функция башкарган кисәкләр арасындагы берсен икенчесе ачыклаган мөнәсәбәт; синтаксик бәйлелеге киресенчә булмаган бер җөмлә кисәгенең икенчесенә ачыклау күренеше

**ДЕФИС** ДЕФИС, СЫЗЫКЧА Парлы сүзләрнең компонентлары һәм сүз белән кисәкчә арасында куела торган кечкенә сызыкча (мәс., *кайта-китә, яши-яши, ап-ак* һ.б.)

**ДЕШИФРОВКА** ДЕШИФРОВКА Дөньядагы бөтен телләргә хас уртак закончалыкларга нигезләнеп, билгесез язу белән язылган текстны укый алуга ирешү

**ДЕЦИБЕЛ** ДЕЦИБЕЛ Экспериментал фонетикада: аваз көчен үлчәү берәмлеге; *дц*

**ДЕЭТИМОЛОГИЗАЦИЯ** ДЕЭТИМОЛОГИЗАЦИЯ Телдә сүзнең мотивлаштыргыч нигезе аңлашылмый башлау, мәгънәсе онытып югалу, мотивлаштыручы сүз белән мотивлашкан сүз арасында бәйләнеш өзелү сәбәпле морфемаларга таркала торган сүзнең таркалмый торганга әйләнүе нәтиҗәсендә этимологиясе ачык күренмәү күренеше

**ДИАКРИТИЧЕСКИЙ ЗНАК** ДИАКРИТИК ТАМГА Транскрипциядә: хәрефнең берәр үзенчәлек белән укылырга тиешлеген күрсәтеп куела торган тамга (мәс., *ā, č, ӱ*)

**ДИАЛЕКТ** ДИАЛЕКТ Гомумхалык теленең аерым бер төбәктә яшәүче халыкларына хас булган, шул төбәк сөйләмендә кулланылган үзенчәлекле өлеше (мәс., татар телендә *көнчыгыш, көнбатыш, урта диалектлар*)

**ДИАЛЕКТАЛЬНЫЙ** ДИАЛЕКТАЛЬ, ДИАЛЕКТЛАРГА КАРАГАН Диалектизмнардан торган, диалектларга караган (диалекталь сүз, диалекталь күренеш)

**ДИАЛЕКТИЗМ** ДИАЛЕКТИЗМ Аерым диалектларда гына очрый торган, әдәби тел нормаларына сыешмаган сүзләр һәм фонетик, морфологик, синтаксик үзенчәлекләр

**ДИАЛЕКТОЛОГИЧЕСКИЙ АТЛАС** ДИАЛЕКТОЛОГИК АТЛАС Аерым телдәге диалектизмнарның географик таралышын күрсәтә торган диалектологик карталарның системалаштырылган җыелмасы

**ДИАЛЕКТОЛОГИЯ** ДИАЛЕКТОЛОГИЯ Тел гыйлеменең бер тармагы буларак җирле сөйләшләрдәге тел үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән

**ДИАЛОГ** ДИАЛОГ Туры сөйләмнең бер төре; ике яки берничә кешенең үзара кара-каршы сөйләшүе

**ДИАЛОГИЗМ** ДИАЛОГИЗМ Диалогка хас булган үзенчәлекле сөйләм төзелеше яки сүз, әйләнмә

**ДИАПАЗОН** ДИАПАЗОН Аерым бер лингвистик күренешнең таралышы, аның функциональ киңлеге

**ДИАФОРА** ДИАФОРА Стилистик фигура: кечкенә генә контекст эчендә бер үк сүзнең яки сүзтезмәнең төрле мәгънәләрдә кабатлануы

**ДИАХРОНИЯ** ДИАХРОНИЯ Лингвистик тикшеренү объекты буларак тел күренешләре үсешендәге тарихи эзлеклелек һәм тел системасының тулаем үсеше

**ДИВЕРГЕНТЫ** ДИВЕРГЕНТЛАР Янындагы авазларга бәйле рәвештә төрле яңгыраштa әйтелә торган сөйләм авазлары – фонема вариантлары (мәс., *бул – бүл; ур – үр* нечкә һәм калын сузыклар янында килгән бер үк тартык авазларның әйтелеш вариантлары)

**ДИВЕРГЕНЦИЯ** ДИВЕРГЕНЦИЯ 1) Янындагы авазларга бәйле рәвештә сөйләм авазларының яңгырашы үзгәрү күренеше. *к.* **дивергенты**; 2) Телнең тарихи үсеше барышында бер фонеманың ике мөстәкыйль фонемага бүленүе (мәс., татар телендә *к – къ);* 3) Бер телдән шул гомуми телнең үзенчәлекләрен саклаган ике яки берничә кардәш тел барлыкка килү яки бер телнең диалектлары, бер-берсеннән ераклашып, мөстәкыйль телләргә әверелүе

**ДИГЛОССИЯ** ДИГЛОССИЯ Бер тел эчендә төрле катламнарның (әдәби тел һәм диалектлар) үзара мөнәсәбәте

**ДИЕРЕЗА** ДИЕРЕЗА Ассимиляция яки диссимиляция нәтиҗәсендә берәр аваз яки иҗекнең төшеп калу күренеше

**ДИНАМИКА** ДИНАМИКА Тел күренешләрен алдагы чор күренешләре белән, шул кардәш төркемгә караган башка телләрдә чагыштырып карау, телнең үсеше; *киресе*: **статика**

**ДИНАМИЧЕСКОЕ УДАРЕНИЕ** ДИНАМИК БАСЫМ Артикуляциянең киеренкелеге белән аерылып торган көчле тын белән әйтелгән иҗек

**ДИСИЛЛАБ** ДИСИЛЛАБ Ике иҗектән торган сүз

**ДИССИМИЛЯЦИЯ** ДИССИМИЛЯЦИЯ Ике бертөрле яки охшаш авазларның берсен охшаш булмаган икенче аваз белән алыштыру күренеше; күбесенчә җанлы сөйләм өчен хас (мәс., *шешә – чешә, шашкан – чашкан, трамвай – транвай һ.б.*)

**ДИСТАКТНАЯ АССИМИЛЯЦИЯ** ДИСТАКТЛЫ АССИМИЛЯЦИЯ Сүзләрдәге тәэсир итешкән авазларның бер-берсеннән башка авазлар белән аерылган хәлдәге ассимиляциясе (мәс., *алып бир – аппир, чишмә – шишмә*)

**ДИСТРИБУТИВНЫЙ АНАЛИЗ** ДИСТРИБУТИВ АНАЛИЗ Сөйләм агымының эксперименталь техника ярдәмендә телнең төрле дәрәҗәдәге (фонетик, морфологик, лексик, синтаксик) кисәкләренә бүленеше

**ДИСТРИБУЦИЯ ФОНЕМ** ФОНЕМАЛАР ДИСТРИБУЦИЯСЕ Фонемаларның чолганышы, фонемаларның бергә килә алу закончалыклары

**ДИСФЕМИЗМ** ДИСФЕМИЗМ Стилистик нейтраль сүзне тупас сүз белән алмаштырып, эмоциональ бәяне кискен формада белдерү; *киресе*: **эвфемизм**

**ДИФТОНГ** ДИФТОНГ Бер иҗектә рәттән ике сузык аваз килеп, авазлар системасында бер бөтен кушма берәмлек барлыкка китерү күренеше (чын дифтонглар мәс. немец телендә – *au, ai, eu*; ялган дифтонглар, мәс. татар телендә сузык аваз белән *[й]* һәм *[w]* тартыкларының кушылмалары: беренче тартык авазлар килгәндә *күтәрелмә дифтонглар*, мәс. *йа, йу, wa,* беренче сузык авазлар килгәндә *төшерелмә дифтонглар*, мәс. *ай, уй, аw*)

**ДИФТОНГОИД** ДИФТОНГОИД Дифтонгка охшаган сузыклар (мәс., рус телендә *о* авазы алдан *у* авазын әйткәндәге кебек башланып китә)

**ДИФФЕРЕНЦИАЛЬНЫЙ ПРИЗНАК** ДИФФЕРЕНЦИАЛЬ БИЛГЕ Аера торган билге – фонеманы башкаларына каршы куя, башкалардан аерып тора торган билгесе (мәс., яңгыраулык-саңгыраулык, озынлык-кыскалык, өрелмәлек-йомыклык һ.б.)

**ДИХОТОМИЧЕСКАЯ ФОНОЛОГИЯ** ДИХОТОМИК ФОНОЛОГИЯ Р.О. Якобсон, Г. Фант, М. Халле тарафыннан бар-

лыкка китерелгән, төрле фонологик системаларны чагыштырып, фонемаларны универсаль үлчәү системасы

**ДИХОТОМИЧЕСКАЯ СИСТЕМА ФОНОЛОГИЧЕСКИХ ИЗМЕРЕНИЙ** ФОНОЛОГИК ҮЛЧӘМНЕҢ ДИХОТОМИК СИСТЕМАСЫ Төрле фонологик системаларда фонемаларны үлчәү билгеләре җыелмасы (вокальлек яки тонның булу, булмавы, консонантлык, көчәнеш, яңгыраулык яки саңгыраулык, озынлык, борын, бугаз, тел, тешләр, иреннәр катнашу яки катнашмау, тавышның түбәнлеге яки югарылыгы һ.б.; Р.О. Якобсон тарафыннан бу билгеләр 16 җиткерелгән)

**ДЛИТЕЛЬНОСТЬ** ОЗЫНЛЫК Авазның яңгырау вакыты (фонетикада миллисекундлар *мс* белән үлчәнә)

**ДОБАВОЧНЫЕ ЗНАЧЕНИЯ** ӨСТӘМӘ МӘГЪНӘЛӘР Сүзнең өстәмә мәгънәсе, аның семантик һәм стилистик төсмерләре; *к.* **коннотация**

**ДОЛГИЕ ГЛАСНЫЕ** ОЗЫН СУЗЫКЛАР Артикуляцияләре бердәй, бер-берсеннән бары яңгырау вакытлары белән генә аерыла торган сузыклар (кайбер телләрдә – мәс., *инглиз, немец* – фонематик роль башкаралар)

**ДОЛГИЕ СОГЛАСНЫЕ** ОЗЫН ТАРТЫКЛАР Башка тартыклардан озынрак әйтелеше белән аерылган тартыклар (мәс., рус телендәге *щ* тартыгы *ш* тартыгыннан озынрак әйтелеше белән аерыла)

**ДОМИНАНТА** ДОМИНАНТА Сүзнең атау һәм гомумиләштерү функциясе булган, барлык мәгънә төсмерләрен дә берләштерергә сәләтле нигезенә салынган туры мәгънәсе; синонимик рәттә уртак төшенчә белдерә һәм шул рәттәге барлык сүзләрне дә алмаштырып килә ала торган төп сүз

**ДОПОЛНЕНИЕ** ТӘМАМЛЫК Җөмләнең процесс белдергән кисәгенә ияреп, эш яки хәлнең объектын билгели торган иярчен кисәге; *к.* **прямое дополнение** и **косвенное дополнение**

**ДРОЖАЩИЙ СОГЛАСНЫЙ** КАЛТЫРАУЛЫ ТАРТЫК Әйткән вакытта берәр сөйләм органы (иреннәр, кече тел һ.б.) калтыравы белән ясала торган аваз (мәс., *р* авазы тел очының калтыравы белән ясала)

**ДУБЛЕТЫ** ДУБЛЕТЛАР 1) Телдә төрле чорларда барлыкка килгән, мәгънәләре белән төгәл яки якынча бер-берсен кабатлаган сүзләр; 2) Аерым тел берәмлегенең фонетик, морфологик, синтаксик, стилистик вариантлары

**ДУРАТИВНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ДУРАТИВ МӘГЪНӘ Эш-хәлнең дәвамлы булуын белдерә торган мәгънә

# Е

**ЕГИПЕТСКИЕ ЯЗЫКИ** МИСЫР ТЕЛЛӘРЕ Үле борынгы мисыр, копт телләрен берләштергән Африка-Азия телләре төркеме

**ЕДИНИЧНОЕ ЗНАЧЕНИЕ СЛОВА** Сүзнең билгеле бер чорда гына аңлаткан мәгънәсе (мәс., *кызыллар, аклар, продналог*)

**ЕДИНИЦЫ ЯЗЫКА** ТЕЛ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ Төрле функцияләрне башкара торган һәм төрле мәгънәләре булган тел системасы берәмлекләре

**ЕДИНСТВЕННОЕ ЧИСЛО** БЕРЛЕК САН Исемнәрдә предметның берлеген, фигыльдә процессны үтәүченең берәү генә булуын белдергән грамматик сан категориясе формасы: исемнәрдә ноль грамматик күрсәткече, фигыльдә зат кушымчалары ярдәмендә белдерелә

**ЕКАНЬЕ** ЕЛАШТЫРУ Татар теленең диалектларында [*җ*] урынына [*е*] авазын кулланып сөйләшү

**ЕНИСЕЙСКИЕ ЯЗЫКИ** ЕНИСЕЙ ТЕЛЛӘРЕ Енисей елгасы һәм аның кушылдыклары кергән территорияләрдә таралган телләр (мәс., кет, сым, шулай ук үле котт, ассан телләре)

**ЕСТЕСТВЕННЫЙ ЯЗЫК** ТАБИГЫЙ ТЕЛ Җәмгыятьтә күп буыннар аралашу нәтиҗәсендә формалашкан, фикерләү, мәгълүмат алышу чарасы буларак кулланыла торган һәм ясалма телләргә капма-каршы куелган тел

# Ж

**ЖАРГОН** ЖАРГОН Сөйләм теленең уртак ихтыяҗлары булган яки бер үк шөгыльдәге яисә бер үк социаль төркем кешеләре куллана торган бер төре (мәс., укучылар жаргоны, караклар жаргоны, яшьләр жаргоны)

**ЖАРГОНИЗМ** ЖАРГОНИЗМ Билгеле бер жаргонга караган, шул ук вакытта көндәлек сөйләмдә дә кулланыла торган сүзләр, шартлы тәкъбирләр

**ЖАРГОННОЕ СЛОВО** ЖАРГОН СҮЗ *к.* **жаргонизм**

**ЖЕЛАТЕЛЬНОЕ НАКЛОНЕНИЕ** ТЕЛӘК НАКЛОНЕНИЯСЕ, ТЕЛӘК ФИГЫЛЬ Фигыльдә теләк, ихтыяр күрсәтү, шулай ук, контекстка бәйле рәвештә, шарт, кире шарт, тиешлек, мөмкинлек мәгънәләрен белдерә, беренче зат һәм сан кушымчалары алып төрләнә торган зат наклонение (мәс., *Шул турыда аз гына – биш-алты сүз сөйлим әле, гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле*. Г. Тукай)

**ЖЕСТОВ ЯЗЫКИ** ЫМ-ИШАРӘ ТЕЛЛӘРЕ *к.* **языки жестов**

**ЖЕСТОВЫЕ УДАРЕНИЯ** ЖЕСТ БАСЫМНАРЫ Сөйләм белән бер үк вакытта бер үк коммуникатив пространствода синхрон ясала торган кул хәрәкәтләре

**ЖЕНСКИЙ РОД** ЖЕНСКИЙ РОД Кайбер телләрдә исемнәрдә грамматик категориянең төрләнешендәге аерым бер парадигма булган, биологик җенескә генә түгел, ә сүз формасы аша билгеләнә торган тел категориясе

**ЖИВОЙ СУФФИКС** ТЕРЕ СУФФИКС, АКТИВ СУФФИКС Җанлы сөйләм телендә актив яңа форма, сүзләр ясый торган кушымча; продуктив кушымча

**ЖИВОЙ ЯЗЫК** ҖАНЛЫ ТЕЛ Теге яки бу халыкның сөйләм теле булган, шуңа да үсеш-үзгәреш процессында торган тел

# З

**ЗАГЛАВНЫЕ БУКВЫ** БАШ ХӘРЕФЛӘР Хәрфләрнең зуррак языла, кайчак язылыш формасы белән дә аерыла торган варианты

**ЗАДНЕЯЗЫЧНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ТЕЛ АРТЫ ТАРТЫКЛАРЫ Телнең арткы өлеше йомшак аңкауга күтәрелү белән ясалган тартыклар (татар телендә *к, г, х, ң* тартыклары)

**ЗАИМСТВОВАННЫЕ СЛОВА** АЛЫНМА СҮЗЛӘР Телгә чит телләрдән кереп, кулланышта йөри торган сүзләр (мәс., татар телендә *гарәп, фарсы, рус, Европа телләреннән* кергән алынмалар)

**ЗАКОН ЗНАКА** ТАМГА ЗАКОНЫ Билгеле бер эчтәлекнең билгеле бер чагылышка тәңгәллеге

**ЗАКОН ПЕРЕДВИЖЕНИЯ УДАРЕНИЯ** БАСЫМ КҮЧҮ ЗАКОНЫ Төрләнгән вакытта басымның нигездән кушымчага күчү законы (тел гыйлемендә Фортунатов – де Соссюр законы дип тә йөртелә)

**ЗАКОНОМЕРНОЕ ЧЕРЕДОВАНИЕ ЗВУКОВ** АВАЗЛАРНЫҢ ЗАКОНЛЫ ЧИРАТЛАШУЫ Төрләнгән вакытта бер төрле авазларның икенче төрле авазларга күчүе

**ЗАКРЫТЫЕ ГЛАСНЫЕ** ЯБЫК СУЗЫКЛАР Авызның азрак ачылышы, телнең биегрәк күтәрелеше белән әйтелә торган сузыклар (мәс., *э, ы* һ.б.)

**ЗАКРЫТЫЙ СЛОГ** ЯБЫК ИҖЕК Тартыкка тәмамланган иҗек

**ЗАЛОГ** ЮНӘЛЕШ Эш-хәлнең субъекты белән объекты арасындагы мөнәсәбәтләрне белдерә торган фигыльләргә хас грамматик категория (татар телендә *төп, төшем, йөкләтү, уртаклык, кайтым* юнәлешләре бар)

**ЗАПАДНЫЙ ДИАЛЕКТ** КӨНБАТЫШ ДИАЛЕКТ Мишәр сөйләшләрен берләштергән татар телендәге өч диалектның

берсе (чистай, чүпрәле, хвалын, сергач, мәләкәс, ләмбрә һ.б. сөйләшләр)

**ЗАПЯТАЯ** ӨТЕР Тиңдәш яки аерымланган җөмлә кисәкләрен, кабатлауларны, эндәш сүзләрне, ымлыкларны, җөмләләрне һ.б. аера торган тыныш билгесе (,)

**ЗАСТЫВШИЙ** КАТЫП КАЛГАН Телнең борынгы чорыннан үзгәрмичә күчкән, хәзерге хәлендә продутив булмаган (*катып калган форма, катып калган сүз, катып калган әйләнмә*)

**ЗВОНКИЕ СОГЛАСНЫЕ** ЯҢГЫРАУ ТАРТЫКЛАР Артикуляция вакытында тавыш ярылары бер-берсенә якынаеп, һава агымы үткәндә калтырап тавыш барлыкка китереп, тавыш өстәп әйтелә торган авазлар; мәс., *б, в, г, д, ж, з* һ.б.ш.)

**ЗВУК** АВАЗ Сөйләм органнары тарафыннан барлыкка китерелә һәм башкача таркалмый торган иң гади сөйләм берәмлеге

**ЗВУК РЕЧИ** СӨЙЛӘМ АВАЗЫ Аерым бер зат тарафыннан аерым бер очракта конкрет әйтелгән аваз

**ЗВУК ЯЗЫКА** ТЕЛ АВАЗЫ Сөйләүче тарафыннан телдә булган конкрет фонетик берәмлеккә артикуляцион-акустик яктан тәңгәлләштереп әйтелгән, бер-берсенә якын торган сөйләм авазлары җыелмасы

**ЗВУКОВАЯ СИСТЕМА** АВАЗЛАР СИСТЕМАСЫ Аерым телгә хас авазлар системасы

**ЗВУКОВОЙ ТИП** АВАЗ ТИБЫ Сөйләүче аңындагы аваз эталоны

**ЗВУКОВЫЕ ИЗМЕНЕНИЯ** АВАЗ ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ Авазларның төрле сәбәпләр аркасында сөйләм процессындагы үзгәрешләре; мәсәлән, *унбер – умбер; менгәч – меңгәч*); *к.* **комбинаторные изменения звуков** һәм **позиционные изменения звуков**

**ЗВУКОПОДРАЖАТЕЛЬНЫЕ СЛОВА** АВАЗ ИЯРТЕМНӘРЕ Аваз составы белән кеше тавышына, хайван, кош-корт, бөҗәкләр чыгарган, төрле җансыз предметлар тудырган авазларга охшатып, телнең үз үзенчәлекләре нигезендә ясалган сүзләр (мәс., *хыр-хыр; кар-кар; мрау* һ.б.)

**ЗВУКОСОЧЕТАНИЕ** АВАЗ ТЕЗМӘЛӘРЕ Авазларның төрле комбинацияләрдә килә алу тәртибе

**ЗВУЧАНИЕ** ЯҢГЫРАШ Тел берәмлегенең тышкы ягы, әйтелеше

**ЗЕВГМА** ЗЕВГМА Барысы өчен дә уртак булган бер җөмлә кисәгенә караган бер үк төзелештәге синтаксик конструкцияләрнең бер-бер артлы эзлекле тезелүе; мәс., ***иртәдән бирле*** *күк йөзе кара болытлар белән капланган, пыскып яңгыр ява, төньяктан салкын җил исә*

**ЗИЯНИЕ** ИКЕ СУЗЫКНЫҢ РӘТТӘН КИЛҮЕ Морфема эчендә ике сузыкның бергә туры килүе (мәс., *аэропорт, радиоузел*)

**ЗНАК ПЕРЕНОСА** ЮЛНЫ ЮЛГА КҮЧЕРҮ ТАМГАСЫ Бер юлдан икенче юлга сүзне бүлеп күчерү тамгасы, дефис (-)

**ЗНАКИ ПРЕПИНАНИЯ** ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ Язма текстның эчтәлеген һәм пауза, интонация үзенчәлекләрен дөрес чагылдырырга ярдәм итә торган график билгеләр (*нокта, өтер, сызык, ике нокта, нокталы өтер, күп нокталар* һ.б.)

**ЗНАМЕНАТЕЛЬНЫЕ СЛОВА** МӨСТӘКЫЙЛЬ СҮЗЛӘР Тулы мәгънәгә ия булган сүзләр

**ЗНАЧЕНИЕ** МӘГЪНӘ Нинди дә булса эчтәлеккә ия булу; лексик яки грамматик мәгънә белдерү

**ЗНАЧЕНИЕ БУКВ** ХӘРЕФ МӘГЪНӘСЕ Хәрефнең фонемаларга һәм аның кисәкләренә тәңгәллеге, шулай ук янәшәсендәге хәрефләрнең мәгънәсен ачыклавы

**ЗНАЧЕНИЕ ПОСТРОЕНИЯ** ТӨЗЕЛМӘНЕҢ МӘГЪНӘСЕ Синтаксик конструкциянең, әйләнмәнең, сүз тәртибенең эчтәлек ягы

**ЗНАЧЕНИЕ СЛОВА** СҮЗ МӘГЪНӘСЕ Сүзнең семантик составы, сүзнең чынбарлыкны чагылдырган эчтәлеге

# И

**ИДЕОГРАММА** ИДЕОГРАММА Тулы бер сүзне, тамырны яки тулы бер төшенчәне аңлата торган шартлы сурәтләр яки рәсемнәр

**ИДЕОГРАФИЧЕСКИЙ СИНОНИМ** ИДЕОГРАФИК СИНОНИМ Мәгънә төсмере, билгенең дәрәҗәсе белән аерыла торган лексик синоним (мәс., *кычкыру – акыру – үкерү*)

**ИДЕОГРАФИЧЕСКОЕ ПИСЬМО** ИДЕОГРАФИК ЯЗУ График тамга ярдәмендә төрле төшенчәләр, мәгънәләр белдерә торган язу

**ИДЕОГРАФИЯ** ИДЕОГРАФИЯ Идеограммалар ярдәмендә язу системасы

**ИДЕОРГАФИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ** ИДЕОГРАФИК СҮЗЛЕК Телнең лексикасы тематик төркемнәрдә яки семантик кырларда бирелгән лингвистик сүзлек

**ИДИОЛЕКТ** ИДИОЛЕКТ Аерым шәхес теле, аерым кеше сөйләменең семантик, стилистик үзенчәлекләре

**ИДИОМА** ИДИОМА Составындагы сүзләрнең мәгънәләреннән аңлашылмый торган, яңа кинаяле мәгънә алган һәм билгеле бер телгә генә хас әйтелмә, тотрыклы сүз тезмәсе; фразеологизмнарның иң тотрыклы, таркалмый торган төре (мәс., *кара коелу*, *комы коелу*)

**ИДИОМАТИКА** ИДИОМАТИКА 1) Лексикологиянең идиомаларны өйрәнә торган бер тармагы; 2) Аерым телдәге идиомалар җыелмасы

**ИДИОМАТИЧЕСКОЕ ВЫРАЖЕНИЕ** ИДИОМАТИК ТӘКЪБИР Берәр телнең идиомага әверелгән сөйләм әйләнмәсе

**ИДИОМАТИЧНОСТЬ** ИДИОМАЛЫЛЫК Ясалма тел берәмлегенең мәгънәсе аның компонентларының мәгънәләре суммасыннан зуррак булу күренеше

**ИДИОМАТОЛОГИЯ** ИДИОМАТОЛОГИЯ Тел белеменең идиомаларны тикшерә торган бүлеге

**ИДО** ИДО Эсперанто варианты буларак Л. де Бофрон уйлап тапкан халыкара ясалма тел

**ИЕРОГЛИФ** ИЕРОГЛИФ Кытай, япон, корея кебек кайбер халыкларның язу системасында шартлы рәвештә тулы бер төшенчәне, иҗек яки аерым авазны белдерә торган рәсемгә охшаш билге

**ИЗАФЕТ** ИЗАФӘ Кайбер телләрдәге атрибутив конструкция төре (мәс., төрки телләрдә ике буыны да исем белән белдерелгән төзелмәләр; өч төре күзәтелә: I төр – *таш койма,* II төр – *мәктәп бакчасы,* III төр – *дустының сүзе*)

**ИЗМЕНЕНИЕ ЗНАЧЕНИЙ СЛОВ** СҮЗЛӘРНЕҢ МӘГЪНӘСЕ ҮЗГӘРҮ Тарихи процесста сүзләрнең мәгънәсе киңәю яки тараю

**ИЗМЕНЯЕМЫЕ ЧАСТИ РЕЧИ** ТӨРЛӘНӘ ТОРГАН СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ Грамматик характеристикасы флексияләрдә белдерелгән сүз төркемнәре

**ИЗОГЛОССА** ИЗОГЛОССА Географик картада нинди дә булса тел күренеше таралышының чикләрен күрсәткән сызык

**ИЗЪЯВИТЕЛЬНОЕ НАКЛОНЕНИЕ ГЛАГОЛА** ХИКӘЯ ФИГЫЛЬ Эш яки хәлнең булу-булмавын хикәяләү, хәбәр итү рәвешендә белдерә торган фигыль формасы

**ИЗОЛИРУЮЩИЕ ЯЗЫКИ** ИЗОЛЯЦИЯЛӘҮЧЕ ТЕЛЛӘР Сүзләрнең төрләнмәве белән характерлана торган телләр; грамматик мәгънәләр сүз тәртибе, ярдәмлек сүзләр, интонация файдаланып белдерелә торган телләр

**ИЛЛИРИЙСКАЯ ГРУППА ЯЗЫКОВ** ИЛЛИРИЯ ТЕЛЛӘРЕ ТӨРКЕМЕ Һинд-Европа телләренең үле иллирия һәм мессап телләрен берләштергән төркеме

**ИЛЛОКУЦИЯ** ИЛЛОКУЦИЯ Сөйләм актының коммуникатив максатны белдерә торган состав өлеше

**ИМЕНИТЕЛЬНЫЙ ПАДЕЖ** БАШ КИЛЕШ Объектны, субъектны белдерә, махсус кушымча алмый торган килеш па-

радигмасында беренче категориаль килеш формасы; төп килеш; кем? нәрсә? сорауларына җавап бирә

**ИМЕННАЯ ОСНОВА** ИСЕМ НИГЕЗ Нигезе исем белән белдерелгән сүз

**ИМЕННОЕ ПОДЛЕЖАЩЕЕ** ИСЕМ ИЯ Фигыльдән башка сүз төркемнәре белән белдерелгән ия

**ИМЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ИСЕМ ҖӨМЛӘ Баш кисәге исем яки исемләшкән башка сүзләр белән белдерелгән бер составлы җөмлә

**ИМЕННОЕ СКАЗУЕМОЕ** ИСЕМ ХӘБӘР Җөмләдә фигыльдән башка сүз төркемнәре белән белдерелеп килә торган хәбәр (мәс., *Балык каптыру минем бәләкәй чактан ук сөйгән эшемдер.* Г. Ибраһимов.)

**ИМЕННОЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЕ** ИСЕМ СҮЗТЕЗМӘ Ияртүче кисәге исем булган сүзтезмә

**ИМЕННЫЕ ГЛАГОЛЬНЫЕ ФОРМЫ** ЗАТЛАНЫШСЫЗ ФИГЫЛЬ ФОРМАЛАРЫ Төрләнми торган, ягъни эш-хәрәкәт предметлаштырылган яки билгеләштерелгән фигыльләр; *к.* **инфинитив, причастие, деепричастие**

**ИМЕННЫЕ КЛАССЫ** ИСЕМ КЛАССЛАРЫ Исемнәрне семантик билгеләреннән чыгып һәм шул ук вакытта исемнең җөмлә структурасында формаль чагылышына карап төркемнәргә аера торган лексик-грамматик категория

**ИМПЕРАТИВ** ИМПЕРАТИВ, БОЕРЫК ФИГЫЛЬ Грамматик күрсәткече нуль форма булган, категориаль мәгънәсе эшкә кушу, эштән тыю, боеру, өндәү, үтенүне белдергән һәм фигыль формасы; заманда төрләнми, сан белән төрләнә, II–III затларда кулланыла

**ИМПЕРАТИВНЫЕ МЕЖДОМЕТИЯ** ИМПЕРАТИВ ЫМЛЫКЛАР Теләк, ихтыярны, шулай ук кош-кортларны, хайваннарны чакыруны белдерә торган ымлыклар (мәс., *на-на, баһ-баһ, пес-пес*)

**ИМПЕРФЕКТ** ИМПЕРФЕКТ, ТӘМАМЛАНМАГАН ҮТКӘН ЗАМАН (фигыль) Сөйләм моментыннан алда булган

процесс рәвешендә башкарылган, кабатланган, гадәттә эш-хәлләрне белдерә, хәзерге заман хикәя фигыльгә иде ярдәмче фигыле кушып ясала торган аналитик фигыль формасы (мәс., *елмая иде, көчәя бара иде*)

**ИМПЕРФЕКТИВАЦИЯ** ИМПЕРФЕКТИВАЦИЯ, ИМПЕРФЕКТЛАШУ Несовершеннный вид фигыльләренең -ыва/-ива, -а, -ва суффикслары ярдәмендә совершенный вид фигыльләреннән ясалышы

**ИМПЛОЗИВНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ИМПЛОЗИВ ТАРТЫКЛАР Шартлау бирми торган, йомык тартыклар

**ИМЯ ДЕЙСТВИЯ** ИСЕМ ФИГЫЛЬ Исем һәм фигыль билгеләренә ия булган затланышсыз фигыль төркемчәсе; барлык-юклыкта төрләнә, үзенә бәйләнгән исемнең нинди дә булса килештә булуын сорый (мәс., *аклану, кайту, саклау*)

**ИМЯ ПРИЛАГАТЕЛЬНОЕ** СЫЙФАТ Предметның гомумкатегориаль билгесен белдерә, төрләнми, дәрәҗә категориясе хас булган һәм нинди? кайсы? сорауларына җавап бирә торган сүз төркеме; җөмләдә аергыч булып килә

**ИМЯ СОБСТВЕННОЕ** ЯЛГЫЗЛЫК ИСЕМ Бер төрдән булган предметларның берсен икенчесеннән аеру өчен бирелгән исем

**ИМЯ СУЩЕСТВИТЕЛЬНОЕ** ИСЕМ Предметлыкны белдерә һәм килеш, тартым, сан, род белән төрләнә торган сүз төркеме; җөмләдә, гадәттә, ия, тәмамлык, хәбәр, аергыч функцияләрен башкара

**ИМЯ ЧИСЛИТЕЛЬНОЕ** САН Микъдар төшенчәсен, предметларның сан, данә исәбен белдерә торган сүз төркеме; микъдар саны, тәртип саны, бүлем саны, чама саны, җыю саны лексик-грамматик төремнәренә бүленә

**ИНВАРИАНТ** ИНВАРИАНТ Бер үк төшенчәнең конкрет модификацияләргә-вариантларга бәйле булмаган абстракт билгеләнеше

**ИНВЕКТИВНАЯ ЛЕКСИКА** ИНВЕКТИВ ЛЕКСИКА Үтә тискәре бәяләү, кеше, зат, предмет һәм күренешләрне хурлау максатыннан кулланыла торган әдәпсез сүз һәм сүзтезмәләр

**ИНВЕРСИЯ** ИНВЕРСИЯ 1) Җөмлә кисәкләренең гомум кабул ителгән тәртибе бозылу; 2) Берәр сүзнең мәгънәсенә басым ясау яки җөмләгә билгеле бер стилистик төсмер бирү, тәэсирлекне арттыру өчен җөмләдә сүзләрнең гадәти тәртибен үзгәртү

**ИНДИВИДУАЛЬНЫЙ СТИЛЬ** ИНДИВИДУАЛЬ СТИЛЬ Аерым кеше сөйләмендәге семантик һәм стилистик үзенчәлекләр

**ИНДИВИДУАЛЬНО-АВТОРСКИЕ НЕОЛОГИЗМЫ** АВТОР НЕОЛОГИЗМНАРЫ Билгеле бер автор керткән неологизмнар

**ИНДИКАТИВ** ИНДИКАТИВ *к.* **глагол изъявительного наклонения**

**ИНДОЕВРОПЕЙСКИЕ ЯЗЫКИ** ҺИНД-ЕВРОПА ТЕЛЛӘРЕ 12 генетик төркемне (һинд, иран, славян, балтика, герман, роман, кельт, грек, албан, әрмән, хет, тохар һ.б.) берләштергән иң эре һәм иң киң таралган телләр семьялыгы

**ИНДОЕВРОПЕИСТИКА** ИНДОЕВРОПЕИСТИКА Лингвистиканың Һинд-Европа телләрен чагыштырма-тарихи метод белән өйрәнү бүлеге

**ИНДОИРАНСКИЕ ЯЗЫКИ** ҺИНД-ИРАН ТЕЛЛӘРЕ Һинд-Европа телләре семьялыгының һинд һәм иран телләре тармагы

**ИНДОНЕЗИЙСКАЯ ГРУППА ЯЗЫКОВ** ИНДОНЕЗИЯ ТЕЛЛӘРЕ ТӨРКЕМЕ Австронезия телләре семьялыгыннан 300 дән артык телне (мәс., индонезия, филиппин телләре) берләштергән төркем

**ИНИЦИАЛЬ** ИНИЦИАЛЬ Аваз, башлангыч иҗек; *чаг.* **медиаль, финаль**

**ИНИЦИАЛЬНАЯ АББРЕВИАТУРА** ИНИЦИАЛЬ АББРЕВИАТУРА Сүзтезмәнең беренче хәрефләреннән яки беренче иҗекләреннән ясалган аббревиатура

**ИНКОРПОРАЦИЯ** ИНКОРПОРАЦИЯ Полисинтетик телләрдә тамыр һәм ярдәмлек сүзләрне кушып сүз җөмләләр төзү (мәс., ацтек телендә: *ни* – «мин», *накатя* – «ит» , *ква* – «ашарга», ә *нинакатква* – «мин ит ашыйм» була)

**ИНКОРПОРИРОВАНИЕ** ИНКОРПОРАЦИЯЛӘҮ *к.* **инкорпорация**

**ИНКОРПОРИРОВАННОЕ СЛОВО-ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ИНКОРПОРАЦИЯЛӘНГӘН СҮЗ-ҖӨМЛӘ Инкорпорация ысулы белән ясалган сүз-җөмлә

**ИНКОРПОРИРУЮЩИЕ ЯЗЫКИ** ИНКОРПОРАЦИЯЛӘҮЧЕ (ПОЛИСИНТЕТИК) ТЕЛЛӘР Грамматик төзелешләре инкорпорациягә нигезләнгән телләр

**ИННОВАЦИЯ** ИННОВАЦИЯ Телдә эчке үзгәреш

**ИНОСКАЗАНИЕ** КИНАЯ Читләтеп, яшереп әйтелгән сүз

**ИНОСТРАННЫЕ СЛОВА** ЧИТ ТЕЛ СҮЗЛӘРЕ *к.* **иноязычные слова**

**ИНОСТРАННЫЙ ЯЗЫК** ЧИТ ТЕЛ Билгеле бер милләт, халык өчен туган тел булмаган тел

**ИНОЯЗЫЧНЫЕ СЛОВА** ЧИТ ТЕЛ СҮЗЛӘРЕ Туган телгә башка телләрдән алынган сүзләр; *к.* **заимствованные слова**

**ИНТЕГРАЦИЯ** ИНТЕГРАЦИЯ Телләрнең бер-берсенә якынаюы

**ИНТЕНСИВНОСТЬ** ИНТЕНСИВЛЫК Авазның басымлы-басымсыз иҗекләрне аерырга ярдәм итә торган акустик билгесе, тавышның көче, интонация чарасы

**ИНТЕНСИВНОСТЬ РЕЧИ** СӨЙЛӘМНЕҢ ИНТЕНСИВЛЫГЫ Тавышның көче белән характерлана торган интонацион берәмлек

**ИНТЕРВОКАЛЬНАЯ ПОЗИЦИЯ** ИНТЕРВОКАЛЬ ПОЗИЦИЯ Тартык авазның ике сузык арасында килүе

**ИНТЕРВОКАЛЬНОЕ ОЗВОНЧЕНИЕ** ИНТЕРВОКАЛЬ ЯҢГЫРАУЛАШУ Интервокаль позициядә саңгырау тартыкның яңгыраулашу күренеше (мәс., *китап – китабы*)

**ИНТЕРВОКАЛЬНОЕ ПОЛОЖЕНИЕ** ИНТЕРВОКАЛЬ УРЫН (ТОРЫШ) *к.* **интервокальная позиция**

**ИНТЕРВОКАЛЬНЫЙ СОГЛАСНЫЙ** ИНТЕРВОКАЛЬ ТАРТЫК Ике сузык арасындагы тартык

**ИНТЕРДЕНТАЛЬНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ИНТЕРДЕНТАЛЬ ТАРТЫКЛАР Телне аскы һәм өске тешләр арасына куеп әйтелә

торган тартыклар (мәс., Минзәлә сөйләшендәге «сакау» [*з*], инглиз телендәге [*th*] тартыгы)

**ИНТЕРДИАЛЕКТ** ИНТЕРДИАЛЕКТ *к.* **койне**

**ИНТЕРЛЕКТ** ИНТЕРЛЕКТ *к.* **язык-посредник**

**ИНТЕРЛИНГВА** ИНТЕРЛИНГВА Дж.Пиано уйлап тапкан грамматик структурасы латин теленә, лексик яктан төрле европа телләренең тамыр сүзләренә нигезләнгән халыкара ясалма тел

**ИНТЕРЛИНГВИСТИКА** ИНТЕРЛИНГВИСТИКА Тел белеменең ясалма телләрне өйрәнә торган бүлеге

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗАЦИЯ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ ИНТЕРНАЦИОНАЛЬЛӘШҮЕ Телнең кулланылышы этник төркем кысаларыннан чыгуы, бер төркем этнослар өчен уртак булып китүе

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗМЫ** ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗМНАР *к.* **интернациональная лексика**

**ИНТЕРНАЦИОНАЛЬНАЯ ЛЕКСИКА** ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ ЛЕКСИКА Кардәш булмаган күпчелек телләр өчен уртак халыкара характердагы сүзләр, гадәттә, фән һәм техника терминнары

**ИНТЕРНАЦИОНАЛЬНАЯ ТЕРМИНОЛОГИЯ** ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ ТЕРМИНОЛОГИЯ Кардәш булмаган күпчелек телләр өчен уртак булган терминнар (мәс., *грамматика*)

**ИНТЕРНАЦИОНАЛЬНЫЕ СЛОВА** ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ СҮЗЛӘР Кардәш булмаган күпчелек телләр өчен уртак булган сүзләр (мәс., *коммунист, радио*)

**ИНТЕРПУНКЦИЯ** ИНТЕРПУНКЦИЯ Язмада тыныш билгеләренең куелышы

**ИНТЕРФЕРЕНЦИЯ** ИНТЕРФЕРЕНЦИЯ Икетеллелек шартларында тел системаларының тәэсир итешү күренеше; туган тел үзенчәлекләрен чит телгә күчереп сөйләшү

**ИНТЕРФИКС** ИНТЕРФИКС Номинатив мәгънәгә ия булмаган, сүздә тамыр белән кушымчаны бәйләргә ярдәм итә торган өстәмә аваз

**ИНТЕРФИКСАЦИЯ** ИНТЕРФИКСАЦИЯ Морфлар тоташканда авыр әйтелешле фонемаларның төзелмәләрен җиңелрәк

әйтү өчен ике янәшә морфлар арасына интерфикс өстәүдән гыйбарәт морфонологик күренеш

**ИНТОНАЦИОННОЕ ЦЕЛОЕ** ИНТОНАЦИОН БЕРБӨТЕН Сөйләмдә бер паузадан икенче паузага кадәр булган ара

**ИНТОНАЦИОННЫЕ СРЕДСТВА** ИНТОНАЦИЯ ЧАРАЛАРЫ Сөйләмдә синтаксик мәгънәләр һәм эмоциональ төсмерләр белдерә торган чаралар

**ИНТОНАЦИЯ** ИНТОНАЦИЯ Сөйләмнең синтаксик мәгънәләр һәм эмоциональ төсмерләр белдерә торган ритмик-мелодик ягы

**ИНТОНАЦИЯ ОЖИДАНИЯ** КӨТТЕРҮ ИНТОНАЦИЯСЕ Сөйләмдә дәвам ителәчәк кисәкне искәртеп куя, аңа кадәрге өлешне аңлатып килә торган сүзләр яки җөмләләр арасындагы пауза

**ИНТОНАЦИЯ ПРОТИВОПОСТАВЛЕНИЯ** КАРШЫ КУЮ ИНТОНАЦИЯСЕ Семантик яктан бер-берсенә каршы булган сүзләр, җөмләләр арасындагы интонация; ул, нигездә, паузадан гыйбарәт

**ИНТОНИРОВАНИЕ** ИНТОНАЦИЯЛӘҮ Тавыш көче, сөйләм тизлеге, паузалар, тембр, басымнар үзгәреше

**ИНФИКС** ИНФИКС Сүзнең тамыры яки нигезе эченә үтеп керә торган кушымча

**ИНФИНИТИВ** ИНФИНИТИВ Фигыльләрнең зат, сан, заман белән төрләнми торган башлангыч формасы (мәс., *укырга, эшләргә*)

**ИНФИНИТИВНЫЕ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ИНФИНИТИВ ҖӨМЛӘЛӘР Башкаручыга бәйләнмәгән потенциаль эш белдерелгән берсоставлы хәбәр җөмлә (мәс., *Туңга сөрүне вакытында тәмамларга!*)

**ИНФОРМАНТ** ИНФОРМАНТ Лингвистик материал чыганагы буларак теге яки бу телдә сөйләшүче

**ИНХОАТИВНЫЕ ГЛАГОЛЫ** ИНХОАТИВ ФИГЫЛЬЛӘР Эшнең башлангычын белдерә торган совершенный вид фигыльләре

**ИРАНИСТ** ИРАНИСТ Иран телләре белгече

**ИРАНСКИЕ ЯЗЫКИ** ИРАН ТЕЛЛӘРЕ Һинд-европа телләре семьялыгыннан дүрт астөркемне (көньяк-көнбатыш – фарсы, таҗик һ.б. телләр, төньяк-көнбатыш – көрд, каспий буе һ.б.

телләр, көньяк-көнчыгыш – пашто, памир һ.б. телләр, төньяк-көнчыгыш – осетин һ.б. телләр) берләштергән телләр төркеме

**ИРРАЦИОНАЛЬНЫЕ ГЛАСНЫЕ** ИРРАЦИОНАЛЬ СУЗЫКЛАР Бик кыскартылган сузыклар

**ИСКОННОЕ СЛОВО** ТУГАН ТЕЛ СҮЗЕ Туган телнең беренчел сүзлек составына кергән яки шул телнең үз лексик материалыннан ясалган сүз

**ИСКУССТВЕННОЕ ДВУЯЗЫЧИЕ** ЯСАЛМА ИКЕТЕЛЛЕЛЕК Икетеллелекнең икенче телне дидактик юл белән өйрәнүгә нигезләнгән төре

**ИСКУССТВЕННЫЕ ЯЗЫКИ** ЯСАЛМА ТЕЛЛӘР Гадәти телне куллану мөмкин булмаган яисә бик үк эффектив саналмаган өлкәләрдә файдалану өчен тудырыла торган билге системалары (мәс., эсперанто)

**ИСТИННЫЙ ДИФТОНГ** ЧЫН ДИФТОНГ Төп, чын мәгънәсендәге дифтонг; иҗек ясаучы сузык авазлардан торган дифтонг

**ИСТОРИЗМ** ТАРИХИ СҮЗ Үзләре белдерә торган төшенчәләр белән бергә кулланылыштан төшеп калган сүзләр (мәс., *айбалта, алпавыт, коммуна*)

**ИСТОРИОГРАФИЯ ЛИНГВИСТИКИ** ЛИНГВИСТИКА ИСТОРИОГРАФИЯСЕ Тел белемендә тел турындагы белемнәрнең үсешен өйрәнә, лингвистик фикерләүнең генезисы турындагы теория һәм концепцияләрне анализлау белән шөгыльләнә торган юнәлеш

**ИСТОРИЧЕСКАЯ ГРАММАТИКА** ТАРИХИ ГРАММАТИКА Грамматиканың тел төзелешен, тел берәмлекләренең төрле чорлардагы торышларын чагыштырып өйрәнә торган бүлеге

**ИСТОРИЧЕСКАЯ ФОНЕТИКА** ТАРИХИ ФОНЕТИКА Теге яки бу телдә авазлар составының шул тел үсеше процессында үзгәрүен һәм ул үзгәрүнең сәбәпләрен тикшерә-өйрәнә торган фән

**ИСТОРИЧЕСКИЕ ЧЕРЕДОВАНИЯ ЗВУКОВ** АВАЗЛАРНЫҢ ТАРИХИ ЧИРАТЛАШУЫ Авазларның фонетик позициягә бәйле булмаган, ә тел үсешенең элгәрерәк чорларында барган фонетик үзгәрешләргә бәйле чиратлашуы

**ИСТОРИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ** ТАРИХИ СҮЗЛЕК Сүзләрнең килеп чыгышы, мәгънәләре үсеше, сүзьясалыш структурасы үзгәрү турындагы мәгълүматлар китерелгән сүзлек

**ИСТОРИЧЕСКОЕ ЯЗЫКОЗНАНИЕ** ТАРИХИ ТЕЛ БЕЛЕМЕ Телләр үсеше тарихын тикшерә-өйрәнә торган фән

**ИСХОДНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ТӨП МӘГЪНӘ Сүзнең, беренчел мәгънәсе; сүзнең этимоны

**ИСХОДНЫЙ ПАДЕЖ** ЧЫГЫШ КИЛЕШЕ Эш яки хәлнең урын я вакыт ягыннан чыгыш ноктасын, урынын, берәр нәрсәдән аерылу һәм ераклашуын, эш яки хәлнең туры һәм кыек объектын, эшнең сәбәбен белдерә торган форма

**ИСЧЕЗАЮЩИЕ ЯЗЫКИ** ЮГАЛЫП БАРУЧЫ ТЕЛЛӘР Кулланылыш даирәсе тар һәм кулланучылар саны аз булган аз санлы халыкларның теле (мәс., сойот теле)

**ИТАЛИЙСКАЯ ГРУППА ЯЗЫКОВ** ИТАЛИЯ ТЕЛЛӘРЕ ТӨРКЕМЕ Һинд-европа телләренең берничә хронологик чорларга караган телләрне (үле латин, француз, прованс, испан, сардин, руманш, румын, молдован һ.б.) берләштергән төркеме

# Й

**ЙОТ** ЙОТ, КЫСКА *И* Янындагы авазга янәшәлек юлы белән бәйләнә торган, өрелмәле, тел уртасы сонант авазы

**ЙОТАЦИЯ** ЙОТЛАШУ Сүз башында яки сузык авазлар уртасында йот авазы барлыкка килү

**ЙОТИЗАЦИЯ** ЙОТЛАШТЫРУ Йот алдыннан тартык авазның палатальләшүе

**ЙОТИРОВАННЫЕ ГЛАСНЫЕ** ЙОТЛЫ СУЗЫКЛАР Алдында [*j*] авазы булган сузыклар

**ЙОТОВАЯ АРТИКУЛЯЦИЯ** ЙОТ АРТИКУЛЯЦИЯСЕ Телнең уртасын каты аңкауга тидерү яки палатальләшүдән гыйбарәт артикуляция

# К

**КАКУМИНАЛЬНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** КАКУМИНАЛЬ ТАРТЫКЛАР *к.* **церебральные согласные**

**КАЛЬКИРОВАНИЕ** КАЛЬКАЛАУ Чит тел сүзен морфемалап тәрҗемә итеп телгә кабул итү

**КАНЦЕЛЯРИЗМЫ** КАНЦЕЛЯРИЗМНАР Әдәби телдә рәсми стиль, аеруча канцелярия эше стилендә даими кулланылып килгән һәм шул стильгә беркетелгән сүзләр, сүзтезмәләр, грамматик формалар һ.б.

**КАРИТИВ** КАРИТИВ, ЮКЛЫК КИЛЕШЕ Объектта билгеле сыйфатның булмавын белдерә торган категориаль килеш формасы

**КАРТИНА МИРА** ДӨНЬЯ КАРТИНАСЫ Кешенең әйләнәтирә чынбарлык белән аралашуы барышында, аның бөтен рухи активлыгы нәтиҗәсендә тупланган дөньяның глобаль, гомуми образы, чагылышы

**КАРТИННЫЙ СЛОВАРЬ** КАРТИНАЛЫ СҮЗЛЕК Предметлы-тематик принцип белән берләштерелгән график иллюстрацияләре булган сүзлек

**КАРТОГРАФИРОВАНИЕ** КАРТОГРАФИЯЛӘҮ Телнең территорияләр белән бәйле үзенчәлекләрен картага төшерү (мәс., диалект лексикасын картографияләү, топонимнарны картографияләү)

**КАТАХРЕЗА** КАТАХРЕЗА Сүзне аның этимологик мәгънәсендә кулланмау, капма-каршы төшенчәләрне берләштерү

**КАТЕГОРИАЛЬНЫЕ (ЛОГИЧЕСКИЕ) ГРАММАТИКИ** КАТЕГОРИАЛЬ (ЛОГИК) ГРАММАТИКАЛАР Тел белеменең табигый һәм ясалма телләрне тасвирлау методларын булдыру белән шөгыльләнә торган юнәлешләре

**КАТЕГОРИЗАЦИЯ** КАТЕГОРИЯЛӘШҮ, КАТЕГОРИЯЛӘШТЕРҮ Категория барлыкка килү яисә теге яки бу тел берәмлеге ярдәмендә белдерелгән мәгънәләрне инде телдә булган категорияләр белән тәңгәлләштерү процессы

**КАТЕГОРИЯ СОСТОЯНИЯ (БЕЗЛИЧНО-ПРЕДИКАТИВНЫЕ СЛОВА)** ХӘБӘРЛЕК СҮЗЛӘР Җанлы һәм җансыз табигатьнең халәтен, торышын, кайвакыт модаль мәгънә һәм бәяләү белдерә, җөмләдә хәбәр функциясендә килә торган төрләнешсез сүзләрнең лексик-грамматик төре

**КАУЗАЛЬНЫЕ ОТНОШЕНИЯ** КАУЗАЛЬ МӨНӘСӘБӘТЛӘР, СӘБӘП МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ Синтаксик чаралар белән белдерелгән сәбәп мөнәсәбәтләре

**КАЧЕСТВЕННАЯ РЕДУКЦИЯ** СЫЙФАТ РЕДУКЦИЯСЕ *к.* **редукция**

**КАЧЕСТВЕННОЕ ПРИЛАГАТЕЛЬНОЕ** АСЫЛ СЫЙФАТ Сыйфатларның объектның саф билгеләрен: төсен, физик билгесен, характерын, күләмен һ.б.ш. белдерә торган төре

**КАЧЕСТВЕННЫЕ ОТЛИЧИЯ БЕЗУДАРНЫХ ГЛАСНЫХ** БАСЫМСЫЗ СУЗЫКЛАРНЫҢ СЫЙФАТ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ Редукцияләнгән сузыкларны тулы ясалышлы авазлардан принципиаль рәвештә аера торган билгеләр (мәс., тембр)

**КВАЗИКАУЗАЛЬНЫЕ ОТНОШЕНИЯ** КВАЗИКАУЗАЛЬ МӨНӘСӘБӘТЛӘР, ЯЛГАН СӘБӘП МӨНӘСӘБӘТЛӘР Сәбәп мөнәсәбәтләре бөтенләй булмаган яки чагыштырмача белдерелгән мөнәсәбәтләр

**КВАЗИЭКСПЕРИМЕНТ** КВАЗИЭКСПЕРИМЕНТ Тикшерүче тел материалларын үзе билгеләгән параметрлардан чыгып, информантларга мөрәҗәгать итмичә туплаудан һәм эшкәртүдән гыйбарәт, эксперимент белән күзәтү арасында торган фәнни метод

**КВАНТИТАТИВНАЯ ТИПОЛОГИЯ** КВАНТИТАТИВ ТИПОЛОГИЯ Типологик тел белеменең бары тик сыйфатка гына караган параметрлар белән эш итмичә, төрле телләрдә теге яки бу сыйфатлы билгенең булу-булмавын чагылдырган статистик индекслар белән эшли торган юнәлеше

**КВАНТИТАТИВНЫЙ** КВАНТИТАТИВ Объектның, билгенең күләм, микъдар, сан ягын чагылдыра торган (мәс., *квантитатив анализ, квантитатив чиратлашу* һ.б.)

**КЕНЕМА** КЕНЕМА Глоссемантикада тел берәмлегенең билгеләү планының инварианты

**КИНЕСИКА** КИНЕСИКА Паралингвистиканың коммуникация эчтәлеген, шулай ук ым, ишарә һ.б.ш. өйрәнә торган бүлеге

**КИНЕТИКА** КИНЕТИКА Ишарә теле

**КИНЕТИЧЕСКАЯ РЕЧЬ** КИНЕТИК СӨЙЛӘМ Ишарәләр теле ярдәмендә аралашу

**КИНЕТИЧЕСКИЙ ЯЗЫК** КИНЕТИК ТЕЛ Ишарәләр теле

**КИПУ** КИПУ Борынгы Перу халкының төен язуы; график язу барлыкка килгәнче мәгүлүматны төрле төстәге җепләр һәм төрле формадагы төеннәр ярдәмендә белдерә торган шартлы билгеләр системасы

**КИРИЛЛИЦА** КИРИЛЛИЦА, КИРИЛЛ ГРАФИКАСЫ Хәзерге рус алфавиты нигезенә салынган беренче ике славян әлифбасының берсе; глаголицадан хәрефләрнең формасы төгәлрәк һәм гадирәк булуы белән аерыла

**КИССАНДЫ** КИССАНДЛАР Билабиаль тартыклар, ирен-ирен тартыклары, мәс., бушмен телендә

**КЛАССИФИКАЦИОННЫЕ ТИПЫ ГРАММАТИЧЕСКИХ КАТЕГОРИЙ** ГРАММАТИК КАТЕГОРИЯЛӘРНЕҢ КЛАССИФИКАЦИОН ТИПЛАРЫ Сүзнең теге яки бу лексик-грамматик класска каравын билгели торган һәм сүзнең һәр кулланылышында чагылган категорияләр (мәс., рус телендә исемнең род категориясе)

**КЛАССИФИКАЦИЯ ГЛАСНЫХ** СУЗЫК АВАЗЛАР КЛАССИФИКАЦИЯСЕ Сузык авазларны акустик билгеләренә (*озынлык, форманталарының урнашуы*) һәм артикуляцион билгеләренә (*горизонталь, вертикаль хәрәкәте, иреннәрнең катнашу-катнашмавы*) карап төркемләү

**КЛАССИФИКАЦИЯ СОГЛАСНЫХ** ТАРТЫК АВАЗЛАР КЛАССИФИКАЦИЯСЕ Тартык авазларны артикуляцион (*ясалу урыны, ясалу ысулы*) һәм акустик (*тон һәм шауның катнашуы*) яктан төркемләү

**КЛАСТЕР** КЛАСТЕР Берничә билге буенча берләштерелгән берәмлекләр структурасы (мәс., *сарай, йорт, өй, ызба, алачык*

‘торак’ мәгънәле бер кластер тәшкил итәләр, үз чиратында ул ‘әйбәт торак’, ‘начар торак’ кластерларына бүленергә мөмкин)

**КЛАСТЕРИЗАЦИЯ** КЛАСТЕРЛАШТЫРУ Тикшерелә торган берәмлекләрне төрле алгоритмнар кулланып, теге яки бу параметрлар белән үлчәп, кластерларга берләштерү

**КЛАСТЕРНЫЙ АНАЛИЗ** КЛАСТЕРЛЫ АНАЛИЗ Эксперименталь тел белемендә тикшерү объектларын, төрле классификацияләү алгоритмнарын кулланып, күргәзмә структураларга – кластерларга оештырып өйрәнү алымы

**КЛИКС** КЛИКС Әйтелгәндә берьюлы авыз куышлыгында һәм бугазда фокус йомылып ясала торган чиертүле тартык аваз

**КЛИНОПИСЬ** ЧӨЙ ЯЗУЫ Борынгы язуларның Алгы Азиядә таралыш алган, тамгалары чөйсыман сызыкчалардан торган төре

**КЛИШЕ** КЛИШЕ Бер үк мәгънәдә бик еш кулланылган сөйләм гыйбарәсе

**КЛЮЧЕВАЯ ЛЕКСЕМА** АЧКЫЧ ЛЕКСЕМА, ТӨП СҮЗ Концептның мәгънәви үзәген тәшкил иткән, стилистик яктан иң нейтраль, иң кулланылышлы һ.б.ш. сүз

**КНАКЛАУТ** КНАКЛАУТ Немец телендә сөйләм агымында сүзне сүздән аеру чарасы буларак сүз башын катылык белән башлау

**КНИЖНЫЙ СТИЛЬ** КИТАП СТИЛЕ Әдәби телнең фәнни, публицистик һәм рәсми юнәлешләрдән торган стиле

**КОАРТИКУЛЯЦИЯ** КОАРТИКУЛЯЦИЯ Алдарак әйтелгән авазның артикуляциясе арттан килгән авазга кушылып китү күренеше

**КОГЕЗИЯ** КОГЕЗИЯ Кабатлаулар яки башка чаралар ярдәмендә тудырыла торган җөмлә эчендәге яки җөмләләр арасындагы бәйлелек

**КОГЕРЕНЦИЯ ЗВУКОВ** АВАЗЛАР КОГЕРЕНЦИЯСЕ Сөйләм авазларының үзара комбинатор бәйлелеге

**КОГНИТИВНАЯ БАЗА** КОГНИТИВ БАЗА Бер телдә сөйләшүчеләрнең һәммәсе өчен дә уртак, шул лингвокультур җәмгы-

ятьтә мәҗбүри булган һәм билгеле тәртиптә оештырылган белемнәр җыелмасы

**КОГНИТИВНАЯ ЛИНГВИСТИКА** КОГНИТИВ ЛИНГВИСТИКА Когнитология фәненең төрле формадагы мәгълүматны тел берәмлекләре ярдәмендә кабул итү, чагылдыру һәм эшкәртү күренешләрен өйрәнә торган тармагы

**КОГНИТИВНАЯ МЕТАФОРА** КОГНИТИВ МЕТАФОРА Реаль яки күзалланган сыйфатларның фикердәге чагылышы (мәс., рус. *горстка* – бик аз кеше мәгънәсендә, тат. *бөртек* – шундый ук мәгънәдә)

**КОГНИТИВНАЯ (ГНОСЕОЛОГИЧЕСКАЯ) ФУНКЦИЯ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ КОГНИТИВ (ГНОСЕОЛОГИК) ФУНКЦИЯСЕ Телнең төп иҗтимагый функцияләренең берсе: фикерләү һәм танып белү коралы булып хезмәт итүе

**КОГНИЦИЯ** КОГНИЦИЯ Дөньяны танып белүгә караган тою, фикерләү һәм гомумән, белем һәм мәгълүмат алу белән бәйле барлык психик процесслар: белем, аң, фикерләү, күзаллау, иҗат, уйлау, символлаштыру, логик нәтиҗә ясау, хәтерләү, тану һ.б.

**КОДИФИЦИРОВАННЫЙ (ЛИТЕРАТУРНЫЙ) ЯЗЫК** КОДИФИКАЦИЯЛӘНГӘН (ӘДӘБИ) ТЕЛ Әдәби, камиль дәрәҗәдә куллануны тәэмин иткән кагыйдәләргә җавап бирә торган тел

**КОЙНЕ** КОЙНЕ Бер яки берничә диалект нигезендә барлыкка килеп, төрле телләрдә сөйләшүчеләрнең диалектара аралашуы өчен хезмәт итә торган тел

**КОЛИЧЕСТВЕННО-ДИНАМИЧЕСКИЕ СРЕДСТВА ИНТОНАЦИИ** ИНТОНАЦИЯНЕҢ КҮЛӘМ-ДИНАМИКА ЧАРАЛАРЫ Интонациянең физик параметрларын үзгәртү белән бәйле чаралар: тавыш көчен арттыру яки киметү, сөйләм тактының яки фразаның аерым өлешләрен әйтү темпын үзгәртү

**КОЛИЧЕСТВЕННОЕ ВАРЬИРОВАНИЕ (ФРАЗЕОЛОГИЗМОВ)** (ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫҢ) САНЧА ВАРИАЦИЯЛӘНҮЕ Фразеологик берәмлекләрдә, эчтәлегенә зыянсыз рәвештә, компонентлар саны үзгәрү күренеше (мәс., *пустить (красного) петуха*)

**КОЛИЧЕСТВЕННОЕ ЧИСЛИТЕЛЬНОЕ** МИКЪДАР САНЫ Әйбернең санын, микъдарын, төгәл исәбен белдерә торган сан төре

**КОЛИЧЕСТВЕННЫЕ МЕСТОИМЕНИЯ** МИКЪДАР АЛМАШЛЫКЛАРЫ Саннарны алмаштырып килә һәм микъдарга, күләмгә, санга күрсәтә торган алмашлыклар

**КОЛИЧЕСТВЕННЫЕ ОТЛИЧИЯ БЕЗУДАРНЫХ ГЛАСНЫХ** БАСЫМСЫЗ СУЗЫКЛАРНЫҢ КҮЛӘМ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ Басымсыз сузыкларны басымлылардан аерып торган билгеләр (мәс., беренчеләре икенчеләренә караганда кыскарак һәм көчсезрәк әйтеләләр)

**КОЛИЧЕСТВЕННЫЕ СПОСОБЫ ГЛАГОЛЬНОГО ДЕЙСТВИЯ** ФИГЫЛЬ ЭШ-ХӘРӘКӘТЕНЕҢ МИКЪДАР ЫСУЛЛАРЫ Семантикасында эш-хәрәкәтнең кабатлаулы яки бер тапкыр эшләнә торган булуын күрсәткән мәгънәләр (мәс., рус. *рубануть, хаживать*; тат. – ярдәмче фигыльләр, фигыль дәрәҗәләре белән белдерелә)

**КОМБИНАТОРНЫЕ ВАРИАНТЫ ФОНЕМ** ФОНЕМАЛАРНЫҢ КОМБИНАТОР ВАРИАНТЛАРЫ Фонемаларның позициясенә, нинди авазлар белән янәшә килүенә карап үзгәргән вариантлары ( Н.С. Трубецкой термины)

**КОМБИНАТОРНЫЕ ИЗМЕНЕНИЯ ЗВУКОВ** АВАЗЛАРНЫҢ КОМБИНАТОР ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ Авазларның, бер-берсенә карата нинди урында килүенә карап, үзара тәэсир итүләре нәтиҗәсендә була торган аваз үзгәрешләре: ассимиляция, диссимиляция, аккомодация, редукция, метатеза һ.б.

**КОММУНИКАНТ** КОММУНИКАНТ, АРАЛАШУЧЫ Мәгълүмат алмашу, сөйләшү процессында катнашучы кеше

**КОММУНИКАТИВНАЯ ЕДИНИЦА** КОММУНИКАТИВ БЕРӘМЛЕК Мөстәкыйль рәвештә бер хәбәрне белдерү өчен җитәрлек сөйләм өзеге

**КОММУНИКАТИВНАЯ КОМПЕТЕНЦИЯ** КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНТЛЫЛЫК Аралашучы сөйләменең нәтиҗәлелеге өчен җитәрлек белем һәм күнекмәләр; 2) Сөйләшүченең,

аралашу максатыннан чыгып, төрле шартларда тиешле социаль нормаларны һ.б.ш. истә тотып, үзенең телне белүеннән файдалану сәләте

**КОММУНИКАТИВНАЯ НАПОЛНЕННОСТЬ** КОММУНИКАТИВ ТУЛЫЛЫК Җөмләнең, әйтелмәнең объектив чынбарлыктагы ситуацияне чагылдыру үзлеге

**КОММУНИКАТИВНАЯ СИТУАЦИЯ** КОММУНИКАТИВ СИТУАЦИЯ Аралашу ихтыяҗын тудыра һәм катнашучыларның сөйләм рәвешен билгели торган үзара бәйле факторлар системасы

**КОММУНИКАТИВНАЯ УСТАНОВКА** КОММУНИКАЦИЯ БИЛГЕЛӘНЕШЕ Сөйләмнең максаты

**КОММУНИКАТИВНАЯ ФУНКЦИЯ СЛОВА** СҮЗНЕҢ КОММУНИКАТИВ ФУНКЦИЯСЕ Сүзнең аралашу һәм мәгълүмат тапшыру чарасы буларак хезмәт итүе

**КОММУНИКАТИВНАЯ ФУНКЦИЯ ТЕКСТА** ТЕКСТНЫҢ КОММУНИКАТИВ ФУНКЦИЯСЕ Текстның аралашу һәм мәгълүмат тапшыру чарасы буларак хезмәт итүе

**КОММУНИКАТИВНАЯ ФУНКЦИЯ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ КОММУНИКАТИВ ФУНКЦИЯСЕ Телнең иҗтимагый функцияләренең берсе: аралашу чарасы буларак кулланылуы

**КОММУНИКАТИВНОСТЬ** КОММУНИКАТИВЛЫК Сөйләмнең репрезентатив – предметны атау, экспрессив – фикер-хисләрне белдерү, апеллятив – адресатка тәэсир итү кебек төп функцияләренең берсе буларак, аралашу функциясен үтәве

**КОММУНИКАТИВНЫЙ КОНТЕКСТ** КОММУНИКАТИВ КОНТЕКСТ Сөйләмнең турыдан-туры интеллектуаль эчтәлекне тапшыруга бәйле чаралары

**КОММУНИКАТИВНЫЙ СИНТАКСИС** КОММУНИКАТИВ СИНТАКСИС Коммуникатив бурычларны һәм тел берәмлекләре арасындагы мөнәсәбәтләрне истә тотып сөйләмне төзү һәм аның төрле контекстта үзгәрү мәсьәләләрен тикшерә торган юнәлеш

**КОММУНИКАЦИЯ** КОММУНИКАЦИЯ 1) Тел ярләмендә билгеле фикер эчтәлеген хәбәр итү яки тапшыру; аралашу, бер

телдә сөйләшү процессы; 2) Фикердә булган җөмләләр тезмәсен башкаларга тапшыру максаты күздә тотылган үзенчәлекле фикерләү акты: барлык җөмлә төрләренең психологик нигезе

**КОММУТАЦИЯ** КОММУТАЦИЯ Ике берәмлек арасында, аларның билгеле контекстта алмашынуы капма-каршы план берәмлекләренең дә (эчтәлек планы – билгеләү планы) алмашынуына китерә торган мөнәсәбәтләр

**КОММУТАТИВНЫЙ ТЕКСТ** КОММУТАТИВ ТЕКСТ Эчтәлек планы парадигмасы белән билгеләү планы парадигмасы арасында мөнәсәбәт урнаштыра торган текст

**КОМОНОМИКА** КОМОНОМИКА Топонимиканың авыл исемнәрен өйрәнә торган тармагы

**КОМПАРАТИВ** КОМПАРАТИВ Чагыштыру дәрәҗәсе

**КОМПАРАТИВИСТИКА** КОМПАРАТИВИСТИКА *к.* **компаративная лингвистика**

**КОМПАРАТИВИСТЫ** КОМПАРАТИВИСТЛАР Компаратив лингвистика өлкәсендә эшләгән тел галимнәре: Ф. Бопп, Р. Раск, Я. Гримм һ.б.

**КОМПАРАТИВНАЯ ЛИНГВИСТИКА** КОМПАРАТИВ ТЕЛ БЕЛЕМЕ Бер семьялыкка караган, кардәш телләрне тарихи-чагыштырма планда өйрәнә торган фән тармагы

**КОМПЕТЕНЦИЯ** КОМПЕТЕНЦИЯ Генератив грамматикада төп төшенчәләрнең берсе: үз телен реаль белү дәрәҗәсе

**КОМПОНЕНТНЫЙ АНАЛИЗ** КОМПОНЕНТЛАП АНАЛИЗЛАУ Тел берәмлегенең телнең бер дәрәҗәсенә караган берәмлекне башка дәрәҗә берәмлегеннән аерырлык өлешләрен (компонентларын) билгеләү

**КОМПРЕССИВНОЕ СЛОВООБРАЗОВАНИЕ** КОМПРЕССИВ СҮЗЪЯСАЛЫШЫ Ясагыч сүзне яки сүзтезмәне гадирәк формалы сүз дәрәҗәсенә кадәр «кысу» максатыннан сүз ясау (мәс., *библиотека им. Ленина – ленинка, читальный зал – читалка* һ.б.)

**КОМПРЕССИЯ** КОМПРЕССИЯ Бер үк мәгънәне белдерү өчен сөйләм чараларының экономрак, кыскарак формаларыннан файдалану

**КОНАТИВНЫЙ** КОНАТИВ Сөйләм адресатына юнәлтелгән, адресатны истә тоткан

**КОНВЕНЦИИ** КОНВЕНЦИЯЛӘР *к.* **норма**

**КОНВЕРГЕНЦИЯ ЗВУКОВ** АВАЗЛАР КОНВЕРГЕНЦИЯСЕ Авазларның охшаш билгеләре артуга, хәтта аларның тәңгәлләшүенә китерә торган үзгәреш

**КОНВЕРСИВНЫЕ (ВЕКТОРНЫЕ) АНТОНИМЫ** КОНВЕРСИВ (ВЕКТОРЛЫ) АНТОНИМНАР Төрле юнәлештәге эш-хәрәкәт яки билгеләрнең капма-каршылыгын белдерә торган антонимнар

**КОНВЕРСИВЫ** КОНВЕРСИВЛАР *к.* **конверсивные антонимы**

**КОНВЕРСИЯ** КОНВЕРСИЯ Бер сүз төркеменә караган сүзнең башка сүз төркеменә күчүеннән гыйбарәт сүз ясалу ысулы

**КОНГЛОМЕРАТ** КОНГЛОМЕРАТ Тел берәмлекләренең ияртүле, градацион һ.б. мөнәсәбәтләргә кермичә килгән очрак, аларның гади җыелмасы (мәс., тезүле бәйләнештәге сүзләр, әмма һәрвакыт түгел)

**КОНГЛОМЕРАТНАЯ ВЫБОРКА** КОНГЛОМЕРАТЛЫ САЙЛАНЫШ Ассоциатив экспериментта төрле информантлардан алынган җавапларның гади җыелмасы

**КОНДИЦИОНАЛИС** КОНДИЦИОНАЛИС, ШАРТ ФИГЫЛЬ Икенче бер эшнең үтәлүенә шарт булган эш яки хәлне белдерә торган фигыль формасы

**КОНКРЕТНОЕ ИМЯ** КОНКРЕТ ИСЕМ Чынбарлыкта булган реаль затны, предметны яки күренешне белдергән исем

**КОНКРЕТНЫЙ АКТ РЕЧИ** КОНКРЕТ СӨЙЛӘМ АКТЫ Коммуникация процессында катнашкан теләсә кайсы затның ике яктан тынлык белән чикләнгән сөйләм кисәге

**КОНКУРЕНЦИЯ ВИДОВ** ВИДЛАР КОНКУРЕНЦИЯСЕ Бер үк ситуацияләрне тасвирлау өчен ике вид фигыльләрдән дә файдалану мөмкинлеге (мәс., *Он обычно приходил и садился.* – несов.; *Он обычно придет и сядет.* – сов.)

**КОННОТАТИВНЫЕ СЕМЫ** КОННОТАТИВ СЕМАЛАР Төп денотатив мәгънәгә өстәмә, функциональ-стилистик һәм эмоциональ-экспрессив төсмер бирә торган мәгънәләр

**КОННОТАЦИИ** КОННОТАЦИЯЛӘР Сүзнең өстәмә мәгънәләре, аның төп мәгънәсенә кушылып, төрле эмоциональ-экспрессив төсмерләр яки стилистик мәгънәләр барлыкка китерә торган нюанслар; *к. ш. ук* **потенции**

**КОНСОНАНТИЗМ** КОНСОНАНТИЗМ Бер телнең тартыклар системасы, шул телдәге тартыкларның үзенчәлекләре һәм үзара мөнәсәбәтләре

**КОНСОНАНТНОСТЬ-НЕКОНСОНАНТНОСТЬ** КОНСОНАНТЛЫЛЫК-КОНСОНАНТСЫЗЛЫК Фонологиядә тартык авазларны бәяләүнең бер билгесе буларак шаулылык-шаусызлык

**КОНСТАНТЫ КУЛЬТУРЫ** КУЛЬТУРА КОНСТАНТАЛАРЫ Бик борынгы чорда барлыкка килеп, тарих буенча барлык фикер ияләренең яки гади сөйләшүчеләрнең карашларында чагылыш тапкан концептлар, үзгәрми торган концептлар

**КОНСТЕЛЛЯЦИЯ** КОНСТЕЛЛЯЦИЯ 1) Глоссемантикада, Л. Ельмслев классификациясендә: тел берәмлекләре арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзара бәйле элементлар һәм бергә, һәм мөстәкыйль рәвештә килә ала торган төре, берсе икенчесеннән башка яши ала торган ирекле бәйлелек (мәс., рус. *пишу – пишет* – зат бар, род юк; *писал – писала* – зат юк, род бар); 2) тезүле бәйләнеш яки янәшәлек (мәс., рус. фигыль белән рәвеш арасындагы бәйләнеш)

**КОНСТИТУТИВНЫЕ ПРИЗНАКИ ФОНЕМ** ФОНЕМАЛАРНЫҢ КОНСТИТУТИВ БИЛГЕЛӘРЕ Фонемаларны берберсеннән аера торган төп билгеләре, дифференциаль билгеләр

**КОНСТРУКТИВНАЯ ФУНКЦИЯ МОРФЕМЫ** МОРФЕМАНЫҢ КОНСТРУКТИВ ФУНКЦИЯСЕ Морфеманың сүзгә карата төзелеш элементлары функциясен үтәве

**КОНСТРУКТИВНОЕ (СИНТАКСИЧЕСКОЕ) СЛОВООБРАЗОВАНИЕ** КОНСТРУКТИВ (СИНТАКСИК) СҮЗ ЯСАЛЫШЫ Сөйләм структурасын үзгәртү максатыннан сүз ясау (мәс., *приезжать* урынына *приезд* сүзе ясалса, җөмлә структурасы үзгәрә)

**КОНСТРУКТИВНЫЙ СИНТАКСИС** КОНСТРУКТИВ СИНТАКСИС Синтаксисның сүзләр арасындагы бәйләнеш төрләрен, сүзләрнең үзара бәйләнү мөмкинлекләрен, җөмләнең эчке төзелешен өйрәнә торган тармагы

**КОНСТРУКЦИЯ** КОНСТРУКЦИЯ, ТӨЗЕЛМӘ Мәгънә белдергән теләсә нинди сүзләр яки морфемалар төркеме

**КОНТАКТИРУЮЩИЕ ЯЗЫКИ** КОНТАКТКА КЕРГӘН ТЕЛЛӘР Сөйләшүчеләре төрле тарихи, географик, дини һ.б. сәбәпләр аркасында бергә яки янәшә яшәп, бер-берсенә йогынты ясаган телләр

**КОНТАМИНАЦИЯ** КОНТАМИНАЦИЯ Ассоциатив яки синтагматик яктан бериш берәмлекләрнең семантик яки формаль үзгәрүенә, яки өченче берәмлек ясалуга китерә торган үзара бәйлелек

**КОНТАМИНИРОВАННЫЙ** КОНТАМИНАЦИЯЛЕ Контекст белән бәйле, контексттан килеп чыккан

**КОНТЕКСТУАЛЬНЫЕ ВАРИАНТЫ ФОНЕМ** ФОНЕМАЛАРНЫҢ КОНТЕКСТУАЛЬ ВАРИАНТЛАРЫ (А. Мартине термины); *к.* **комбинаторные варианты фонем**

**КОНТЕНСИВНАЯ ТИПОЛОГИЯ** КОНТЕНСИВ ТИПОЛОГИЯ Типологик лингвистикада телләрнең семантик категорияләрен һәм аларны белдерү чараларын өйрәнә торган агым

**КОНТИНУАТИВ** КОНТИНУАТИВ Эш-хәрәкәтне конкрет үтәлеш моментына бәйле рәвештә атый торган фигыль формасы, прогрессив (мәс., инглиз телендә)

**КОНТРАДИКТОРНЫЕ (ПРОТИВОРЕЧАЩИЕ, КОМПЛЕМЕНТАРНЫЕ) АНТОНИМЫ** КОНТРАДИКТОР (КАПМА-КАРШЫ, КОМПЛЕМЕНТАР) АНТОНИМНАР Төшенчәне билгеләгәндә урталыктагы, арадашчы элементы булмаган, бер ыру төшенчәсен тәшкил иткән ике төр төшенчәсе (мәс., *борын төбендә – җәһәннәм кырыенда*)

**КОНТРАСТ** КОНТРАСТ Телнең бер үк дәрәҗәсенә караган, әмма интегратив функцияләре белән аерылып торган берәмлекләре арасындагы мөнәсәбәт

**КОНТРАСТИВНАЯ ЛИНГВИСТИКА** КОНТРАСТИВ ТЕЛ БЕЛЕМЕ Тел белеменең кардәш булмаган, төрле типтагы телләрне чагыштырып өйрәнә торган тармагы

**КОНТРАСТИВНЫЙ МЕТОД** КОНТРАСТИВ АЛЫМ Тел күренешләрен кардәш булмаган телләрне чагыштыру аша өйрәнү алымы

**КОНТРАСТИВНЫЙ СИНТАКСИС** КОНТРАСТИВ СИНТАКСИС Тел белеменең төрле типтагы телләрнең синтаксисын чагыштырып өйрәнә торган бүлеге

**КОНТРАСТНАЯ ДИСТРИБУЦИЯ** КОНТРАСТЛЫ ДИСТРИБУЦИЯ Ике тел берәмлеге (фонема, морфема) бер үк шартларда килеп, сүзләрнең аваз тышчасын һәм мәгънәләрен үзгәртү, тыңлаучыда төрле реакция тудыру күренеше (мәс., фонетика дәрәҗәсендә татар телендә *бул – бүл*)

**КОНФИКС** КОНФИКС (Н.В. Юшманов термины) Сүзьясагыч нигезгә берьюлы ике урыннан – алдан һәм арттан – ялгана торган катлаулы морфема, циркумфиксның бер төре

**КОНФИКСАЛЬНЫЕ СТРУКТУРЫ** КОНФИКСАЛЬ СТРУКТУРАЛАР Конфикслау ысулы белән төзелгән сүзләр

**КОНФИКСАЦИЯ** КОНФИКСАЦИЯ, КОНФИКСЛАУ Конфикс ярдәмендә сүз ясау: борынгы рус телендә XIV гасырдан алып актив кулланылган сүз ясау ысулы

**КОНФОРМНОСТЬ** КОНФОРМЛЫК Охшашлык, уртаклык

**КОНЦЕПТ** КОНЦЕПТ Когнитив лингвистиканың төп төшенчәләренең берсе: кеше аңында аның халкына хас булган милли, культур күзаллауны чагылдырган менталь образлар һәм аларның телдәге исемнәре; сүзне тәшкил иткән барлык мәгънәләр

**КОНЦЕПТОГРАФИЯ** КОНЦЕПТОГРАФИЯ Дөнья картинасын тәшкил иткән концептлар системасын сүзлектә чагылдыру мәсьәләләре белән шөгыльләнә, яңа гына үсеп килә торган тел белеме тармагы, төп вәкиле Ю.Н. Караулов

**КОНЦЕПТОСФЕРА** КОНЦЕПТЛАР СФЕРАСЫ Бер телдә сөйләшүчеләрнең мөмкин булган барлык концептларыннан тор-

ган, миллэт өчен гомуми концептлар җыелмасы, концептлар системасы (*термин 1993 елда Д.С. Лихачев тарафыннан кертелә*); *к. ш. ук* **картина мира**

**КОНЦЕПТУАЛИЗАЦИЯ** КОНЦЕПТЛАШУ, КОНЦЕПТЛАШТЫРУ Телгә карамаган, экстралингвистик характердагы теләсә нинди яңа мәгълүматны менталитет дәрәҗәсендә кабул итү, аңлау һәм тел чаралары белән билгеләү; концептлар, концептуаль структуралар һәм гомумән концептлар сферасы барлыкка килү процессы

**КОНЦЕПТУАЛЬНАЯ КАРТИНА МИРА** КОНЦЕПТУАЛЬ ДӨНЬЯ КАРТИНАСЫ Дөньяны күзаллауның гомумкешелек, милли һәм шәхси карашлардан торган дөнья картинасы

**КОНЦЕПТУАЛЬНАЯ СИСТЕМА** КОНЦЕПТУАЛЬ СИСТЕМА, КОНЦЕПТЛАР СИСТЕМАСЫ Кеше аңында булган һәм аның шәхси тәҗрибәсен чагылдырган барлык концептларның тулы, эзлекле системасы

**КООРДИНАТИВНОЕ ДВУЯЗЫЧИЕ** КООРДИНАТИВ ИКЕТЕЛЛЕЛЕК Ике телне дә абсолют иркен белү, сөйләшкән телдә фикер йөртә алу сәләте

**КОПЕНГАГЕНСКИЙ СТРУКТУРАЛИЗМ** КОПЕНГАГЕН СТРУКТУРАЛИЗМЫ Структур тел белеменең чиктән тыш теорияләштерү, телдән, конкрет гамәли бурычлардан тулысынча читләшү белән аерылып торган агымы; *к. ш. ук* **глоссемантика**

**КОРЕНЬ** ТАМЫР Сүзнең ясалма булмаган, ягъни составында хәзерге тел карашыннан бернинди өстәмә аффиксы булмаган һәм тарихи яктан этимон булып торган гади нигезе

**КОРНЕВАЯ МОРФЕМА** ТАМЫР МОРФЕМА Сүзнең төп лексик мәгънәсе салынган минималь базасы, сүзнең иң кечкенә кисәге

**КОРНЕВОЕ СЛОВО** ТАМЫР СҮЗ Нигезе тамыры белән тәңгәл килә торган сүз, ягъни составында аффиксаль яки ялгагыч элементларны аерып чыгару мөмкин булмаган сүз

**КОРНЕВЫЕ ЯЗЫКИ** ТАМЫРЛЫ ТЕЛЛӘР Аффикслар ярдәмендә ясалган сүзләр булмаган, сүзләр тамыр белән тәңгәл

булган, ә телләр (мәс. кытай, сиам һ.б.); *к. ш. ук* **изолирующие языки**

**КОРРЕЛЯТИВЫ** КОРРЕЛЯТИВЛАР Кайчандыр телдә булган, ә хәзерге вакытта «үле» закончалыклар нигезендә барлыкка килгән тарихи чиратлашу очраклары (мәс., русчада *врата – вращать*, хәзерге чорда *т/щ* чиратлашуы булмас иде, чөнки икесе дә бер позициядә)

**КОРРЕЛЯТ** КОРРЕЛЯТ Үзара бәйле тел берәмлекләре рәтендә яки парында берсе

**КОРРЕЛЯЦИОННАЯ СВЯЗЬ** КОРРЕЛЯЦИОН БӘЙЛӘНЕШ Бәйле берәмлекләр бергә ярашып үзгәрү күренеше

**КОРРЕЛЯЦИОННЫЙ АНАЛИЗ** КОРРЕЛЯЦИОН АНАЛИЗ Корреляция очракларын, корреляцион бәйләнешләрне ачыклый торган анализ

**КОРРЕЛЯЦИЯ** КОРРЕЛЯЦИЯ Тел берәмлекләренең бер яки берничә билге буенча охшашлык-аермалылык нигезендә үзара бәйлелеге

**КОСВЕННАЯ РЕЧЬ** КЫЕК СӨЙЛӘМ Чит сөйләмне автор, сөйләүче исеменнән җиткерү ысулы

**КОСВЕННО-ВОЗВРАТНЫЕ ГЛАГОЛЫ** КЫЕК КАЙТЫМЛЫ ФИГЫЛЬЛӘР Субъектның үз мәнфәгатеннән чыгып үтәгән эш-хәлне белдерә торган кайтымлы фигыльләр (мәс., рус. *укладываться, строиться*; тат. *чистарыну, бизәнү-ясану*)

**КОСВЕННОЕ ДОПОЛНЕНИЕ** КЫЕК ТӘМАМЛЫК Күчемсез фигыльгә ияреп килгән тәмамлык

**КОСВЕННО-НОМИНАТИВНОЕ ЗНАЧЕНИЕ СЛОВА** СҮЗНЕҢ КЫЕК НОМИНАТИВ МӘГЪНӘСЕ *к.* **переносное значение слова**

**КОСВЕННЫЕ ПАДЕЖИ** КЫЕК КИЛЕШЛӘР Баш килештән башка килешләр

**КРАСИС** КРАСИС Янәшә килгән ике сузыкның бер гади сузыкка әйләнү күренеше, русчасы: стяжение

**КРАТКАЯ ФОРМА ПРИЛАГАТЕЛЬНОГО** СЫЙФАТНЫҢ КЫСКА ФОРМАСЫ Рус телендә асыл сыйфатларның килеш

белән төрләнми торган, туры формалардан кайбер морфологик, семантик, синтаксик үзенчәлекләр белән аерылып торган формасы (мәс., *горазд, надобен, великоват* һ.б.)

**КРАТКИЕ ГЛАСНЫЕ** КЫСКА СУЗЫКЛАР Сөйләм темпы бер үк дәрәҗәдә булганда озын сузык белән чагыштырганда кыскарак әйтелгән сузыклар

**КРАТНЫЕ СПОСОБЫ ГЛАГОЛЬНОГО ДЕЙСТВИЯ** ФИГЫЛЬ ЭШ-ХӘРӘКӘТЕНЕҢ КАБАТЛАУЛЫ ЫСУЛЛАРЫ *к.* **количественные способы глагольного действия**

**КРИПТОНИМ** КРИПТОНИМ Шәһәр, урын, әйбер һ.б. шундыйларның (ләкин кешенең түгел) уйдырма, шифрланган атамасы

**КРИПТОТИПЫ** КРИПТОТИПЛАР Б. Уорф классификациясендә: сүзләрнең күзгә күренеп тормаган билгеләре, ягъни конкрет морфологик күрсәткечләре булмаган класслары (мәс., рус телендә *в* һәм *на* предлогларын куллану конкрет морфологик үзенчәлеккә бәйле түгел)

**КРЫЛАТЫЕ СЛОВА** КАНАТЛЫ СҮЗЛӘР Билгеле әдәби чыганактан яки тарихи шәхесләрнең теленнән кулланылышка кергән тотрыклы гыйбарәләр

**КУЛЬМИНАТИВНАЯ ФУНКЦИЯ УДАРЕНИЯ** БАСЫМНЫҢ КУЛЬМИНАТИВ ФУНКЦИЯСЕ Басымның барлык төр басымнар өчен дә уртак булган, сүзнең тулылыгын һәм аерымлыгын тәэмин итү функциясе

**КУЛЬТУРА РЕЧИ** СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ Телдә кабул ителгән әйтелеш, сүзләрне куллану һ.б.ш. кагыйдәләргә туры килү дәрәҗәсе, индивидуаль сөйләмдә әлеге кагыйдәләрне үтәү сәләте

**КУЛЬТУРНАЯ ЗНАЧИМОСТЬ** КУЛЬТУР ӘҺӘМИЯТ Культур белемнең концептлашу һәм категорияләшү аспектларын чагылдырган тел берәмлекләре арасындагы семантик мөнәсәбәтләр

**КУЛЬТУРНАЯ КОННОТАЦИЯ** КУЛЬТУР КОННОТАЦИЯ Бер реалиянең һәм аны белдергән берәмлекнең билгеле бер телдә сөйләшүче халык тарафыннан кулланылуы яки турыдан-

туры шушы культурага караган концептуаль берәмлекләр эчке форма белән тәңгәлләштерелү нәтиҗәсендә барлыкка килгән тотрыклы семантик билге

**КУЛЬТУРНЫЕ СЕМЫ** КУЛЬТУР СЕМАЛАР Сүздән кечерәк һәм гомумирәк, универсальрәк характердагы семантик берәмлекләрнең, семантик билгеләрнең культур фонга караган өлеше

**КУЛЬТУРНЫЕ УНИВЕРСАЛИИ** КУЛЬТУР УНИВЕРСАЛИЯЛӘР Чынбарлыкның әдәби текстта чагылыш тапкан, халык культурасы, традицияләре өчен әһәмиятле дип исәпләнгән һәм барлык культуралар өчен дә гомуми булган элементлары (мәс., тел, мифлар, бию һ.б.)

**КУЛЬТУРНЫЙ ФОН** КУЛЬТУР ФОН Социаль тормыш күренешләрен, тарихи вакыйгаларны һ.б.ш. белдергән номинация берәмлекләренең (сүзләр һәм фразеологизмнарның) мәгънә үзенчәлеге

**КУЛЬТУРОЛОГИЯ** КУЛЬТУРОЛОГИЯ Концептлар барлыкка килүендә һәм яшәешендә культураның ролен тикшерә торган фән

# Л

**ЛАБИАЛИЗАЦИЯ** ЛАБИАЛЬЛӘШҮ *к.* **огубление**

**ЛАБИАЛИЗОВАННЫЕ ГЛАСНЫЕ** ИРЕНЛӘШКӘН СУЗЫКЛАР Әйтелешендә иреннәр катнашу белән аерылган сузыклар (мәс. *у, ү, о, ө* иреннәр түгәрәкләнеп алга таба сузыла)

**ЛАБИАЛИЗОВАННЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ИРЕНЛӘШКӘН ТАРТЫК Резонатор тоны түбәнәйгән тартык (мәс., *сөт* дигәндә ирен сузыгы *ө* алдыннан *с* да иренләшү күренеше)

**ЛАБИАЛЬНЫЕ ГЛАСНЫЕ** ЛАБИАЛЬ СУЗЫКЛАР *к.* **огубленные гласные**

**ЛАБИОДЕНТАЛЬНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ЛАБИОДЕНТАЛЬ ТАРТЫКЛАР, ИРЕН-ТЕШ ТАРТЫКЛАРЫ Артикуляциясендә

ирен һәм теш катнаша торган тартыклар (мәс., *ф, в* тартыкларын әйткәндә аскы ирен өске кискеч тешләргә таба хәрәкәт итә)

**ЛАКОНИЧНАЯ РЕЧЬ** ЛАКОНИК СӨЙЛӘМ Кыска, анык һәм ачык сөйләм

**ЛАЛЕТИКА** ЛАЛЕТИКА Тел белеменең сөйләм телен өйрәнә торган тармагы

**ЛАРИНГАЛИЗАЦИЯ** ЛАРИНГАЛИЗАЦИЯ Сөйләм авазлары ясалышында актив орган бугаз булып, шунда һава агымы тоткарланып ясалу ысулы (мәс., татар телендә, бугаздагы тавыш ярыларының шартлап ачылуы нәтиҗәсендә ясала торган «һәмзә» тартыгы – *маэмай, тәэсир* һ.б.)

**ЛАРИНГАЛЬНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ЛАРИНГАЛЬ ТАРТЫКЛАР *к.* **гортанный звук**

**ЛАСКАТЕЛЬНАЯ ФОРМА** ИРКӘЛӘҮ-КЕЧЕРӘЙТҮ ФОРМАСЫ Иркәләү-кечерәйтү кушымчасы алып экспрессив төсмер алган исем

**ЛАСКАТЕЛЬНЫЙ АФФИКС** ИРКӘЛӘҮ-КЕЧЕРӘЙТҮ КУШЫМЧАСЫ Исемнәргә экспрессив төсмер бирә торган кушымча; нинди дә булса кечкенә әйбергә яки якын кешегә нечкә хисләрне белдерү өчен кулланыла (мәс., рус телендә *-ок – листок; флажок -ик – домик;* татар телендә *-чык/-чек – кошчык, йолдызчык*)

**ЛАТЕНТНЫЙ** ЛАТЕНТ Реаль күренеп тормаган, әмма бу системада очравын аңлатырга мөмкин булган, потенциаль (мәс., *латент аваз, латент лексик мәгънә*)

**ЛАТЕРАЛЬНЫЙ СОГЛАСНЫЙ** ЛАТЕРАЛЬ ТАРТЫК Ян як тартык аваз; сөйләм авазлары ясалышында тел очы пассив органга килеп терәлеп, һава агымы телнең ян-якларыннан үтеп ясала торган аваз (*л* авазын әйткәндә тел өске тешләргә терәлә)

**ЛАТИВ** ЛАТИВ Эш-хәрәкәтнең максатка юнәлдерелүен белдергән рус телендәге винительный килеш формасы

**ЛАТИНИЗМ** ЛАТИНИЗМ Латин теленнән алынган сүз яки гыйбарә

**ЛАТИНИЦА** ЛАТИНИЦА Латин алфавитына нигезләнгән графика

**ЛЕКСЕМА** ЛЕКСЕМА Телдәге сүзлек составы берәмлеге; бер лексемага мөстәкыйль мәгънәгә ия булган бер сүзнең барлык төр парадигматик формалары (мәс., *бакча, бакчага, бакчадан*) һәм контекст эчендә барлыкка килә торган мәгънә төрләре (мәс., *кәтүк* сүзенең туры һәм күчерелмә мәгънәләре) берләшә

**ЛЕКСИКА** ЛЕКСИКА 1) Нинди дә булса телнең сүзлек составы; 2) Кулланылыш сферасы, килеп чыгышы, стиль ягыннан бүленеше буенча уртак яки аерым авторга гына хас булган сүзләр җыелмасы (мәс., *фәнни лексика, диалекталь лексика, алынма лексика* һ.б.)

**ЛЕКСИКА ОГРАНИЧЕННОГО УПОТРЕБЛЕНИЯ** ЧИКЛӘНГӘН КУЛЛАНЫЛЫШТАГЫ ЛЕКСИКА Телнең хәзерге хәлендә көндәлек тормышта аз кулланылган лексика; ул берничә төркемне билгели: түбән кулланылыш ешлыклы – пассив лексика; куллану периоды буенча – искергән сүзләр һәм неологизмнар; хезмәт һәм иҗат эшчәнлеген чагылдыру характеры буенча – терминология һәм профессиональ лексика; социаль гомум кабул ителеше буенча – жаргон һәм арго

**ЛЕКСИКАЛИЗАЦИЯ** ЛЕКСИКАЛИЗАЦИЯ, ЛЕКСИКАЛАШУ Кушма сүз ясалуның бер ысулы буларак сүзтезмәнең тел берәмлегенә әйләнүе

**ЛЕКСИКОГРАФИЯ** ЛЕКСИКОГРАФИЯ 1) Сүзлек төзү эше; басылып чыккан сүзлекләр тупламасы; 2) Сүзлекләр төзү теориясен һәм практикасын өйрәнә торган тел гыйлеме тармагы

**ЛЕКСИКО-ГЕНЕТИЧЕСКИЙ АНАЛИЗ** ЛЕКСИК-ГЕНЕТИК АНАЛИЗ Чагыштырма-тарихи метод ярдәмендә сүзнең килеп чыгышын, чыганак телен билгеләгән анализ

**ЛЕКСИКО-ГРАММАТИЧЕСКИЙ** ЛЕКСИК-ГРАММАТИК Лексик һәм грамматик үзлекләрнең бердәмлегенә нигезләнгән

**ЛЕКСИКО-ГРАММАТИЧЕСКИЙ НЕОЛОГИЗМ** ЛЕКСИК-ГРАММАТИК НЕОЛОГИЗМ Телнең үз лексик һәм грамма-

тик чараларына нигезләнеп ясалган яңа сүзләр (мәс., *кәсәбәчелек, иминиятләү* һ.б.)

**ЛЕКСИКОЛОГИЯ** ЛЕКСИКОЛОГИЯ Телдәге сүзлек составын, аларның мәгънәләрен, килеп чыгышын, кулланыш өлкәләрен өйрәнә торган тел гыйлеме тармагы

**ЛЕКСИКОН** ЛЕКСИКОН 1) *иск.* Сүзлек; 2) Билгеле бер даирә кешеләренә хас булган, яки аерым бер кеше генә куллана торган сүзләр җыелмасы

**ЛЕКСИКО-СЕМАНТИЧЕСКИЙ АНАЛИЗ** ЛЕКСИК-СЕМАНТИК АНАЛИЗ Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен, синоним, омоним, антонимнарын тикшерү

**ЛЕКСИКО-СЕМАНТИЧЕСКИЙ СПОСОБ СЛОВООБРАЗОВАНИЯ** СҮЗЬЯСАЛЫШЫНЫҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ЫСУЛЫ Алдан билгеле сүзләргә күчерелмә яңа мәгънә өстәү юлы белән омонимнар барлыкка китереп, яңа сүзләр ясау (мәс., *билге* – тамга, *билге* – знак, значок, *билге* – бәя; *бәйге* – ат чабышы; *бәйге* – теләсә нинди ярыш)

**ЛЕКСИКО-СИНТАКСИЧЕСКИЙ СПОСОБ СЛОВООБРАЗОВАНИЯ** СҮЗЬЯСАЛЫШЫНЫҢ ЛЕКСИК-СИНТАКСИК ЫСУЛЫ Ике яки берничә лексик берәмлекнең синтаксик бәйләнешләре нигезендә барлыкка килә торган кушма сүзләр ясалышы (мәс., *бу+көн – бүген, үги ана яфрагы* һ.б.)

**ЛЕКСИКОСТАТИСТИЧЕСКИЙ МЕТОД** ЛЕКСИКОСТАТИК МЕТОД Лексик тәңгәллелекне яки аермалылыкны ачыклау өчен кулланыла торган статистик метод

**ЛЕКСИКО-ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИЙ** ЛЕКСИК-ФРАЗЕОЛОГИК Сүзләрнең семантик яктан үзара ярашуына караган, лексик мәгънәләре ягыннан бер-берсенә ялгану сәләте булган яки булмаган

**ЛЕКСИКО-ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКАЯ ФОРМА СЛОВА** СҮЗНЕҢ ЛЕКСИК-ФРАЗЕОЛОГИК ФОРМАСЫ Сүзнең өстәмә мәгънә төсмере белән билгеләнгән семантик варианты (мәс., *аклар шахмат* сүзе белән килгәндә «кара фигуралар түгел», *гаскәр* сүзе белән килгәндә «кызыл гаскәр түгел»)

**ЛЕКСИЧЕСКАЯ АБСТРАКЦИЯ** ЛЕКСИК АБСТРАКЦИЯ 1) Сүзнең чынбарлыктагы конкрет бер предметны гына түгел, ә үз ишеләренең барлык төрләрен дә гомумиләштереп күрсәтү үзлеге; 2) Сүзнең чынбарлыктагы матди булмаган күренешләрне, мөнәсәбәтләрне, билгеләрне һ.б.ш. белдерүе; *чаг.*: **грамматическая абстракция**

**ЛЕКСИЧЕСКИЕ ДИАЛЕКТИЗМЫ** ЛЕКСИК ДИАЛЕКТИЗМНАР Аерым үзгә сүз кулланылган диалектизм

**ЛЕКСИЧЕСКИЙ НЕОЛОГИЗМ** ЛЕКСИК НЕОЛОГИЗМ Телдә кулланышка кереп киткән яңа барлыкка килгән һәм шулай ук чит телләрдән кергән яңа сүзләр: *күксөзәр, йолдызнамә, инвестиция, маркетинг, бартер һ.б.*

**ЛЕКСИЧЕСКИЙ ФОНД** ЛЕКСИК ФОНД Теләсә нинди телнең төп сүзлек байлыгы

**ЛЕКСИЧЕСКОЕ ГНЕЗДО** ЛЕКСИК ОЯ Бер тамырдан ясалган сүзләрне бергә туплап бирү ысулы

**ЛЕКСИЧЕСКОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ЛЕКСИК МӘГЪНӘ Сүз нигезендәге авазлар комплексының чынбарлыктагы аерым предмет, күренеш, эш-хәлләргә, билгегә тиңләштерелгән төшенчәсе; сүзнең эчтәлеге, шул эчтәлектә чынбарлыкның чагылышы

**ЛИГАТУРА** ЛИГАТУРА Ике транскрипция тамгасын яки ике хәреф элементларын берләштереп ясалган транскрипция тамгасы яки хәрефе (мәс., *æ, ө, ү* һ.б.ш.)

**ЛИМИТАТИВ** ЛИМИТАТИВ Объект килешләренең берсе

**ЛИНГВИСТИКА** ЛИНГВИСТИКА, ТЕЛ ГЫЙЛЕМЕ Телнең яшәү һәм үсү закончалыкларын өйрәнә торган фән; аның тармаклары: фонетика, лексикология, морфология, синтаксис һ.б.

**ЛИНГВИСТИЧЕСКАЯ ГЕОГРАФИЯ** ЛИНГВИСТИК ГЕОГРАФИЯ Тел күренешләренең территориаль таралышын өйрәнә торган, ареаль лингвистика белән тыгыз бәйләнгән тел белеменең бер бүлеге

**ЛИНГВИСТИЧЕСКАЯ ЕДИНИЦА** ЛИНГВИСТИК БЕРӘМЛЕК Лингвистик модель – фәнни-теоретик төзелеш элементы

**ЛИНГВИСТИЧЕСКАЯ ОТНОСИТЕЛЬНОСТЬ** ЛИНГВИСТИК НИСБӘТЛЕЛЕК Төрле телләрнең семантик бөтенлегендә абсолют чынбарлыкның төрлечә анализлануы турындагы теория

**ЛИНГВИСТИЧЕСКАЯ ПАЛЕОНТОЛОГИЯ** ЛИНГВИСТИК ПАЛЕОНТОЛОГИЯ Телнең борынгы чорындагы сүзлек составыннан һәм башка үзенчәлекләреннән шул телдә беренчел сөйләшкән халыкның яшәү рәвешен, тормыш шартларын, фикерләү үзенчәлекләрен торгызуны, әлеге халыкның территориаль таралышын билгеләүне максат итеп куйган тел гыйлеме бүлеге

**ЛИНГВИСТИЧЕСКАЯ СТАТИСТИКА** ЛИНГВИСТИК СТАТИСТИКА Тел системасын һәм сөйләм материалын тикшерүдә статистика методларын куллану, телдәге һәм сөйләмдәге закончалыкларның ешлыгын шул методка нигезләнеп санап өйрәнү

**ЛИНГВИСТИЧЕСКАЯ ФАЗА** ЛИНГВИСТИК ФАЗА Үсеш дәверендә бер-берсен алмаштырып килгән чорлардагы тел үзенчәлекләре халәте

**ЛИНГВИСТИЧЕСКАЯ ХАРАКТЕРОЛОГИЯ** ЛИНГВИСТИК ХАРАКТЕРОЛОГИЯ Гомум тел белеме законнары нигезендә телне синхрониядә тасвирлау

**ЛИНГВИСТИЧЕСКАЯ ЭКОНОМИЯ** ЛИНГВИСТИК ЭКОНОМИЯ Сөйләүченең сөйләмне кыскартырга омтылуы; бу телдә үзгәрешләр, бигрәк тә фонетик үзгәрешләр китереп чыгаруның бер сәбәбе булып тора

**ЛИНГВИСТИЧЕСКИЙ АСПЕКТ** ЛИНГВИСТИК АСПЕКТ, ИҖТИМАГЫЙ, ФУНКЦИОНАЛЬ АСПЕКТ Фонетикада: авазларны төрле мәгънәләргә ия булган, аралашу өчен хезмәт итә торган берәмлекләр буларак тикшерү аспекты, тикшеренүләрнең бер ягы

**ЛИНГВИСТИЧЕСКИЙ МЕТОД** ЛИНГВИСТИК МЕТОД Телне тикшерүдә кулланылган алымнар җыелмасы

**ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ** ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ Тел һәм мәдәниятның үзара мөнәсәбәтләрен өйрәнә торган фән

**ЛИНГВОГНОСЕОЛОГИЯ** ЛИНГВОГНОСЕОЛОГИЯ Телнең танып белү функциясен өйрәнә торган фән

**ЛИНГВОПРАКСИОЛОГИЯ** ЛИНГВОПРАКСИОЛОГИЯ Кешенең үз-үзен тотышында телнең ролен өйрәнә торган фән

**ЛИНГВОПСИХОЛОГИЯ** ЛИНГВОПСИХОЛОГИЯ Сөйләм эшчәнлеген өйрәнү теориясе

**ЛИНГВОЭКОЛОГИЯ, ЛИНГВИСТИЧЕСКАЯ ЭКОЛОГИЯ** ЛИНГВОЭКОЛОГИЯ, ЛИНГВИСТИК ЭКОЛОГИЯ Тел үсешенә, сафлыгына тискәре йогынты ясый торган күренешләрне өйрәнүне максат итеп куйган юнәлеш

**ЛИНЕЙНОСТЬ** СЫЗЫЛМАЛЫЛЫК Сөйләм бөтенлеген барлыкка китергән элементларның эзлекле тәртибе

**ЛИТЕРАТУРНЫЙ ЯЗЫК** ӘДӘБИ ТЕЛ Гомумхалык теленең төп һәм иң камил үзенчәлекләрен үзендә туплаган, өстәмә рәвештә эшкәртелгән һәм кагыйдәләргә буйсындырылып нормалаштырылган өлеше; матур әдәбият әсәрләре, вакытлы матбугат, радио, телевидение теле

**ЛИТОТА** ЛИТОТА 1) Нинди дә булса объект турындагы тәэсирне аңлы рәвештә киметү, йомшарту, кечерәйтеп күрсәтү максатыннан тискәре сүзне инкяр итү юлы белән ясалган сүзтезмә (мәс., *эш начар түгел; хатасыз гына булмас*); 2) *к.* **мейозис**

**ЛИЦО** ЗАТ Эшнең һәм субъектның сөйләүчегә мөнәсәбәтен белдерә торган фигыльләргә хас грамматик категория (1 зат – эшне сөйләүче яки сөйләүчеләр башкаруын белдерә – *укыйм*; *укыйбыз*; 2 зат – эшне тыңлаучы яки тыңлаучылар башкаруын белдерә – *укыйсың*; *укыйсыз*; 3 зат – эшне сөйләүчеләрдән читтәге зат яки затлар башкаруын белдерә – *укый*; *укыйлар*)

**ЛИЧНЫЕ ФОРМЫ ГЛАГОЛА** ФИГЫЛЬНЕҢ ЗАТЛАНЫШЛЫ ФОРМАЛАРЫ Предикатив фигыль формасы; билгеле үтәүчеле җөмләләрдә хәбәр булып килә, затта, санда, заманда, наклонениеда төрләнә торган фигыль формалары (мәс., *укыйм, сөйләгәнсең, кайтачаклар* һ.б.)

**ЛИЧНЫЕ МЕСТОИМЕНИЯ** ЗАТ АЛМАШЛЫКЛАРЫ Сөйләм процессында катнашкан затларны белдереп килә торган алмашлыклар (сөйләүче, тыңлаучы, сөйләмдә катнашмаган, аның турында сүз барган зат – *мин, без; син, сез; ул, алар*)

**ЛИШНИЕ СЛОВА** АРТЫК СҮЗЛӘР Сөйләмне ямьсезли һәм сөйләүче сүзенә игътибарны киметә торган, сөйләмдә еш кабатланып килгән, бер нинди мәгълүмат өстәмәгән паразит сүзләр

**ЛОГИКО-ГРАММАТИЧЕСКОЕ НАПРАВЛЕНИЕ** ЛОГИК-ГРАММАТИК ЮНӘЛЕШ XIX гасырның беренче яртысында яшәп килгән, логика законнарын тел материалларын анализлауга, бигрәк тә, синтаксисны, этимологияне өйрәнүгә юнәлдергән тел гыйлемендәге агым; төп проблемасы – логика законнарының милли тел үзенчәлекләренә йогынтысын билгеләү (тарафдарлары: немец логик-грамматик мәктәбеннән – Карл Беккер, рус мәктәбеннән – Н.И. Греч, П.М. Перевлесский, И.И. Давыдов, Ф.И. Буслаев һ.б.)

**ЛОГИЧЕСКИЕ ГРАММАТИКИ** ЛОГИК ГРАММАТИКАЛАР *к.* **категориаль грамматикалар**

**ЛОГИЧЕСКОЕ УДАРЕНИЕ** ЛОГИК БАСЫМ Җөмләдәге берәр сүзнең мәгънәсенә басым ясау өчен аны башкаларыннан көчлерәк тавыш белән аерып әйтү (мәс., татар телендә хәбәр алдында торган сүзне, рус телендә җөмләдә соңгы торган сүзне көчлерәк тавыш белән әйтү)

**ЛОГОГРАММА** ЛОГОГРАММА Шартлы кыскартылмалар

**ЛОЖНАЯ ЭТИМОЛОГИЯ** ЯЛГАН ЭТИМОЛОГИЯ, ХАЛЫК ЭТИМОЛОГИЯСЕ Сүзнең килеп чыгышын очраклы аваз тәңгәллекләренә нигезләнеп, башка сүзләргә охшатып, фәнни булмаган аңлату

**ЛОЖНЫЕ ДИФТОНГИ** ЯЛГАН ДИФТОНГЛАР *к.* **дифтонг**

**ЛОКАЛИЗАЦИЯ** ЛОКАЛЬЛӘШҮ Сузык авазлардан аермалы буларак тартык авазларның ясалу урыннары аныклыгы

**ЛОКАТИВ** ЛОКАТИВ Урынны белдергән килеш

**ЛЯПСУС** ЛЯПСУС, ТУПАС ХАТА Сөйләмдә яки язмада җибәрелгән тупас хата

# М

**МАТРИЦА** МАТРИЦА Культурологиядә: үзенә җыярга, тупларга, сеңдерергә сәләтле булган беренчел төп нигез, конструкция, план, үстерергә мөмкин булган, күздә тотылган идея (мәс., *ак кәгазьгә тиңләштерелгән бала күңеле, кешенең эчке дөньясы, аерым төшенчәләр* һ.б.)

**МАТЕМАТИЧЕСКАЯ ЛИНГВИСТИКА** МАТЕМАТИК ЛИНГВИСТИКА Тел күренешләрен өйрәнүдә математика методларын файдаланудан гыйбарәт тел гыйлеменең бер бүлеге

**МАТЕРИАЛЬНОСТЬ СЛОВА** СҮЗНЕҢ МАТЕРИАЛЬЛЕГЕ Сүзнең яңгырашы һәм язылышы булу

**МАШИННЫЙ ПЕРЕВОД** МАШИНА ТӘРҖЕМӘСЕ Алдан төзеп салынган алгоритмга нигезләнеп, текстны бер телдән икенче телгә ЭВМ ярдәмендә күчерү

**МЕДИАЛЬ** МЕДИАЛЬ Иҗекнең уртасында торган аваз; *чаг.:* **инициаль, финаль**

**МЕДИАТИВ** МЕДИАТИВ Кыек корал килеше

**МЕДИТАТИВНЫЙ ВОПРОС** МЕДИТАТИВ СОРАУ Куелган сорауга җавап алу рәвешендә түгел, ә эмоциональ фикерләүне җиткерү, поэтик образларны аерып бирү өчен төзелгән, күбесенчә үз-үзеңә бирелә торган сорау җөмлә

**МЕЖДОМЕТИЕ** ЫМЛЫК Сөйләүченең хис-тойгыларын, эчке кичерешләрен, ихтиярын белдергәндә кулланыла, төрләнми торган сүз төркеме (мәс., *уф, ах, һайт, фи, абау, ура* һ.б.)

**МЕЖСТИЛЕВАЯ ЛЕКСИКА** СТИЛЬАРА ЛЕКСИКА Бер стильгә дә карамаган, гомумкулланылышта йөри торган лексика (мәс., *яхшы, начар, бәлки, түгел* һ.б.)

**МЕЖДУНАРОДНЫЙ ЯЗЫК** ХАЛЫКАРА ТЕЛ Төрле милләттәге дәүләт вәкилләре аралаша торган тел (мәс., инглиз теле)

**МЕЖНАЦИОНАЛЬНЫЙ ЯЗЫК** МИЛЛӘТАРА ТЕЛ Күп милләтле дәүләт эчендә милләтләрнең эш кәгазьләрен алып бару, үзара аралашу өчен кулланыла торган рәсми дәүләт теле

**МЕЙОЗИС** МЕЙОЗИС Охшату-чагыштыру нигезендә нормаль әйберләрне аңлы рәвештә чамасыз киметеп, нык кечерәйтеп күрсәтә торган образлы тәгъбир (мәс., *чыпчык та батып үлә алмаслык инеш, чәнти бармак буе малай*); *киресе:* **гипербола**

**МЕЛОДИКА РЕЧИ** СӨЙЛӘМ МЕЛОДИКАСЫ Интонациянең иң әһәмиятле элементларыннан берсе буларак сөйләм процессындагы тавыш югарылыгының үзгәрүе; кайбер телләрдә басымлы-басымсыз иҗекләрне аеру өчен дә хезмәт итә; күп телләрдә интонацияне төзи торган иң мөһим берәмлек булып тора

**МЕНТАЛИТЕТ** МЕНТАЛИТЕТ Аерым милләтнең сүзлек составыннан күз алдында барлыкка килгән дөнья картинасының төп концептларындагы шул халык аңына хас чынбарлыкны кабул итү үзенчәлеге, милли аңга нигезләнгән объектив чынбарлык хакындагы фикер сөреш рәвеше

**МЕНТАЛЬНОСТЬ** МЕНТАЛЬЛЕК Үзенчәлекле дөнья картинасының корылышын барлыкка китерә торган фикерләү процесслары җыелмасы

**МЁРТВЫЙ ЯЗЫК** ҮЛЕ ТЕЛ Җанлы сөйләмдә кулланылмый торган, бары язма истәлекләрдә сакланып калган тел (мәс., *тофалар теле, скиф теле, согдай теле, сак теле, полаб теле, шумер теле* һ.б.)

**МЕСТНО-ВРЕМЕННОЙ ПАДЕЖ** УРЫН-ВАКЫТ КИЛЕШЕ Эшнең урынын һәм вакытын, берәр нәрсәдә предметның булу-булмавын белдерә торган татар телендәге исемнәргә хас категориаль килеш формасы; грамматик күрсәткече – *-да/-дә, -та/-тә* кушымчалары

**МЕСТО ОБРАЗОВАНИЯ** ЯСАЛУ УРЫНЫ Тартык авазларны артикуляцион яктан төркемләүнең беренче нигезе; тартык авазны әйткәндә, үпкәдән килә торган һава агымына тоткарлык ясала торган урын (иреннәр, тел алды, кече тел һ.б.)

**МЕСТОИМЕНИЕ** АЛМАШЛЫК Мөстәкыйль мәгънәгә ия булмаган, предмет, күренеш һәм аларның билгеләренә күрсәтә, ишарәли, сөйләмдә башка сүз төркемнәрен алмаштырып килә ала торган сүз төркеме (татар телендә зат, тартым, сорау, күрсәтү, билгеләү, билгесезлек, юклык алмашлыкларына бүленә)

**МЕСТОИМЁННОЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЕ** АЛМАШЛЫК СҮЗТЕЗМӘ Алмашлыкның исемне һәм исемләшкән сүзләрне ияртүе белән ясалган сүзтезмә (мәс., *хезмәтемнең монысы, укыганнарымнан бу*)

**МЕТАТЕЗА** МЕТАТЕЗА Ассимиляция яки диссимиляция нәтиҗәсендә сүзләрдәге ике авазның яки ике иҗекнең урыннары алышыну, үзара күчеше (мәс., *абзар – азбар*)

**МЕТАФОРА** МЕТАФОРА Охшашлык нигезендә мәгънә күчеше барлыкка килгән, кинаяләп әйтелә торган күчерелмә мәгънәле сүз яки тәгъбир (мәс., *ачык авыз, корыган агач* һ.б.)

**МЕТАФОРИЧЕСКАЯ ПРОИЗВОДНОСТЬ** МЕТАФОРИК ЯСАЛЫШ Нигез сүзнең метафорик мәгънәсеннән чыгып яңа сүз ясау (мәс., начарлык мәгънәсендә – *этлек,* куркаклык мәгънәсендә – *куянлык* һ.б.)

**МЕТАЯЗЫК** МЕТАТЕЛ Сөйләм һәм тел күренешләрен тасвирлап бирә торган ярдәмче тел

**МЕТОНИМИЯ** МЕТОНИМИЯ Образлы сөйләмдә бер сүзне аңа бәйләнеше булган икенче сүз мәгънәсендә алмаштырып кулланыла торган, мәгънә күчеше янәшәлек нигезендә барлыкка килгән күчерелмә мәгънәле сүз (мәс., *Такташны яттан беләм, зал дәррәү торып басты* һ.б.)

**МЕТРОРИТМИЧЕСКАЯ МАТРИЦА** МЕТРОРИТМИК МАТРИЦА Синхрон ритмлы тәртип параметры бирә торган эзләнү-тикшеренү берәмлеге

**МИРОВЫЕ ЯЗЫКИ** ДӨНЬЯ ТЕЛЛӘРЕ БМО тарафыннан рәсми тел буларак юридик танылган телләр

**МИФОПОЭТИКА** МИФОПОЭТИКА Телдә һәм сөйләмдә кулланыла торган мифологиягә нигезләнгән поэтик чаралар: мотивлар, архитиплар, сюжетлар (мәс., *ана һәм бала мотивы, ата-*

*лар һәм балалар мотивы, мәҗүсилек мотивлары, юл архитипы, сагыш архитибы* һ.б.)

**МЛАДОГРАММАТИЗМ** МЛАДОГРАММАТИЗМ XIX гасырның 70 елларында тел гыйлемендә натуралистик һәм логик юнәлешләрдә телне ниндидер мөстәкыйль, кешегә бәйсез әйбер буларак өйрәнүне тәнкыйть итеп барлыкка килгән, төп принциплары тарихилык һәм психологизм булган, иң беренче чиратта *сөйләп торучы* телен өйрәнүне максат итеп куйган, тел бары тик аерым бер индивид сөйләмендә генә яши, бөтен үзгәрешләр индивидтан килә дип дәлилләгән, сөйләм эшчәнлеген физиологик һәм психик процессларга бүлеп караган, нәтиҗәдә фонетик законнарны тирәнтен өйрәнгән юнәлеш (төп вәкилләре – Карл Бругман, Герман Остхоф, Август Лескин, Бертольд Дельбрюк, Герман Пауль һ.б.)

**МЛАДОПИСЬМЕННЫЙ** ЯШЬ ЯЗУЛЫ Уку-язу культурасын күптән түгел генә үзләштергән, борынгы чордан ук килгән графикалары булмаган, язма әдәбияты булмаган

**МНОГОЗНАЧНОСТЬ** КҮПМӘГЪНӘЛЕЛЕК *к.* **полисемия**

**МНОГОКРАТНОЕ ДАВНОПРОШЕДШЕЕ ВРЕМЯ** КАБАТЛАУЛЫ КҮПТӘН ҮТКӘН ЗАМАН Сөйләү моменты белән бәйләнешле үткәннән алда булган, гадәти яки кабатлана торган эш-хәлләрне белдергән фигыль формасы (мәс., татар телендә грамматик күрсәткече -*а торган иде – килә торган иде, сөйли торган иде* һ.б.)

**МНОГОТОЧИЕ** КҮП НОКТАЛАР Текстта фикернең тәмамланмавын, сүзләрнең төшеп калган урыннарын яки фикернең кисәк үзгәрүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән паузаны белдерү өчен куела торган, ноктлар рәтеннән гыйбарәт булган тыныш билгесе (…)

**МНОГОЧЛЕННОЕ СМЕШАННОЕ СЛОЖНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** КҮП КИСӘКЛЕ КАТНАШ КУШМА ҖӨМЛӘ Үзләренең иярчен җөмләсе дә булган, үзара тезү юлы белән бәйләнгән ике яки аннан да артык җөмлә; аерым җөмләләре тезү юлы белән дә, ияртү юлы белән дә бәйләнгән кушма җөмлә

**МНОГОЧЛЕННОЕ СЛОЖНОПОДЧИНЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ Бер баш җөмләгә берничә иярчен җөмлә ияреп килгән кушма җөмлә; тиңдәш иярткүле, тиңдәш түгел иярткүле, бер-бер артлы иярткүле, берничә төр иярткүле күп иярченле кушма җөмләләр була

**МНОГОЧЛЕННОЕ СЛОЖНОПОДЧИНЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ С НЕОДНОРОДНЫМ ПОДЧИНЕНИЕМ** КАБАТЛАУЛЫ КҮПТӘН ҮТКӘН ЗАМАН, ТИҢДӘШ ТҮГЕЛ ИЯРҮЛЕ КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ Баш җөмләне төрлечә ачыклап килгән берничә иярчен җөмлә иярген кушма җөмлә

**МНОГОЧЛЕННОЕ СЛОЖНОПОДЧИНЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ С ОДНОРОДНЫМ ПОДЧИНЕНИЕМ** ТИҢДӘШ ИЯРҮЛЕ КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ Баш җөмләгә бер үк мәгънә мөнәсәбәтендә берничә иярчен җөмлә иярген кушма җөмлә

**МНОГОЧЛЕННОЕ СЛОЖНОПОДЧИНЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ С ПОСЛЕДОВАТЕЛЬНЫМ ПОДЧИНЕНИЕМ** БЕР-БЕР АРТЛЫ ИЯРҮЛЕ КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ Берничә иярчен җөмлә турыдан-туры баш җөмләгә түгел, ә бер-бер артлы берсе икенчесенә ияреп килгән берничә җөмләдән торган иярченле кушма җөмлә

**МНОГОЧЛЕННОЕ СЛОЖНОПОДЧИНЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ СО СМЕШАННЫМ ПОДЧИНЕНИЕМ** БЕРНИЧӘ ТӨР ИЯРҮЛЕ КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ Баш җөмләгә төрле бәйләнеш юллары белән ияреп килгән берничә иярчен җөмләләре булган кушма җөмлә

**МНОГОЧЛЕННОЕ СЛОЖНОСОЧИНЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** КҮП ТЕЗМӘЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ Үзара тезү юлы белән бәйләнеп килгән берничә җөмләсе булган кушма җөмлә

**МНОГОЯЗЫЧИЕ** КҮПТЕЛЛЕЛЕК Аерым бер иҗтимагый төркем, яки берәр дәүләт эчендә төрле милләтләрнең берьюлы төрле системага караган берничә телдә аралашу күренеше

**МНОЖЕСТВЕННОЕ СОБИРАТЕЛЬНОЕ** ҖЫЙМА КҮПЛЕК Бердәй предметлар җыелмасын белдерә торган форма (мәс.,

татар телендә парлы сүзләр: *бала-чага, савыт-саба, итек-читек һ.б.*)

**МНОЖЕСТВЕННОЕ ЧИСЛО** КҮПЛЕК САНЫ Грамматик һәм лексик чаралар ярдәмендә исемнәрдә предметларның күп булуын, фигыльләрдә процессның күп субъектка каравын белдерә торган категория

**МОДАЛЬНО-ПРЕДИКАТИВНОЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЕ** МОДАЛЬ СҮЗТЕЗМӘ, ХӘБӘРЛЕКЛЕ СҮЗТЕЗМӘ Башка сүз төркемнәрендәге сүзләрнең хәбәрлек сүзләргә ияреп ясалган сүзтезмәсе (*һава кебек кирәк, кемгә ярый, бу мөмкинме*)

**МОДАЛЬНОЕ СЛОВО** МОДАЛЬ СҮЗ Сөйләүченең чынбарлыкка төрле-төрле мөнәсәбәтен – шикләнү, гаҗәпләнү, ихтималлык, тиешлек, мөмкинлек, ышанычлы булу һ.б. – белдерә торган лексик берәмлекләр (мәс., *дөрес, әлбәттә, мөгаен, имеш* һ.б.)

**МОДАЛЬНОСТЬ** МОДАЛЬЛЕК Сөйләмнең чынбарлыкка төрле-төрле мөнәсәбәтен белдерә торган грамматик-семантик категория (морфологик, синтаксик, фонетик һәм лексик чаралар ярдәмендә башкарыла)

**МОДАЛЬНЫЕ ЧАСТИЦЫ** МОДАЛЬ КИСӘКЧӘЛӘР Сөйләмгә төрле модаль төсмерләр (шикләнү, гаҗәпләнү, ихтималлык, икеләнү һ.б.) өсти торган кисәкчәләр (мәс., *әллә, -дыр/-дер* һ.б.: *бер дә юкка түгелдер; күрерменме икән; әллә бар, әллә юк*)

**МОДАЛЬНЫЙ ЧЛЕН** МОДАЛЬ КИСӘК Җөмлә кисәкләренең берсенә дә грамматик бәйләнмәгән, ә сөйләүченең сөйләмгә мөнәсәбәтен, чынбарлыкка бәяләмәсен күрсәткән сүз яки җөмлә (кереш сүз, эндәш сүз, кереш җөмлә) *к.* **вводное предложение, вводное слово, обращение**

**МОДЕЛЬ** МОДЕЛЬ, КАЛЫП Нинди дә булса тел күренешләренең, процессның, системаның төп элементларын күрсәткән схема, үрнәк, калып (мәс., *сүзьясалыш калыбы, җөмлә моделе, композицион модель* һ.б.)

**МОДЕЛИ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘ МОДЕЛЬЛӘРЕ Баш һәм мәҗбүри иярчен кисәкләрдән төзелгән, ирекле лексик

берәмлекләр белән тулыландыру мөмкин булган җөмләләрнең традицион структур үрнәге

**МОДЕЛЬ СЛОВООБРАЗОВАНИЯ** СҮЗЬЯСАЛЫШ КАЛЫБЫ Сүз ясалышында барлык грамматик чараларның классификациясен биргән схема

**МОДИФИКАЦИОННОЕ СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** СҮЗЬЯСАЛЫШЫНЫҢ МОДИФИКАЦИОН МӘГЪНӘСЕ Төшенчәнең өлешчә модификациясен барлыкка китергән мәгънәсе (мәс., *аксыл, зәңгәрсу, йолдызчык, шагыйрә*)

**МОНОЛОГ** МОНОЛОГ Бер персонажның үз-үзенә, яисә башка берәүгә мөрәҗәгать итеп җавап көтмичә сөйләве

**МОНОСЕМИЯ** МОНОСЕМИЯ Сүзнең бер мәгънәгә генә ия булуы

**МОНОСИЛЛАБ** МОНОСИЛЛАБ Бер иҗекле сүз

**МОНОФТОНГИЗАЦИЯ** МОНОФТОНГЛАШТЫРУ Дифтонгларның бер генә аваз – монофтонглар белән алыштырылуы (мәс., *көймә – кәмә, өй – ү, көй – кү* һ.б.)

**МОРФЕМА** МОРФЕМА Телнең башкача бүленми торган мәгънәле кисәге (*тамыр морфемалар* һәм *кушымча морфемалар*)

**МОРФЕМИКА** МОРФЕМИКА 1) Морфемалар җыелмасы; 2) Тел гыйлемендә морфемаларның, ягъни сүз төзелешенең гомуми үзенчәлекләрен (*сүз, сүзформа, морфема, морф* төшенчәләрен) өйрәнә торган фән

**МОРФЕМНЫЙ АНАЛИЗ** МОРФЕМА АНАЛИЗЫ Телнең хәзерге хәлендә яшәп килгән сүзләрдәге морфемаларны аерып алу, аларның мәгънәләрен, функцияләрен күрсәтеп бирүдән гыйбарәт анализ

**МОРФЕМОГРАФИЯ** МОРФЕМОГРАФИЯ Морфемалар сүзлеге

**МОРФОЛОГИЧЕСКАЯ КЛАССИФИКАЦИЯ** МОРФОЛОГИК (ТИПОЛОГИК) КЛАССИФИКАЦИЯ Телләрне төзелеш билгеләре, ягъни грамматик формаларны белдергән чараларга нисбәтле төркемләү; бу классификация буенча *агглютинатив, флектив, полисинтетик, аморф* телләр була

**МОРФОЛОГИЧЕСКАЯ ПАРАДИГМА** МОРФОЛОГИК ПАРАДИГМА Сүзнең барлык грамматик формалары җыелмасы

**МОРФОЛОГИЧЕСКИЕ ДИАЛЕКТИЗМЫ** МОРФОЛОГИК ДИАЛЕКТИЗМНАР Грамматик кушымчалар белән аерылган диалектизмнар

**МОРФОЛОГИЧЕСКИЕ КАТЕГОРИИ** МОРФОЛОГИК КАТЕГОРИЯЛӘР Сүзнең грамматик формалары бәяләмәсе җыелмасы

**МОРФОЛОГИЧЕСКИЙ АНАЛИЗ** МОРФОЛОГИК АНАЛИЗ Сүзләрнең сүз төркемнәренә бүленешен, лексик-грамматик категорияләрен һәм бу категорияләрне белдергән грамматик чараларын күрсәтеп бирүдән гыйбарәт анализ

**МОРФОЛОГИЧЕСКИЙ ПРИНЦИП** МОРФОЛОГИК ПРИНЦИП Орфографиядә: бер үк морфемаларны һәрвакыт бер генә төрле язуны таләп итә торган принцип (мәс., *утынлык – утынның; көтеп – көтөп* һ.б.)

**МОРФОЛОГИЧЕСКИЙ СПОСОБ СЛОВООБРАЗОВАНИЯ** СҮЗЬЯСАЛЫШЫНЫҢ МОРФОЛОГИК ЫСУЛЫ Телдә булган морфемаларның кушылуы, аффикслар ялгану юлы белән сүзьясалыш: кушымчалау, сүзләр кушылу, аббревиация (мәс., *күзлек, кыекча, көнбагыш, профуку* һ.б.)

**МОРФОЛОГИЧЕСКОЕ ЗНАЧЕНИЕ** МОРФОЛОГИК МӘГЪНӘ Сүзне үзе караган сүз төркеменә хас барлык грамматик категорияләр комплексында күзаллау

**МОРФОЛОГИЯ** МОРФОЛОГИЯ, САРЫФ Тел гыйлемендә сүзләрнең төзелешен, төрләнешен, сүз төркемнәрен һәм аларга хас грамматик категорияләрне өйрәнә торган фән

**МОРФОЛОГО-СИНТАКСИЧЕСКИЙ СПОСОБ СЛОВООБРАЗОВАНИЯ** СҮЗЬЯСАЛЫШЫНЫҢ МОРФОЛОГИК-СИНТАКСИК ЫСУЛЫ Сүзнең нигез хәлендә яки нинди дә булса грамматик формада бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчүе (мәс., *чәчү* – фигыль, *чәчү* – исем; *кара* – сыйфат, *кара* – исем; *ак* – сыйфат, *аклар* – исем һ.б.) *к.* **конверсия**

**МОРФОНЕМА** МОРФОНЕМА Морфемаларның фонетик позицияләрдә кулланылуы нәтиҗәсендә чиратлаша торган фонетик берәмлекләр – фонемалар комплексы

**МОРФОНОЛОГИЧЕСКИЕ ЯВЛЕНИЯ** МОРФОНОЛОГИК КҮРЕНЕШЛӘР Морфологик процесслар вакытында сүзнең фонетик төзелешендәге үзгәрешләр (фонемалар чиратлашу, нигезләр кыскару, асемантик фонемалар ялгану һ.б.)

**МОРФОНОЛОГИЯ** МОРФОНОЛОГИЯ Тел гыйлемендә морфологик процесслар вакытында сүзнең фонетик төзелешендә бара торган үзгәрешләрне өйрәнә торган фән

**МОТИВ** МОТИВ Культурологиядә: еш кабатланып килгән иң гади тасвирлау берәмлеге – сюжетлар, образлар, вакыйгалар һ.б. (мәс., *ана, бәхет, өй, туган җир, аерылышу-кавышу* һ.б.)

**МОТИВИРОВАННОЕ ЗНАЧЕНИЕ СЛОВА** СҮЗНЕҢ МОТИВЛАШТЫРЫЛГАН МӘГЪНӘСЕ Сүзгә сүзьясалыш чаралары ярдәмендә салынган мәгънә

**МУЖСКОЙ РОД** МУЖСКОЙ РОД Аерым телләрдә төрләнешнең аерым парадигмалары белән билгеләнгән, биологик җенесне генә түгел, сүз формасы белән дә белдерелә торган лексик-грамматик үзлек

**МУЗЫКАЛЬНОЕ УДАРЕНИЕ** МУЗЫКАЛЬ БАСЫМ Басым төшкән иҗекнең басымсыз иҗекләрдән тавышның югарылыгы белән аерылып торган басым (мәс., *кытай, япон телләрендәге басым*)

**МУТАЦИОННОЕ СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** СҮЗЬЯСАЛЫШЫНЫҢ МУТАЦИОН МӘГЪНӘСЕ Нигез сүздәге мәгънәдән ясалма сүзнең кискен аерылып торган мәгънәсе (мәс., *аклау* – оправдать; *бозыклык* – разврат һ.б.)

**МЯГКИЕ ГЛАСНЫЕ** ЙОМШАК СУЗЫКЛАР Алгы рәт сузыклар; тел авыз куышлыгының алгы өлешенә килеп ясала торган сузыклар

**МЯГКИЕ СОГЛАСНЫЕ** ЙОМШАК (ПАЛАТАЛЬ) ТАРТЫКЛАР Тел авыз куышлыгының алгы өлешенә елышкан хәлдә ясалган тартыклар; *к.* **твердые согласные**

# Н

**НАЗАЛИЗАЦИЯ** НАЗАЛИЗАЦИЯ, БОРЫНЛАШУ Борын авазлары белән янәшә торган сузык авазларны әйткәндә, йомшак аңкауның түбән төшүе нтиҗәсендә, тавышның бер өлеше борын аша үтеп, сузык авазда борын тембры барлыкка килү (мәс., *урман, моң, намус* һ.б.)

**НАЗАЛЬНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** БОРЫН ТАРТЫКЛАРЫ *к.* **носовые согласные**

**НАЗЫВНАЯ ФУНКЦИЯ** АТАУ ФУНКЦИЯСЕ. *к.* **номинативная функция**

**НАЗЫВНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** АТАУ ҖӨМЛӘ Әйбернең, күренешнең булуын хәбәр итә, баш кисәге исем, сыйфат яки рәвеш белән белдерелә торган җөмлә (мәс., *Көз. Яңгыр. Салкын. Шыксыз*)

**НАКЛОНЕНИЕ** НАКЛОНЕНИЕ Эш яки хәлнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерә торган грамматик категория, фигыльләрдә модальлек белдерә торган төп чара: *хикәяләү, шарт, теләк, боеру* наклонениеләре; шулардан чыгып фигыль төркемчәләре билгеләнә (*хикәя фигыль, шарт фигыль, теләк фигыль, боерык фигыль, сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль, инфинитив*)

**НАЛОЖЕНИЕ ФОНЕМ** ФОНЕМАЛАР КЕРЕШҮ Морфемалар ялганган урында ике бер үк төрле фонема туры килгәндә берсенең кыскару күренеше (мәс., *алмагач, карагач*)

**НАПРАВИТЕЛЬНЫЙ ПАДЕЖ** ЮНӘЛЕШ КИЛЕШ Урын, вакыт, сәбәп, максат мөнәсәбәтләрен белдереп, *-га/-гә, -ка/-кә* кушымчалары ярдәмендә исемне башка сүзләргә ияртә торган килеш

**НАРЕЧИЕ** РӘВЕШ Эш-хәлнең билгесен яки билгенең билгесен белдереп, җөмләдә гадәттә хәбәрне ачыклап һәм хәл булып килә, төрләнми торган сүз төркеме; татар телендә билге

(сыйфатлау, күләм-чама, охшату-чагыштыру), һәм хәл (вакыт, урын, сәбәп-максат) рәвешләренә бүленә

**НАРЕЧИЯ ВРЕМЕНИ** ВАКЫТ РӘВЕШЛӘРЕ Эш-хәлнең үтәлү вакытын ачыклаган рәвешләр (мәс., *элек, әллә кайчан, кайвакыт* һ.б.)

**НАРЕЧИЯ КАЧЕСТВЕННО-ОПРЕДЕЛИТЕЛЬНЫЕ** БИЛГЕ РӘВЕШЛӘРЕ Эш-хәлнең үтәлү рәвеше буенча характерлый торган яки эш-хәлнең күләм-чамасын, үтәлү дәрәҗәсен белдергән рәвешләр

**НАРЕЧИЯ МЕСТА** УРЫН РӘВЕШЛӘРЕ Эш-хәл, процессны үтәлү урыны ягыннан ачыклый торган рәвешләр (мәс., *югары үрләү, түбәнгә ташлану*)

**НАРЕЧИЯ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА** ХӘЛ РӘВЕШЛӘРЕ Эшхәлнең үтәлү вакытын, урынын, сәбәбен, максатын белдергән рәвешләр

**НАРЕЧНОЕ СЛОВОСОЧИТАНИЕ** РӘВЕШ СҮЗТЕЗМӘ Рәвешләр рәвеш һәм исемнәрне ияртеп ясалган сүзтезмәләр (мәс., *бөтенләй ялгыз, искиткеч мөһим*)

**НАРИЦАТЕЛЬНОЕ ИМЯ** УРТАКЛЫК ИСЕМ Бер төрдән булган әйберләрне, күренешләрне атый торган исемнәр (мәс., *су, балчык, тәрәзә, йорт* һ.б.)

**НАРОДНАЯ ЭТИМОЛОГИЯ** ХАЛЫК ЭТИМОЛОГИЯСЕ *к.* **ложная этимология**

**НАСТОЯЩЕЕ ВРЕМЯ** ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН Сүз барган эш, хәл, вакыйганың сөйләп торган вакытка туры килүен белдергән фигыльләргә хас заман категориясе

**НАТУРАЛИСТИЧЕСКОЕ НАПРАВЛЕНИЕ** НАТУРАЛИСТИК ЮНӘЛЕШ Тел гыйлемендә XIX гасыр урталарында Европада Чарлз Дарвинның табигать фәннәре үсешендәге уңышлары йогынтысында барлыкка килгән, тел яшәешен кеше ихтиярына бәйсез дип дәлилләгән, аны табигать фәннәренә кертеп караган, гомумтеоретик мәсьәләләргә караганда конкрет тел фактлары белән кызыксынуга юнәлтелгән агым; бу агым телләрнең типологик классификациясен, фонетик законнар үсешен, һиндевропа

телләрендә этимологик тикшеренүләр, телләрнең туганлык шәҗәрәсе һ.б. тикшерүе белән үзенчәлекле (аңа нигез салучы Август Шлехер була)

**НАУЧНАЯ ЛЕКСИКА** ФӘННИ ЛЕКСИКА Фәнни төшенчәләрне терминлаштырган махсус лексика

**НЁБНАЯ ГАРМОНИЯ** АҢКАУ ГАРМОНИЯСЕ *к.* **рядовая гармония**

**НЁБО** АҢКАУ Авазларны әйтүдә катнаша торган, авыз кушлыгының өске өлешен тәшкил иткән пассив артикуляцион орган

**НЕВЕРБАЛЬНЫЕ СРЕДСТВА ОБЩЕНИЯ** АРАЛАШУДА СҮЗДӘН ГАЙРЕ ЧАРАЛАР Тел белән әйтелмичә, сөйләмгә өстәмә булып яки аны алмаштырып килгән, мәгълүмат тапшыра торган чаралар (мимика, куллар ишарәсе, караш, төрле хәрәкәт – баш кагу, кулны, күзне кысу, җилкәгә сугу, аякка басу һ.б.)

**НЕЗАВЕРШЁННОЕ ПРОШЕДШЕЕ ВРЕМЯ** ТӘМАМЛАНМАГАН ҮТКӘН ЗАМАН, ИМПЕРФЕКТ Сөйләү моментыннан алда булып, дәвамлы, процесс рәвешендә башкарылган, тәмамланып бетмәгән яки кабатланган, гадәти эш-хәлләрне белдерә торган фигыль формасы (мәс., татар телендә грамматик күрсәткече *-а/-ә, -ый/-и* кушымчасы һәм *иде* ярдәмлек фигыле ярдәмендә ясалган фигыль формасы: *сөйли иде, укый иде*)

**НЕЗНАМИНАТЕЛЬНЫЕ ЧАСТИ РЕЧИ** ЯРДӘМЛЕК СҮЗЛӘР Семантик яктан предметларны, билгене һ.б. турыдан-туры атамыйлар, ә чынбарлык күренешләре арасындагы мөнәсәбәтләрне, ягъни грамматик мәгънә (*бәйлек, теркәгечләр*) яки төрле мәгънә төсмерләрен (*кисәкчәләр*) белдерә торган сүз төркемнәре

**НЕИЗМЕНЯЕМЫЕ ЧАСТИ РЕЧИ** ТӨРЛӘНЕШСЕЗ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ Сүзне үзгәртә торган парадигмалары булмаган, грамматик формалар алмый торган сүз төркемнәре

**НЕЙРОЛИНГВИСТИКА** НЕЙРОЛИНГВИСТИКА Когнитив лингвистикада кеше акылының менталь эшчәнлеген танып белүдә телне нигез итеп өйрәнә торган фән

**НЕЙТРАЛЬНАЯ ЛЕКСИКА** НЕЙТРАЛЬ СҮЗЛӘР Югары яки түбән стильдә синонимнары булган, әмма үзе стилистик төсмерләрдән азат гомумкулланышта йөргән сүз

**НЕКСУС** НЕКСУС Сүзләр арасындагы предикатив мөнәсәбәт

**НЕЛИЧНЫЕ ФОРМЫ ГЛАГОЛОВ** ЗАТЛАНЫШСЫЗ ФИГЫЛЬ ФОРМАЛАРЫ *к.* **именные глагольные формы**

**НЕЛОКАЛИЗОВАННЫЙ ГЛАСНЫЙ** ЛОКАЛЬЛӘШМӘГӘН СУЗЫК Тел хәрәкәт итмичә генә әйтелә торган сузыклар

**НЕМОТИВИРОВАННОЕ ЗНАЧЕНИЕ СЛОВА** СҮЗНЕҢ МОТИВЛАШТЫРЫЛМАГАН МӘГЪНӘСЕ Синхрониядә ясалма булмаган, ни өчен шулай аталганы күренеп тормаган тамыр яки тамырлашкан сүз белдергән мәгънә

**НЕОГУБЛЕННЫЕ ГЛАСНЫЕ** ИРЕНЛӘШМӘГӘН СУЗЫКЛАР Әйткән вакытта иреннәр нейтраль хәлдә калган сузыклар

**НЕОГРАММАТИЧЕСКОЕ НАПРАВЛЕНИЕ** НЕОГРАММАТИКА ЮНӘЛЕШЕ XIX гасыр ахыры XX гасыр башында барлыкка килгән, тел гыйлемендә тел тарихын гына түгел, ә телнең үз структурасын өйрәнүне дә аның төп предметы дип таныган юнәлеш (1975 елда В.И. Кодухов тарафыннан шушы атама белән исемләнә, өч лингвистик мәктәпне берләштерә: И.А. Бодуэн де Куртенэ җитәкчелегендәге Казан мәктәбен, Ф.Ф. Фортунатов җитәкчелегендәге Мәскәү мәктәбен, Ф. де Соссюр җитәкчелегендәге Швейцария яки Женева мәктәбен, әмма алар үзләрен бердәм дип танымаганнар; өйрәнү объектлары – Казан мәктәбенең: фонемалар, морфемалар, Мәскәү мәктәбенең: сүзтезмәләр һәм сүз формалары, Швейцария мәктәбенең: синтагматик һәм ассоциатив тел мөнәсәбәтләре)

**НЕОДУШЕВЛЁННОСТЬ** ҖАНСЫЗЛЫК *Нәрсә, ни* соравына җавап биреп килә торган, рус телендә җансыз предметларны, үсемлекләрне, вакыйгаларны, күренешләрне, сыйфатны, хәлне, халәтне белдереп килгән исем сүз төркеменә хас грамматик категория, татар телендә кешедән кала барлык исемнәр дә *нәрсә, ни* соравына җавап бирә *к.* **одушевленность/ неодушевленность**

**НЕОЛОГИЗМ** НЕОЛОГИЗМ, ЯҢА СҮЗ Яңа күренешләрне, предметларны, билгеләрне, эш, хәл, хәрәкәтне атау өчен телдә яңа барлыкка килгән, моңарчы кулланылмаган лексик катлам (чыганаклары: телнең үз потенциалы нигезендә барлыкка килгән сүзләр, диалектизмнар, калькалар, алынма лексика)

**НЕОПРЕДЕЛЁННОЕ БУДУЩЕЕ ВРЕМЯ** БИЛГЕСЕЗ КИЛӘЧӘК ЗАМАН Татар телендә: фигыльләрдә эш, хәл, хәрәкәтнең киләчәктә булу-булмавын ихтимал рәвешендә хәбәр итә, *-ыр/-ер/-р* кушымчалары ярдәмендә ясала торган хикәя фигыльнең заман формасы (мәс., *кил-ер, укы-р*)

**НЕОПРЕДЕЛЁННО-ЛИЧНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** БИЛГЕСЕЗ ҮТӘҮЧЕЛЕ ҖӨМЛӘ Баш кисәге хикәя һәм шарт фигыльләрнең 3 зат күплек сан формасы белән белдерелә торган үтәүчесе билгесез бер составлы фигыль җөмлә (мәс., *Таң белән юлга чыгарга булдылар*)

**НЕОПРЕДЕЛЁННЫЕ МЕСТОИМЕНИЯ** БИЛГЕСЕЗЛЕК АЛМАШЛЫКЛАРЫ Сорау алмашлыкларына билгесезлекне белдергән *-дыр/-дер* кисәкчәсе ялганып яки алдына *әллә* кисәкчәсе килеп ясала, зат яки әйберләрнең билге, рәвеш, сан һәм кайбер хәлләрнең билгесезлегенә ишарә итә торган алмашлыклар (*ниндидер, кемдер, каядыр, әллә ни, әллә нинди, әллә кем, әллә ничә* һ.б.)

**НЕПЕРЕХОДНОЙ ГЛАГОЛ** КҮЧЕМСЕЗ ФИГЫЛЬ Туры тәмамлык белән янәшә килә алмый торган, күбесенчә хәлне, торышны, хәрәкәтне белдергән фигыльләр (мәс., *балку, көйсезләнү, яктыру, йөгерү* һ.б.)

**НЕПОЛНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** КИМ ҖӨМЛӘ Контексттан яки ситуациядән аңлашылып торган бер яки берничә кисәге төшереп калдырылган җөмлә (мәс., – *кая киттең? – су коеныргa*)

**НЕПОЛНОЗНАМЕНАТЕЛЬНЫЕ ГЛАГОЛЫ** ЯРДӘМЧЕ ФИГЫЛЬЛӘР Мөстәкыйль мәгънәгә ия булмаган, аерым җөмлә кисәге булып килә алмый торган грамматикалашкан фигыльләр (мәс., *ит, иде, кыл, быть, являться, мочь* һ.б.)

**НЕПРЕДЕЛЬНЫЕ ГЛАГОЛЫ** ЧИКСЕЗ ФИГЫЛЬЛӘР Салынган мәгънәсендә эшнең чигенә ишарә ясалмый, эш-хәлнең дәвамлы булуын белдерә торган, рус телендә вид парлары булмаган фигыльләр (мәс., *ярата, тырыша, тәрбияли, висеть, веселиться, спать* һ.б.) *к.* **предельные глаголы**

**НЕПРИДЫХАТЕЛЬНЫЙ СОГЛАСНЫЙ** ӘЙТЕЛЕШ АЛДЫННАН КИҢ ИТЕП СУЛЫШ АЛЫНМАГАН ТАРТЫКЛАР Үпкәдән килгән һава агымы кысылган тавыш ярыгыннан үткәндә сулышны тоткарлап ясалган шартлаулы саңгырау тартыклар

**НЕПРОДУКТИВНЫЙ** ПРОДУКТИВ БУЛМАГАН Телнең хәзерге хәлендә сүз ясалышында еш кулланылмый торган (мәс., *продуктив булмаган кушымчалар*)

**НЕПРОИЗВОДНЫЕ СЛОВА** ЯСАЛМА БУЛМАГАН СҮЗЛӘР Морфемаларга таркалмый торган нигез сүзләр; аларга *тамыр сүзләр,* телнең хәзерге торышында аерым кисәкләргә аерылмый торган *тамырлашкан сүзләр* һәм *алынмалар* керә

**НЕПРОИЗНОСИМЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ӘЙТЕЛМИ ТОРГАН ТАРТЫКЛАР Сөйләм телендә: ике яки берничә тартык рәттән килгән төзелмәләрдә әйтелми кала торган тартыклар: мәс., татар телендә *ңг* төзелмәсендә (*яңгыр, яңгыраш*) *г* авазы, рус телендә *стн* төзелмәсендә (*грустный, честный*)*; стл* төзелмәсендә (*счастливый*)*; нтск* төзелмәсендә (*гигантский*) *т* авазы; *здн* төзелмәсендә (*праздник, поздний*)*; рдц* төзелмәсендә (*сердце*) *д* авазы; *лнц* төзелмәсендә (*солнце*) *л* авазы әйтелми кала

**НЕРАСПРОСТРАНЁННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ҖЫЙНАК ҖӨМЛӘ Баш кисәкләрдән генә торган җөмлә

**НЕСКЛОНЯЕМОЕ СУЩЕСТВИТЕЛЬНОЕ** ТӨРЛӘНМИ ТОРГАН ИСЕМНӘР күбесенчә рус теленә хас: грамматик кушымчалар алып сүз формалары ясамый торган исемнәр; мәс., *кофе, пальто, фортепиано, Гульнур, АЭС* һ.б., татар телендә исемнәрнең төрләнмәү очрагы юк

**НЕСМЕЖНАЯ АССИМИЛЯЦИЯ** АРАДАШ АССИМИЛЯЦИЯ *к.* **дистактная ассимиляция**

**НЕСОБСТВЕННО-ПРЯМАЯ РЕЧЬ** УРТАК СӨЙЛӘМ Автор сөйләме белән персонаж сөйләме кушылып китү, авторның персонаж булып фикер йөртүе

**НЕСОВЕРШЕННЫЙ ВИД** НЕСОВЕРШЕННЫЙ ВИД Рус телендә тәгалләнмәгән, дәвам итә торган, кабатланып килгән эш-хәрәкәтне белдерә торган фигыль формасы

**НЕСПРЯГАЕМЫЕ ФОРМЫ ГЛАГОЛА** ФИГЫЛЬНЕҢ ТӨРЛӘНМИ ТОРГАН ФОРМАЛАРЫ затта, заманда төрләнми торган фигыль формалары: хәл фигыль, сыйфат фигыль, исем фигыль, инфинитив

**НЕЧЛЕНИМОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** БҮЛЕНМИ ТОРГАН ҖӨМЛӘ Баш һәм иярчен кисәкләргә бүленми торган, грамматик формалары булмаган җөмлә (мәс., *әйе мөгаен; ярый яхшы*)

**НОМИНАТИВ** НОМИНАТИВ Баш килеш

**НОМИНАТИВНАЯ ФУНКЦИЯ** НОМИНАТИВ ФУНКЦИЯ Сүзләрнең предметларны атау функциясе

**НОМИНАТИВНАЯ ШКАЛА** НОМИНАТИВ ШКАЛА Сөйләү эшчәнлеген өйрәнү методикасында нинди дә булса сыйныфка хас билгеләрне раслау шкаласы

**НОМИНАТИВНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** НОМИНАТИВ МӘГЪНӘ Сүзнең конкрет төшенчәне белдергән туры мәгънәсе

**НОМИНАТИВНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** НОМИНАТИВ ҖӨМЛӘ *к.* **назывное предложение**

**НОМИНАТИВНОСТЬ** НОМИНАЦИЯЛӘНГӘНЛЕК, АТАЛГАНЛЫК Чынбарлыктагы күренешләрне исемләп, шул мәгънәне сүзнең эчтәлегенә салган булу

**НОРМА** НОРМА Әдәби сөйләм практикасында, матур әдәбиятта куллану өчен норма итеп кабул ителгән сүзләр, авазларның яңгырашы, грамматик һ.б. тел чаралары җыелмасы

**НОСОВЫЕ СОГЛАСНЫЕ** БОРЫН ТАРТЫКЛАР Әйткән вакытта, йомшак аңкау түбән төшеп борын куышлыгына юл ачылып, тавышның бер өлеше борын куышлыгы аша үтеп ясала торган тартыклар: *м, н, ң*

**НОСТРАТИЧЕСКАЯ ТЕОРИЯ** НОСТРАТИК ТЕОРИЯ Берничә семьялык телләренең туганлыгы турындагы теория

**НУЛЕВАЯ МОРФЕМА** НУЛЬ МОРФЕМА *к.* **нулевой аффикс**

**НУЛЕВАЯ ФЛЕКСИЯ** НУЛЬ ФЛЕКСИЯ Башка охшаш формалар белән чагыштырганда, материаль белдерелми торган, кушымчасыз, үзенә аерым грамматик күрсәткече булмаган флексия (мәс., баш килештәге исем башкалар белән чагыштырганда нуль флеция алган: *китап, китап-ның, китап-ка, китап-ны* һ.б.)

**НУЛЕВАЯ ФОНЕМА** НУЛЬ ФОНЕМА Авазларның чиратлашуы вакытында фонеманың булмавы грамматик күрсәткече булып тора (мәс., *холык – холкы* һ.б.)

**НУЛЕВОЙ АФФИКС** НУЛЬ АФФИКС Парадигманың берәр формасында аффикс булмау очрагы (мәс., үткән заман хикәя фигыльнең 3 зат, берлек сан формасы)

# О

**ОБЕРТОН** ОБЕРТОН Төп тон белән бергә яңгыраучы авазның тембрын барлыкка китерә торган өстәмә, аннан югарырак тон

**ОБИХОДНАЯ, ОБИХОДНО-БЫТОВАЯ ЛЕКСИКА** КӨНКҮРЕШ ЛЕКСИКАСЫ Көнкүрештә, гадәти кулланыла торган сүзләр

**ОБЛИГАТОРНЫЕ ВТОРОСТЕПЕННЫЕ ЧЛЕНЫ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘНЕҢ МӨҺИМ ИЯРЧЕН КИСӘКЛӘРЕ Җөмлә төзелеше өчен мөһим булган, баш кисәкләр белән бергә фикернең төп өлешен белдерүдә катнаша торган иярчен кисәкләр

**ОБОБЩАЮЩИЕ СЛОВА** ГОМУМИЛӘШТЕРҮЧЕ СҮЗЛӘР Янындагы тиңдәш кисәкләрнең гомуми аңлатмасы буларак килә торган җөмлә кисәге функциясендәге сүз яки сүзтезмәләр

**ОБОБЩЁННО-ЛИЧНОЕ МЕСТОИМЕНИЕ** ГОМУМИ ҮТӘҮЧЕЛЕ АЛМАШЛЫК Аерым затны күрсәтмичә, гомумән кешеләргә күрсәтә торган алмашлык

**ОБОБЩЁННО-ЛИЧНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ГОМУМИ ҮТӘҮЧЕЛЕ ҖӨМЛӘ Баш кисәге 2 нче зат берлек сандагы яки 1 нче һәм 3 нче зат күплек сандагы һәм потенциаль яктан теләсә нинди затка караган эшне аңлаткан фигыль белән белдерелгән бер составлы иясез җөмлә

**ОБОЗНАЧАЕМОЕ** БИЛГЕЛӘНҮЧЕ Тел берәмлегенең эчке (семантик, абстракт төшенчәгә бәйле) ягы

**ОБОЗНАЧАЮЩЕЕ** БИЛГЕЛӘҮЧЕ Тел берәмлегенең тышкы (материаль) ягы (мәс., сөйләмдә – конкрет авазлар агымы; җөмләдә – аның структур схема һәм модельләрен реализацияләү)

**ОБОЗНАЧЕНИЕ** БИЛГЕЛӘҮ Сүзне номинатив функциядә куллану

**ОБОСОБЛЕНИЕ** АЕРЫМЛАНУ Җөмләдә беркадәр синтаксик мөстәкыйльлек бирү өчен, берәр иярчен кисәкне мәгънәви интонацион аеру

**ОБОСОБЛЕННЫЕ ДОПОЛНЕНИЯ** АЕРЫМЛАНГАН ТӘМАМЛЫКЛАР Интонация һәм пунктуация белән аерылып торган төрле килештәге яки бәйлекләр белән килгән исемнәр

**ОБОСОБЛЕННЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА** АЕРЫМЛАНГАН ХӘЛЛӘР Хәл функциясендә килә торган, интонация һәм пунктуация ярдәмендә аерымланган җөмлә кисәкләре

**ОБОСОБЛЕННЫЕ ОПРЕДЕЛЕНИЯ** АЕРЫМЛАНГАН АЕРГЫЧЛАР Аергыч функциясендә килә торган, интонация һәм пунктуация ярдәмендә аерымланган җөмлә кисәкләре

**ОБОСОБЛЕННЫЕ ПРИЛОЖЕНИЯ** АЕРЫМЛАНГАН ӨСТӘМӘ СҮЗЛӘР Өстәмә сүз функциясендә килә торган, интонация һәм пунктуация ярдәмендә аерымланган җөмлә кисәкләре

**ОБОСОБЛЕННЫЕ ЧЛЕНЫ** АЕРЫМЛАНГАН КИСӘКЛӘР Җөмләнең интонация һәм пунктуация белән аерылып торган кисәкләре

**ОБРАЗНАЯ МЕТАФОРА** ОБРАЗЛЫ МЕТАФОРА Күчерелмә мәгънәнең кешенең органик һәм неорганик дөньяны үзенчәлекле күзаллау нәтиҗәсендә барлыкка килгән, ике семантик планлы – образлы һәм праобразлы, экспрессив-эмоциональ төре

**ОБРАЗОПОДРАЖАТЕЛЬНЫЕ СЛОВА** ОБРАЗ ИЯРТЕМНӘРЕ Чынбарлыкның төрле күренешләрен образлы чагылдыру өчен кулланыла торган сүзләр (мәс., *шак-шык, келт-келт*)

**ОБРАТНОЕ СЛОВООБРАЗОВАНИЕ, РЕДЕРИВАЦИЯ** КИРЕ СҮЗЬЯСАЛЫШЫ, РЕДЕРИВАЦИЯ Сүзнең ясаучы нигездән түгел, ясалган нигездән ясалуы (мәс., *дояр* > *доярка*)

**ОБРАТНОЕ СОГЛАСОВАНИЕ** КИРЕ ЯРАШУ Фигыль бәйләгеченең ия белән түгел, тезмә хәбәр составындагы исем өлеше белән ярашуы

**ОБРАТНЫЙ ПОРЯДОК СЛОВ** СҮЗЛӘРНЕҢ КИРЕ ТӘРТИБЕ Җөмлә кисәкләренең туры тәртипне бозып урнашуы (мәс., җөмләдә иянең постпозитив, хәбәрнең препозитив урнашуы)

**ОБРАТНЫЙ СЛОВАРЬ** КИРЕ СҮЗЛЕК Алфавит тәртибе сүзләрнең ахыргы хәрефләре буенча бирелгән сүзлек

**ОБРАЩЕНИЕ** ЭНДӘШ СҮЗ Сөйләм төбәлгән затны белдереп килгән сүз (мәс., ***Кызым**, нишлисең?*)

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВЕННОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ХӘЛ МӘГЪНӘСЕ Эшнең үтәлү вакытын, максатын, рәвешен, дәрәҗәсен һ.б. белдерү

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВЕННОЕ ДОПОЛНЕНИЕ** ХӘЛ ТӘМАМЛЫК Җөмләнең объект һәм хәл мәгънәләрен берләштергән иярчен кисәге

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВЕННОЕ ОПРЕДЕЛЕНИЕ** ХӘЛ АЕРГЫЧ Җөмләнең атрибут һәм хәл мәгънәләрен берләштергән аергыч

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВЕННЫЕ НАРЕЧИЯ** ХӘЛ РӘВЕШЛӘРЕ Эш-хәл белән бәйле пространство, вакыт, сәбәп мөнәсәбәтләрен белдергән рәвешләр (мәс., *кичә, күптән түгел*)

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВО** ХӘЛ Җөмләнең фигыль, сыйфат, рәвеш, хәбәрлек сүз белән бирелгән кисәгенә ияреп, эшнең, билгенең билгесен, эшнең үтәлү рәвешен, вакытын, сәбәбен һ.б.ларны белдерә торган иярчен кисәге

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВО ВРЕМЕНИ** ВАКЫТ ХӘЛЕ Эшнең үтәлү-үтәлмәү, башкарылу-башкарылмау вакытын белдерә торган җөмлә кисәге

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВО МЕРЫ И СТЕПЕНИ** КҮЛӘМ ХӘЛЕ Процессның яки билгенең күләмен, дәрәҗәсен белдерә торган җөмлә кисәге

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВО МЕСТА** УРЫН ХӘЛЕ Эшнең үтәлү-үтәлмәү, башкарылу-башкарылмау урынын белдерә торган җөмлә кисәге

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВО ОБРАЗА ДЕЙСТВИЯ** РӘВЕШ ХӘЛЕ Эш яки хәлнең ничек һәм ни рәвешле үтәлүен яисә нинди дә булса бер хәлнең яки билгенең билгесен, сыфатын белдерә торган җөмлә кисәге

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВО ПРИЧИНЫ** СӘБӘП ХӘЛЕ Эшнең үтәлү-үтәлмәвенең, башкарылу-башкарылмавының сәбәбен белдерә торган җөмлә кисәге

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВО УСЛОВИЯ** ШАРТ ХӘЛЕ Ияртүче кисәктән аңлашылган процессның киресе үтәлү-үтәлмәвенә шарт булып килгән процессны белдерә торган җөмлә кисәге

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВО УСТУПКИ** КИРЕ ХӘЛ Ияртүче кисәктән аңлашылган процессның киресе булачагын белдерә торган җөмлә кисәге

**ОБСТОЯТЕЛЬСТВО ЦЕЛИ** МАКСАТ ХӘЛЕ Эшнең үтәлү-үтәлмәвенең, башкарылу-башкарылмавының максатын белдерә торган хәл

**ОБЩАЯ ЛИНГВИСТИКА** ГОМУМИ ЛИНГВИСТИКА Тел белеменең тел процессына хас гомумкешелек үзлекләрен ачыклауга юнәлдерелгән төрле телләрне, тел төркемнәрен өйрәнә торган бүлеге

**ОБЩАЯ РИТОРИКА** ГОМУМИ РИТОРИКА Тел белеменең матур әдәбиятка карамаган коммуникатив адекват характердагы текст тудыру закончалыкларын өйрәнә торган тармагы

**ОБЩАЯ ФОНЕТИКА** ГОМУМИ ФОНЕТИКА Фонетиканың төрле телләр өчен уртак булган гомуми мәсьәләләрне

(артикуляцион мөмкинлекләрне, төрле телләрдәге яңгырашын һ.б.) өйрәнә торган тармагы

**ОБЩЕВОЗВРАТНЫЕ ГЛАГОЛЫ** ГОМУМКАЙТЫМЛЫ ФИГЫЛЬЛӘР Субъектның объектсыз торышын белдергән фигыльләр (мәс., *күңелсезләнергә, шатланырга, беспокоиться*)

**ОБЩЕГОСУДАРСТВЕННЫЙ ЯЗЫК** ГОМУМДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ *к.* **государственный язык**

**ОБЩЕЕ ЯЗЫКОЗНАНИЕ** ГОМУМИ ТЕЛ БЕЛЕМЕ Тел белеменең телләргә хас гомуми үзлекләрне, уртак күренешләрне өйрәнә торган тармагы

**ОБЩЕЛИНГВИСТИЧЕСКИЙ** ГОМУМЛИНГВИСТИК Лингвистик күренешләрне, закончалыкларны телнең гомуми үзлекләре итеп аңлата торган

**ОБЩЕНАРОДНАЯ ЛЕКСИКА** ГОМУМХАЛЫК ЛЕКСИКАСЫ Шул телдә сөйләшүчеләрнең барысына да таныш, һәммәсе тарафыннан да кулланыла торган сүзләр

**ОБЩЕОТРИЦАТЕЛЬНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ГОМУМИ ИНКЯР ҖӨМЛӘ Инкяр хәбәрле, ягъни иянең билгесе (ике составлы җөмләдә), яки иясез җөмләдә баш кисәк белән белдерелгән эше-торышы инкяр ителгән җөмлә

**ОБЩЕПОЭТИЧЕСКАЯ МЕТАФОРА** ГОМУМПОЭТИК МЕТАФОРА Метафораларның тыңлаучы, укучы тарафыннан сурәт, образ буларак кабул ителә торган төре (мәс., *салкын караш*)

**ОБЩЕСЛАВЯНСКАЯ ЛЕКСИКА** ГОМУМСЛАВЯН ЛЕКСИКАСЫ Славян телләрендә уртак баба телдән мирас булып килгән сүзләр

**ОБЩЕСТВЕННЫЕ ТЕОРИИ** ИҖТИМАГЫЙ ТЕОРИЯЛӘР Тел барлыкка килүне кешенең аң үсеше һәм хезмәттә туган иҗтимагый ихтыяҗлар белән бәйләп караган теорияләр

**ОБЩЕТЮРКСКАЯ ЛЕКСИКА** ГОМУМТӨРКИ ЛЕКСИКА Төрки телләрдә уртак баба телдән мирас булып килгән сүзләр

**ОБЩЕУПОТРЕБИТЕЛЬНАЯ МЕЖСТИЛЕВАЯ ЛЕКСИКА** ГОМУМИ КУЛЛАНЫЛЫШТАГЫ СТИЛЬАРА ЛЕКСИКА

Кулланылышы стильләргә бәйсез, стилистик синонимнары булмаган сүзләр

**ОБЩЕЯЗЫКОВАЯ МЕТАФОРА** ГОМУМТЕЛ МЕТАФОРАСЫ Метафораларның күчерелмә мәгънәләре стандартлашкан һәм туры мәгънә буларак кабул ителә торган төре (мәс., *тау бите*)

**ОБЩИЙ ГЛАГОЛ** УРТАК ЮНӘЛЕШ ФИГЫЛЕ *к.* **общий залог**

**ОБЩИЙ ЗАЛОГ** УРТАКЛЫК ЮНӘЛЕШЕ Рус телендә фигыльнең -ся га беткән формадан тыш башка юнәлеш формалары булмаган һәм субъектның эчке халәтен белдерә торган категориаль формасы (мәс., *бояться, смеяться*)

**ОБЩИЙ РОД** УРТАК РОД Мәгънәсе буенча мужской родка да, женский родка да карый ала торган род (мәс., рус телендә – *плакса, сирота, Седых*)

**ОБЩИЙ ЯЗЫК** ГОМУМХАЛЫК ТЕЛЕ *к.* **койне**

**ОБЪЕКТНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ОБЪЕКТ МӘГЪНӘСЕ Эш юнәлгән затны белдерү

**ОБЪЕКТНОЕ ОТНОШЕНИЕ** ОБЪЕКТ МӨНӘСӘБӘТЕ Сүзтезмәдә ияртүче сүз (гадәттә фигыль) белән ияррүче сүз (гадәттә кыек килештәге исем) арасында барлыкка килгән мөнәсәбәт, ягъни эш-хәрәкәт белән шул эш юнәлгән предмет арасындагы мөнәсәбәт (мәс., *китап уку, рәсем ясау*)

**ОБЪЕКТНЫЙ ИНФИНИТИВ** ОБЪЕКТЛЫ ИНФИНИТИВ Башка затның эш-хәрәкәтен белдергән фигыль алды инфинитивы; җөмләдә тәмамлык булып килә (мәс., *эшләргә кушу*, *попросил остаться*)

**ОБЪЯСНИТЕЛЬНЫЙ РОДИТЕЛЬНЫЙ** АҢЛАТМАЛЫ РОДИТЕЛЬНЫЙ Родительный килеш формаларының ярашмаган аергыч функциясендә кулланылышы

**ОГЛУШЕНИЕ ЗВУКА** САҢГЫРАУЛАШУ Тартыкларны әйткәндә артикуляциянең көчәюе һәм тавышның кимүе нәтиҗәсендә сүз азагында яки саңгырау тартыклар алдында аерым очракларда кайбер яңгырау тартыкларның саңгырау парлары белән чиратлашуы

**ОГРАНИЧИТЕЛЬНЫЕ ЧАСТИЦЫ** ЧИКЛӘГЕЧ КИСӘКЧӘЛӘР Үзләре ияреп килгән сүзнең мәгънәсен чикли торган кисәкчәләр

**ОГУБЛЕНИЕ** ИРЕНЛӘШҮ Авазны әйткәндә, төп артикуляциягә өстәмә рәвештә, иреннәрнең түгәрәкләнеп алга сузылуы

**ОГУБЛЕННЫЕ ГЛАСНЫЕ** ИРЕНЛӘШКӘН СУЗЫКЛАР Артикуляциясе вакытында иреннәр түгәрәкләнеп алга сузыла торган сузыклар (мәс., *о, ө, у, ү, ō*)

**ОДИНОЧНЫЕ СОЮЗЫ** ЯЛГЫЗАК ТЕРКӘГЕЧЛӘР Кабатланмый торган теркәгечләр (мәс., *ә, ки, гүя, чөнки*)

**ОДНОВИДНЫЕ ГЛАГОЛЫ** БЕР ВИДЛЫ ФИГЫЛЬЛӘР Башка видта пары булмаган фигыльләр

**ОДНОЗНАЧНОСТЬ, МОНОСЕМИЯ** БЕРМӘГЪНӘЛЕЛЕК Сүзнең бер генә мәгънәсе булу

**ОДНОКОРЕННЫЕ СЛОВА** ТАМЫРДАШ СҮЗЛӘР Бер үк тамырдан ясалган сүзләр (мәс., *сату – сатучы – сатлык*; *двигать – отодвинуть – отодвигать*)

**ОДНОКОРНЕВЫЕ СЛОВА** 1) БЕР ТАМЫРЛЫ СҮЗЛӘР Кушма сүзләрдән аермалы буларак, бер генә тамырдан торган сүзләр (мәс., *көндәш* – бер тамырлы, *төнбоек* – ике тамырлы); 2) *к.* **однокоренные слова**

**ОДНОКРАТНЫЙ ПОДВИД** БЕР ТАПКЫРЛЫ ПОДВИД Эшнең бер генә тапкыр һәм кисәк башкарылуын күрсәтә торган фигыль формасы (мәс., *рубануть – өзеп төшерү*)

**ОДНОРОДНОСТЬ ЧЛЕНОВ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘ КИСӘКЛӘРЕНЕҢ ТИҢДӘШЛЕГЕ Бер-берсеннән бәйсез бер төркем җөмлә кисәкләренең параллель рәвештә бер үк кисәкне ачыклап килүеннән гыйбарәт синтаксик күренеш

**ОДНОРОДНЫЕ ЧЛЕНЫ** ТИҢДӘШ КИСӘКЛӘР Бер үк синтаксик функция башкара торган, бер үк кисәккә караган һәм аңа карата бер үк мәгънә мөнәсәбәтендә булган, үзара тезүле бәйләнештәге җөмлә кисәкләре

**ОДНОРОДНЫЕ ПРИДАТОЧНЫЕ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ТИҢДӘШ ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘР Баш җөмләгә ияреп килгән бер

үк синтаксик функция башкара торган үзара тезүле бәйләнештәге иярчен җөмләләр

**ОДНОСЛОЖНОЕ СЛОВО** БЕР ИҖЕКЛЕ СҮЗ Бер генә иҗектән торган сүз

**ОДНОСОСТАВНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** БЕР СОСТАВЛЫ ҖӨМЛӘ Субъекты һәм предикаты грамматик яктан аерым белдерелмәгән, ягъни бер генә баш кисәге булган җөмлә

**ОДНОСТОРОННЕЕ ДВУЯЗЫЧИЕ** БЕР ЯКЛЫ ИКЕТЕЛЛЕЛЕК Аралашуда катнашучы ике якның берсе генә ике телне дә белү һәм куллану белән характерлана торган икетеллелек

**ОДНОФОКУСНЫЙ** БЕР ФОКУСЛЫ Бер фокус белән артикуляцияләнә торган (мәс., өрелмәле [*ф*], [*в*], [*җ*], [*ғ*] тартыклары)

**ОДНОЧЛЕННОЕ СЛОЖНОПОДЧИНЁННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** БЕР КИСӘКЛЕ ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ Иярчен җөмләсе баш җөмләдәге бер сүзгә яки сүзтезмәгә ияреп, аны конкретлаштырып килгән иярченле кушма җөмлә

**ОДНОЯЗЫЧИЕ** БЕРТЕЛЛЕЛЕК Бер телдә аралашу, монолингвизм

**ОДНОЯЗЫЧНЫЙ СЛОВАРЬ** БЕР ТЕЛЛЕ СҮЗЛЕК Барлык информация дә бер тел сүзләре белән бирелгән сүзлек

**ОДУШЕВЛЁННЫЕ СУЩЕСТВИТЕЛЬНЫЕ** ҖАНЛЫ ИСЕМНӘР Җанлы предметларны белдерә торган исемнәр

**ОДУШЕВЛЁННОСТЬ/НЕОДУШЕВЛЁННОСТЬ** ҖАНЛЫЛЫК/ҖАНСЫЗЛЫК Исемнәрдә аларны җансыз яисә җанлы исемнәргә бүлеп карый торган грамматик категория

**ОЗВОНЧЕНИЕ** ЯҢГЫРАУЛАШУ Саңгырау тартыкларның нинди дә булса бер позициядә яңгырау парлары белән алмашынуы

**ОЙКОНИМИКА** ОЙКОНИМИКА Ономастиканың торак пунктлар атамаларын өйрәнә торган тармагы

**ОКАНЬЕ** ОЛАШТЫРУ 1) [*Ōлаштыру*] Басымсыз иҗектә [*а*] белән [*о*] авазларын аеру, дөрес әйтү; рус теленең төньяк

сөйләшләренә хас; 2) [*А*] авазын беренче иҗекләрдә, [*ы*] авазын [*о*]дан соңгы иҗекләрдә [*о*] авазына тартым итеп әйтү (мәс., *балалар* [*ба*$^{о}$*ла*$^{о}$*лар*])

**ОККАЗИОНАЛИЗМ** ОККАЗИОНАЛИЗМ Киң кулланылышта булмаган, берәр авторның әсәрендә генә очрый торган неологизм

**ОКОНЧАНИЕ, ФЛЕКСИЯ** КУШЫМЧА Нигез составында булмаган, морфологик һәм синтаксик бәйләнешләрне тәэмин итә торган морфема

**ОКОНЧАНИЯ ЛИЦА И ЧИСЛА** ЗАТ-САН КУШЫМЧАЛАРЫ Фигыльдә бер үк вакытта затны да, санны да белдерә торган зат кушымчалары (мәс., *-м, -ң, -мын/-мен*)

**ОКРАСКА** БИЗӘК, ТӨСМЕР Сүзнең төп, предмет-логик мәгънәсенә өстәмә салынган эмоциональ-экспрессив, бәяләү характерындагы стилистик мәгънә

**ОКРУГЛЕНИЕ** ИРЕНЛӘШҮ *к.* **огубление**

**ОКСИДЕНТАЛЬ** ОКСИДЕНТАЛЬ Интернациональ лексикага нигезләнгән Э. Вааль тәкъдим иткән ясалма халыкара тел

**ОКСИТОН** ОКСИТОН Соңгы иҗегенә кискен һәм көчле басым төшкән сүз

**ОКСЮМОРОН** ОКСЮМОРОН Ике капма-каршы мәгънәдәге сүзнең кушылуыннан гыйбарәт стилистик фигура (мәс., *яман яхшы, сакаллы сабый*)

**ОЛИЦЕТВОРЕНИЕ** ҖАНЛАНДЫРУ Җан ияләренә хас сыйфатларны җансыз предметларга күчерү, аларны җанлы итү; тропның бер төре (мәс., *җил улау*)

**ОМОГРАФЫ** ОМОГРАФЛАР Язылышлары бер, әйтелешләре төрле булган омонимнар (мәс., *за'мок – замо'к*)

**ОМОМОРФЕМЫ** ОМОМОРФЕМАЛАР Омонимик мәгънәләргә ия морфемалар

**ОМОНИМИКА** ОМОНИМИКА 1) Лексикологиянең омонимнарны өйрәнә торган тармагы; 2) Берәр телнең омонимнары җыелмасы

**ОМОНОМИЧЕСКАЯ ПАРАДИГМА** ОМОНИМИК ПАРАДИГМА График яктан бер үк, семантик яктан төрле булган сүзләр төркеме

**ОМОНИМЫ** ОМОНИМНАР, АВАЗДАШ СҮЗЛӘР Яңгырашлары яки язылышлары бердәй, мәгънәләре төрле булган сүзләр (мәс., *яз* – иртә яз*, яз* – матур яз; *ката* – киез ката*, ката* – төн ката)

**ОМОФОНЫ** ОМОФОННАР Яңгырашлары бер, язылышлары төрле булган сүзләр (мәс., *балавыз – бал авыз, карбыз – кар-боз*)

**ОМОФОРМЫ** ОМОФОРМАЛАР Билгеле бер грамматик формада гына омоним булып килә торган сүзләр (мәс., *үпкәләр – үпкәләр, сабын – сабын*)

**ОНИМЫ** ОНИМНАР Индивидуаль предметларны, аларның үзенчәлекләренә бәйсез рәвештә атаган исемнәр; ялгызлык исемнәр

**ОНОМАСИОЛОГИЯ** ОНОМАСИОЛОГИЯ Лексикологиянең сүзнең атау функциясен, предметларга, күренешләргә атама бирү закончалыкларын өйрәнә торган тармагы

**ОНОМАСТИКА** ОНОМАСТИКА 1) Телдәге ялгызлык исемнәр; 2) Тел белеменең ялгызлык исемнәрне өйрәнә торган тармагы

**ОНОМАТОЛОГИЯ** ОНОМАТОЛОГИЯ 1) *к.* **ономасиология**; 2) *к.* **ономастика**

**ОНОМАТО-ПОЭТИЧЕСКАЯ ТЕОРИЯ** АВАЗ ИЯРТЕМНӘРЕ ТЕОРИЯСЕ Телнең килеп чыгышын аваз һәм аваз ияртемнәренә бәйләп аңлату

**ОПИСАТЕЛЬНАЯ ДЕФИНИЦИЯ** ТАСВИРЛАМА ДЕФИНИЦИЯ Сүзнең мәгънәсен чынбарлыктагы объектны тасвирлап аңлатып бирү – ыруг төшенчәсен (гиперсема) кертү һәм дифференциаль үзенчәлекләрне (гипосема) ачу юлы белән аңлату

**ОПИСАТЕЛЬНАЯ ЛИНГВИСТИКА** ТАСВИРЛАМА ЛИНГВИСТИКА Тел белеменең телне синхрон планда өйрәнә торган бүлеге

**ОПИСАТЕЛЬНЫЙ СИНТАКСИС** ТАСВИРЛАМА СИНТАКСИС *к.* **синхронический синтаксис**

**ОПИСАТЕЛЬНАЯ ФОНЕТИКА** ТАСВИРЛАМА ФОНЕТИКА Нинди дә булса телнең аваз системасын үзенә аерым бергәлек буларак синхрон планда өйрәнә торган тел белеме тармагы

**ОПИСАТЕЛЬНЫЙ МЕТОД** ТАСВИРЛАМА МЕТОД Телнең билгеле бер чорда иҗтимагый яшәеш рәвешен сурәтли, тел механизмының элементларын, кисәкләрен тасвирлау һәм анализлау, шулай ук фонемаларга, морфемаларга, сүзләргә, грамматик формаларга һәм категорияләргә билгеләмәләр бирү методы

**ОПИСКА** ТӨГӘЛСЕЗЛЕК Игътибарсызлык аркасында җибәрелгән язу хатасы

**ОПЕРАЦИОННЫЙ АНАЛИЗ** ОПЕРАЦИОН АНАЛИЗ Күпмәгънәле сүзнең мәгънәләрен контекстларны трансформацияләү юлы белән өйрәнү

**ОПОРНОЕ СЛОВО СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** СҮЗТЕЗМӘДӘГЕ ТӨП СҮЗ Сүзтезмәдә башка сүзләрне ияртеп килгән синтаксик бәйсез сүз

**ОПОРНЫЙ ЗВУК** ТӨП АВАЗ Фонологик функцияне үтәү өчен җитәрлек дәрәҗәдә аерымланган аваз

**ОПОРНЫЙ СОГЛАСНЫЙ** ТАЯНЫЧ ТАРТЫК Рифма иҗегендәге сузыктан алда килгән тартык аваз

**ОППОЗИЦИЯ** ОППОЗИЦИЯ Аермаларын билгеләү максатыннан ике яки берничә төрдәге тел берәмлеген капма-каршы куеп карау

**ОПРЕДЕЛЕНИЕ** АЕРГЫЧ Җөмләнең предмет төшенчәсен атаган кисәгенә ияреп, шуларның билгесен, сыйфатын ачыклап килә торган иярчен кисәк

**ОПРЕДЕЛЁННОЕ (КАТЕГОРИЧЕСКОЕ) БУДУЩЕЕ ВРЕМЯ** БИЛГЕЛЕ (КАТЕГОРИК) КИЛӘЧӘК ЗАМАН Фигыльнең эш, хәл, хәрәкәтнең киләчәктә һичшиксез булачагын хәбәр итә торган заман төре (мәс., *киләчәк, барачак, укыячак, эшләячәк*)

**ОПРЕДЕЛЁННОЕ ПРОШЕДШЕЕ (КАТЕГОРИЧЕСКОЕ, ОЧЕВИДНОЕ) ВРЕМЯ** БИЛГЕЛЕ (КАТЕГОРИК) ҮТКӘН ЗАМАН Фигыльнең сөйләүче үзе күргән, белгән эш, хәл, хәрәкәт турында хәбәр итә торган заман төре (мәс., *килде*, *барды, кайтты, китте* )

**ОПРЕДЕЛЁННО-КОЛИЧЕСТВЕННЫЕ ЧИСЛИТЕЛЬНЫЕ** МИКЪДАР САННАРЫ Бер төрдәге предметларның микъдарын белдереп килә торган, өстәмә кушымчалар алмаган саннар

**ОПРЕДЕЛЁННО-ЛИЧНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** БИЛГЕЛЕ ҮТӘҮЧЕЛЕ ҖӨМЛӘ Баш кисәге 1 нче яки 2 нче затта хикәя фигыль (хәзерге, киләчәк заманнарда) боерык фигыль белән белдерелгән берсоставлы иясез җөмлә (мәс., *Һушыгыз, миңа ачуланмагыз. Лейся песня звонкая, вылей трель унылую.* С. Есенин)

**ОПРЕДЕЛЁННЫЙ ЧЛЕН** БИЛГЕЛЕ КИСӘК Сүзгә билгелелек өсти торган элемент

**ОПРЕДЕЛИТЕЛЬНО-УТОЧНИТЕЛЬНЫЕ ЧАСТИЦЫ** АНЫКЛАУЧЫ КИСӘКЧӘЛӘР Үзе ияреп килгән сүзгә аныклау төсмере өсти торган кисәкчәләр

**ОПРЕДЕЛИТЕЛЬНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** АЕРГЫЧ МӘГЪНӘСЕ Предметның билгесен, сыйфатын, микъдарын белдерү

**ОПРЕДЕЛИТЕЛЬНЫЕ МЕСТОИМЕНИЯ** БИЛГЕЛӘҮ АЛМАШЛЫКЛАРЫ Предметның, затның гомумиләштерелгән сыйфатын белдерә торган алмашлыклар

**ОПРЕДЕЛИТЕЛЬНЫЕ НАРЕЧИЯ** БИЛГЕ РӘВЕШЛӘРЕ Эш яки билгенең сыйфатын, санын, хәл итү ысулын, микъдарын, күләм-чамасын характерлый торган рәвешләр (мәс., *ерак, күптән, кызмача; в насмешку, со зла*)

**ОПРЕДЕЛЯЕМОЕ** АЕРЫЛМЫШ Җөмләдә аергыч ачыклап килгән сүз

**ОПРОЩЕНИЕ** ОПРОЩЕНИЕ Сүзнең морфологик төзелеше үзгәрү, ягъни элек аерым морфемаларга таркала торган ясалма нигез морфемаларының берегүе нәтиҗәсендә ясалма булмаган,

морфологик яктан таркалмый торган тамырлашкан сүзгә әверелү күренеше; *к.* **деэтимологизация**

**ОПТАТИВ** ОПТАТИВ Теләк фигыль төркемчәсе

**ОРГАНЫ ПРОИЗНОШЕНИЯ** АВАЗЛАРНЫ ӘЙТҮ ОРГАННАРЫ Авазларны модельләштерә, сыйфат ягын тудыра торган органнар (пассив һәм актив органнар)

**ОРГАНЫ РЕЧИ** СӨЙЛӘМ ОРГАННАРЫ Сөйләм авазларын ясауда катнаша торган әгъзалар

**ОРИЕНТАЛИСТИКА** ОРИЕНТАЛИСТИКА Көнчыгыш халыклары телен, мәдәниятын, йолаларын һ.б. өйрәнә торган фән

**ОРОНИМИКА** ОРОНИМИКА Ономастиканың рельеф атамаларын өйрәнә торган тармагы

**ОРТОЛОГИЧЕСКИЕ СЛОВАРИ** ОРТОЛОГИК СҮЗЛЕКЛӘР Кыен очраклар сүзлекләре

**ОРТОЛОГИЯ** ОРТОЛОГИЯ Сөйләм культурасының әдәби тел нормаларын, дөрес сөйләм закончалыкларын өйрәнә, аның кагыйдәләрен булдыра торган бүлеге

**ОРФОГРАММА** ОРФОГРАММА Язуда орфография кагыйдәләрен төгәл үтәүне таләп иткән очрак

**ОРФОГРАФИЧЕСКИЕ ОШИБКИ** ОРФОГРАФИК ХАТАЛАР Язуда орфография кагыйдәләрен бозу

**ОРФОГРАФИЧЕСКИЙ РАЗБОР** ОРФОГРАФИК ТИКШЕРҮ, ОРФОГРАФИК АНАЛИЗ Сүзнең орфограммаларын билгеләү, дөрес язу кагыйдәләрен куллану

**ОРФОГРАФИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ** ОРФОГРАФИК СҮЗЛЕК, ОРФОГРАФИЯ СҮЗЛЕГЕ Сүзләрнең дөрес язылышы, стандарт булмаган форма ясалышы булганда, андый формалар, аерым очракларда әйтелеш үзенчәлекләре дә күрсәтелгән сүзлек

**ОРФОГРАФИЯ** ОРФОГРАФИЯ Дөрес язу кагыйдәләре җыелмасы

**ОРФОЭПИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ** ОРФОЭПИК СҮЗЛЕК, ОРФОЭПИЯ СҮЗЛЕГЕ Сүзләрнең әдәби телдә дөрес әйтелеше күрсәтелгән сүзлек

**ОРФОЭПИЯ** ОРФОЭПИЯ Дөрес әйтелеш кагыйдәләре, нормалары җыелмасы

**ОСЛОЖНЁННАЯ ФОРМА ГЛАГОЛЬНОГО СКАЗУЕМОГО** ФИГЫЛЬ ХӘБӘРНЕҢ КАТЛАУЛАНДЫРЫЛГАН ФОРМАСЫ Ярдәмче компоненты катлаулы фигыль формасы белән белдерелгән тезмә фигыль хәбәр (мәс., *хотел продолжать работать, готов был продолжать работать*)

**ОСЛОЖНЁННОЕ ГЛАГОЛЬНОЕ СКАЗУЕМОЕ** КАТЛАУЛАНДЫРЫЛГАН ФИГЫЛЬ ХӘБӘР Ике фигыль яки кисәкчәләр белән килгән фигыль белән белдерелгән гади хәбәр (мәс., *Плыли, плыли в небе облака*)

**ОСЛОЖНЁННОЕ ПРОСТОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** КАТЛАУЛАНДЫРЫЛГАН ГАДИ ҖӨМЛӘ Составында я аерымланган кисәкләр, я эндәш сүзләр, я тиңдәш кисәкләр, я аларның комбинациясе булган гади җөмлә

**ОСНОВА** НИГЕЗ Сүзнең хәзерге дәрәҗәсендә лексик мәгънәгә ия булган, сүзьясагыч һәм грамматик кушымчалардан тыш һәм тамырлашкан өлеше

**ОСНОВНАЯ ЧАСТЬ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘНЕҢ ТӨП ӨЛЕШЕ Җөмләнең аерымланган кисәкләрдән, кереш, эндәш сүз һәм иярчен җөмләләрдән тыш өлеше

**ОСНОВНОЙ ВИД ФОНЕМЫ** ФОНЕМАНЫҢ ТӨП ТӨРЕ Фонеманың иң мөстәкыйль, шартларга, позициягә бәйләнмәгән варианты

**ОСНОВНОЙ ЗАЛОГ** ТӨП ЮНӘЛЕШ Фигыльләрдә үтәүченең эшне үзе башкаруын белдерә торган юнәлеш (мәс., *укый*, *төзи*)

**ОСНОВНОЙ ПАДЕЖ** БАШ КИЛЕШ Кушымчалары булмаган объект, субъект мөнәсәбәтләрен белдерә торган килеш (мәс., *китап укыла, бала йоклый*)

**ОСНОВНОЙ СЛОВАРНЫЙ ФОНД** ТӨП СҮЗЛЕК ФОНДЫ Телнең иң мөһим, киң кулланылыштагы сүзләрдән торган лексик байлыгы, иң тотрыклы пласты

**ОСНОВНЫЕ ФОРМЫ ГЛАГОЛА** ФИГЫЛЬНЕҢ ТӨП ФОРМАЛАРЫ Бөтен фигыль парадигмасының морфонологик нигезе булган фигыль формалары

**ОСНОВООБРАЗОВАТЕЛЬНЫЕ АФФИКСЫ** НИГЕЗ ЯСАГЫЧ АФФИКСЛАР Нигез ясауда гына катнаша торган аффикслар

**ОСНОВОИЗОЛИРУЩИЕ ЯЗЫКИ** НИГЕЗНЕ ИЗОЛЯЦИЯЛӘҮЧЕ ТЕЛЛӘР Сүз төрләнеше булмаган, ләкин сүзьясалышы белән характерлана торган аморф телләр

**ОСНОВОСЛОЖЕНИЕ** НИГЕЗЛӘР КУШЫЛУ Ике яки аннан да күбрәк нигезнең кушылуыннан гыйбарәт сүзьясалыш ысулы

**ОТВЛЕЧЁННЫЕ СУЩЕТВИТЕЛЬНЫЕ** АБСТРАКТ ИСЕМНӘР Фикерләү аша аңлашылган төшенчәләрне, предметлаштырылган билгеләрне, эш-хәрәкәтләрне үтәүчегә мөнәсәбәтсез рәвештә атый торган исемнәр (мәс., *зиһен, шатлык, кайгы, тазалык, байлык*)

**ОТГЛАГОЛЬНЫЕ НАРЕЧИЯ** ФИГЫЛЬДӘН ЯСАЛГАН РӘВЕШЛӘР Фигыльдән, аның вид, вакыт, залог мәгънәләрен югалтып, ясалган рәвешләр (мәс., *лёжа, сидя*)

**ОТГЛАГОЛЬНЫЕ ПРИГАГАТЕЛЬНЫЕ** ФИГЫЛЬДӘН ЯСАЛГАН СЫЙФАТЛАР Фигыль нигезләрдән ясалган һәм алар белән генетик бәйләнешләре генә саклanган сыйфатлар (мәс., *копировальный, восклицательный*)

**ОТГЛАГОЛЬНЫЕ СУЩЕСТВИТЕЛЬНЫЕ** ФИГЫЛЬДӘН ЯСАЛГАН ИСЕМНӘР Фигыль нигезләрдән ясалган һәм предметлаштырылган эш-хәрәкәтне белдерә торган исемнәр (мәс., *вывоз, установление*)

**ОТДЕЛИТЕЛЬНЫЙ ПАДЕЖ** АЕРУ КИЛЕШЕ *к.* **аблатив**

**ОТКРЫТЫЕ СТРУКТУРЫ** АЧЫК СТРУКТУРАЛАР Ачык рәт барлыкка китергән, ягъни ике, өч һәм аннан да күбрәк өлешләрдән торган, ул өлешләрнең тагын да артуы мөмкин булган кушма җөмләләр

**ОТКРЫТЫЙ СЛОГ** АЧЫК ИҖЕК Сузык авазга тәмамланган иҗек (мәс., *ба-ба*)

**ОТМИРАЮЩИЕ ЯВЛЕНИЯ** ҮЛЕП БАРГАН КҮРЕНЕШЛӘР Өлкән буын вәкилләре телендә, әдәби әсәрләрдә стиль чарасы буларак очрый торган, әмма шул телдә сөйләшүчеләрнең күпчелеге тарафыннан кулланылмый торган тел күренешләре

**ОТНОСИТЕЛЬНОЕ ПОДЧИНЕНИЕ** НИСБИ ИЯРҮ Бер җөмләнең икенчесенә мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә иярүе

**ОТНОСИТЕЛЬНЫЕ ПРИЛАГАТЕЛЬНЫЕ** НИСБИ СЫЙФАТЛАР Бер әйбернең икенчесенә булган мөнәсәбәтен билге итеп күрсәтә торган ясалма сыйфатлар (мәс., *җәйге, фәнни*)

**ОТНОСИТЕЛЬНЫЕ ПРОКЛИТИКИ И ЭНКЛИТИКИ** ЧАГЫШТЫРМАЧА ПРОКЛИТИКАЛАР ҺӘМ ЭНКЛИТИКАЛАР Басымсыз сүзләрнең, басымлы сүз белән бергә килгәндә, мөстәкыйль сүзгә хас фонетик үзенчәлекләрен бөтенләй югалтмау күренеше (мәс., *мороз, но солнце*)

**ОТНОСИТЕЛЬНОЕ СЛОВО** МӨНӘСӘБӘТЛЕ СҮЗ Ике сүз арасындагы ачыклаулы һәм хәбәрлекле мөнәсәбәткә буйсына, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләп килә, тулы җөмләне алыштыра ала торган аналитик бәйләүче чара (мәс., *кем – шул, шундый*)

**ОТРИЦАНИЕ** ИНКЯР ИТҮ Җөмлә кисәкләре арасындагы бәйләнешне реаль түгел дип аңлауны лексик, фразеологик, синтаксик чаралар ярдәмендә белдерү

**ОТРИЦАТЕЛЬНО-ВОПРОСИТЕЛЬНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ИНКЯР СОРАУ ҖӨМЛӘ Формаль яктан сорау һәм инкяр мәгънәсен, чынлыкта әдәпле сорауны белдерә торган җөмлә (мәс., *Ул бу турыда сөйләшмәс микән?*)

**ОТРИЦАТЕЛЬНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ИНКЯР ҖӨМЛӘ 1) Инкяр кисәкчәсе яки кушымчасы булган җөмлә (мәс., *Ул укымый. Көн матур түгел*); 2) Аерым кисәкләре арасындагы бәйләнеш реаль түгел дип уйланылган җөмлә

**ОТРИЦАТЕЛЬНЫЕ СЛОВА** ИНКЯР СҮЗЛӘРЕ Инкярны, юклыкны белдергән сүзләр (фигыльләр, алмашлыклар, рәвешләр, кисәкчәләр, теркәгечләр, предикатив сүзләр)

**ОТРИЦАТЕЛЬНЫЕ МЕСТОИМЕНИЯ** ЮКЛЫК АЛМАШЛЫКЛАРЫ Затның, предметның, билгенең юклыгын белдергән алмашлыклар (мәс., *беркем, һичкем, берни, һичбер*)

**ОТРИЦАТЕЛЬНЫЕ ЧАСТИЦЫ** ИНКЯР КИСӘКЧӘЛӘРЕ Үзе ияреп килгән сүзгә инкяр мәгънәсе бирә торган кисәкчәләр (мәс., рус телендә *не, ни* кисәкчәләре)

**ОТСТУПАЮЩЕЕ УДАРЕНИЕ** ЧИГЕНЕШЛЕ БАСЫМ Чыганак телдәгедән аермалы буларак, алган телнең акцентуацион законнары нигезендә алынма сүзләрдә сүз ахырындагы басымның сүз башына күчүе

**ОТСЫЛОЧНАЯ ДЕФИНИЦИЯ** СЫЛТАМАЛЫ ДЕФИНИЦИЯ Мәгънәләрнең мотивлаштыручы һәм мотивлашкан бәйләнешләрен саклаган сүзнең билгеле бер категориягә караганлыгын күрсәтеп торган дефиниция

**ОТТЕНОК ЗНАЧЕНИЯ** МӘГЪНӘ ТӨСМЕРЕ Сүзнең төп номинатив мәгънәсенә өстәмә, бераз гына аерылып торган, янәшә ясалма мәгънәсе

**ОТТЕНОК ФОНЕМЫ** ФОНЕМА ТӨСМЕРЕ *к.* **аллофон**

**ОТЧЕСТВО** ОТЧЕСТВО Әтисенең исеме

**ОТЫМЕННЫЕ ГЛАГОЛЫ** ИСЕМНӘН ЯСАЛГАН ФИГЫЛЬЛӘР Исем нигезләрдән кушымчалау ысулы белән ясалган фигыльләр (мәс., *уйла, күзлә, сана*)

**ОТЫМЕННЫЕ ПРИЛАГАТЕЛЬНЫЕ** ИСЕМНӘН ЯСАЛГАН СЫЙФАТЛАР Исем нигезләрдән кушымчалау ысулы белән ясалган сыйфатлар (мәс., *буранлы, ылыслы, ялкынлы*)

**ОТЫМЕННЫЕ ПРЕДЛОГИ** ИСЕМНӘН ЯСАЛГАН БӘЙЛЕКЛӘР Исем нигезләрдән ясалган бәйлекләр (мәс., *сәбәпле, чаклы, төсле*)

**ОФИЦИАЛЬНО-ДЕЛОВАЯ ЛЕКСИКА** РӘСМИ ЭШ ЛЕКСИКАСЫ Составында тормышның дипломатик, юридик, официаль эш һ.б.ш. өлкәләрдән күп санлы парадигмалар булган, социаль-функциональ характердагы стандартлашкан һәм унификацияләнгән сүзләр

**ОФИЦИАЛЬНО-ДЕЛОВОЙ СТИЛЬ** РӘСМИ ЭШ СТИЛЕ Административ-хокукый эшчәнлек, кешеләр, илләр, дәүләтләр арасындагы хокукый мөнәсәбәтләр белән бәйле стандартлашкан берәмлекләрдән торган функциональ стиль

**ОФИЦИАЛЬНЫЙ ЯЗЫК** РӘСМИ ТЕЛ 1) *к.* **официально-деловая лексика**; 2) Берәр оешма, зур чара һ.б.ш. өчен эш теле итеп билгеләгән тел (мәс., *конгрессның рәсми теле*)

**ОШИБКА** ХАТА Сөйләм берәмлеген грамматик, орфографик, орфоэпик, стилистик яки синтаксик яктан дөрес кулланмау

# П

**ПАДЕЖ** КИЛЕШ Билгеле объектның башка объектларга, эш-хәрәкәткә, билгегә карата мөнәсәбәтен кушымча ярдәмендә белдерә торган грамматик категория

**ПАЛАТАЛИЗАЦИЯ** ПАЛАТАЛЬЛӘШҮ Авазның төп артикуляциясенә өстәмә рәвештә тел уртасының каты аңкауга күтәрелүе һәм шуның нәтиҗәсендә тартыкларның йомшаграк, нечкәрәк әйтелүе (мәс., рус телендә *взят – взять*)

**ПАЛАТОГРАФИЯ** ПАЛАТОГРАФИЯ Эксперименталь фонетикада иң беренче ысулларның берсе: каты аңкауга урнаштырылган пластинкада телнең эзе төшеп калып, шул эз буенча артикуляциядә телнең ничек катнашуы билгеләнә

**ПАЛЕОГРАФИЯ** ПАЛЕОГРАФИЯ Тел белеменең борынгы язма истәлекләрне, башлыча аларның тышкы үзенчәлекләрен: язу ысулын, хәреф формаларын, язу материалларын һ.б.ш. өйрәнеп, аларның язылу вакытын, урынын билгеләү белән шөгыльләнә торган тармагы

**ПАНХРОНИЯ** ПАНХРОНИЯ Тел күренешләрен гомуми, универсаль, вакыт белән бәйле булмаган, кеше теленә гомумән хас нәрсә дип карау

**ПАРАДИГМА** ПАРАДИГМА 1) Берәр сүзгә хас булган үзгәреш формаларының тулы системасы, бер лексеманы

тәшкил иткән барлык формалары; 2) Гомуми (интеграль) семантик билгеләре белән берләшкән һәм дифференциаль билгеләре нигезендә группада бер-беренә капма-каршы куелган сүзләр җыелмасы. Шушы нигездә 6 төр парадигма аерыла: омонимик, синонимик, антонимик, тематик, гиперо-гипонимик, лексик-семантик; 3) Һәркем тарафыннан танылган һәм билгеле вакыт дәвамында фәнни җәмәгатьчелек өчен мәсьәләне кую һәм хәл итү үрнәге булып торган фәнни казанышлар; фәнни тикшеренүнең методологик нигезе. 1962 елда Т. Кун тарафыннан кертелгән термин

**ПАРАДИГМА ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘ ПАРАДИГМАСЫ Җөмләнең морфологик төрләренең барысы да

**ПАРАДИГМАТИКА** ПАРАДИГМАТИКА Тел берәмлекләрен бердәм тел системасының элементлары буларак, хәтердә капма-каршы кую бәйләнешендә берләштерелгән структур берәмлекләр буларак карау; *киресе:* **синтагматика**

**ПАРАДИГМАТИЧЕСКИЕ АССОЦИАЦИИ** ПАРАДИГМАТИК АССОЦИАЦИЯЛӘР Сөйләм эшчәнлеген өйрәнә торган эксперименталь лингвистикада стимул сүз белән бер үк грамматик класска караган реакция сүзләр (мәс., *мәче – эт, абый – апа*)

**ПАРАДИГМАТИЧЕСКИЕ ОТНОШЕНИЯ** ПАРАДИГМАТИК МӨНӘСӘБӘТЛӘР Төрле берәмлекләрнең мәгънәләре үзара бәйле булу күренеше

**ПАРАЛИНГВИСТИКА** ПАРАЛИНГВИСТИКА Тел белеменең сүзләр белән беррәттән мәгълүмат тапшыруда катнаша торган башка чараларны өйрәнә торган тармагы

**ПАРАЛЛЕЛЬНАЯ ПОЛИСЕМИЯ** ПАРАЛЛЕЛЬ КҮПМӘГЪНӘЛЕЛЕК Күпмәгънәле фразеологик берәмлекләрдә мәгънәләр (фразеологик-семантик вариантлар) тигез хокуклы булу

**ПАРАПТИКСИС** ПАРАПТИКСИС Билгеле морфонологик һәм фонетик шартлар аркасында сүздә булмаган өстәмә аваз барлыкка килү, эпентеза

**ПАРЕМИЯ** ПАРЕМИЯ Фольклорның кечкенә жанрлар тибы: әйтем, мәкаль, табышмак, сынамыш, тапкыр сүз, теләк, тизәйт-

кеч һ.б. Халыкның тәҗрибәсен, дөньяга карашын чагылдыра, кыскалык һәм форма тотрыклылыгы белән характерлана

**ПАРОНИМ** ПАРОНИМ Яңгырашлары белән якын, әмма тәңгәл түгел, мәгънәләре ягыннан аерыла торган сүзләр (мәс., рус телендә: *командированный – командировочный*, татар телендә: *тәкъдир итү – тәкъдим итү*)

**ПАРОНИМИЯ** ПАРОНИМИЯ Ике фонетик сүзнең өлешчә тәңгәл килүе

**ПАРЦЕЛЛЯЦИЯ** ПАРЦЕЛЛЯЦИЯ Әйтелмәне мәгънәгә карап мөстәкыйль өлешләргә интонацион яктан бүлү

**ПАССИВНАЯ ЛЕКСИКА** ПАССИВ ЛЕКСИКА Сүзлек байлыгының сөйләмдә сирәк кулланыла торган катламы: актив кулланылышка кереп өлгермәгән яңа сүзләр яки кулланылыштан төшеп калган иске сүзләр *(скрининг, праймирес; чабата, ыштыр)*

**ПАССИВНЫЕ ОРГАНЫ** ПАССИВ ОРГАННАР Артикуляция процессында хәрәкәтләнмичә генә катнаша торган сөйләм органнары: каты аңкау, тешләр, теш казналары, борын куышлыгы һ.б.

**ПАССИВНЫЙ СЛОВАРЬ** ПАССИВ СҮЗЛЕК Гомуми аңлаешлы, таныш, әмма гадәти аралашуда кулланылмый торган сүзләр байлыгы

**ПАТРОНИМ** ПАТРОНИМ Кешене әтисенең исеме белән атаган исем, әтисенең исеме

**ПАТРОНИМИЗАЦИЯ** ПАТРОНИМЛАШУ Кешене атасының исеме белән атый башлау, атасының исеме кеше исеменә ялганып шәхесен билгеләүче өстәмә исем буларак кулланыла башлау күренеше

**ПАУЗА** ПАУЗА, ТЫНЫШ Синтаксик, интонацион, эмоциональ максатлардан чыгып сөйләм процессын туктатып тору, сөйләмдә барлыкка килгән өзеклек

**ПЕРЕДНЕНЁБНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** АҢКАУ АЛДЫ ТАРТЫКЛАРЫ Тартыкларның ясалыш урыны буенча классификациясендәге бер төркемчәсе (мәс., *р, ш* тартыклары)

**ПЕРЕДНЕЯЗЫЧНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ТЕЛ АЛДЫ ТАРТЫКЛАРЫ Тартыкларның ясалыш урыны буенча классификациясендәге бер төркемчәсе: телнең алгы өлеше яки очы катнашында артикуляцияләнә торган тартыклар (мәс., *д, т, с* тартыклары)

**ПЕРЕДНИЙ РЯД** АЛГЫ РӘТ Телнең алгы өлеше аңкауның алгы өлешенә табан күтәрелеп ясалган сузык авазларның фонологик үзенчәлеге

**ПЕРЕНОС** ЮЛДАН ЮЛГА КҮЧҮ Юл азагында, сүзне иҗекләргә бүлүнең гомум кабул ителгән кагыйдәләрен истә тотып, сүзне язуны өзү

**ПЕРЕНОСНОЕ ЗНАЧЕНИЕ СЛОВА** СҮЗНЕҢ КҮЧЕРЕЛМӘ МӘГЪНӘСЕ Сүзнең төп – туры мәгънәсеннән соң, бер предмет яки билге белән башка предмет яки билге арасындагы функциональ-ассоциатив бәйләнеш нәтиҗәсендә метафора, метонимия, синекдоха, функция буенча күчеш юлы белән барлыкка килгән икенчел мәгънәсе

**ПЕРЕРАЗЛОЖЕНИЕ** МОРФЕМА ЧИКЛӘРЕ ҮЗГӘРҮ Сүздә морфема чикләре үзгәрү, күчү, ешрак нигезләр кыскару исәбенә кушымчалар киңәюдән гыйбарәт морфонологик күренеш (мәс., рус телендә, элек: *сн+я+ть;* хәзер *с+ня+ть*)

**ПЕРЕХОДНОСТЬ** КҮЧЕМЛЕЛЕК Фигыльләрдә лексик-семантик категория: фигыльнең туры объектны белдергән сүз белән мөнәсәбәткә керүе

**ПЕРЕХОДНЫЕ ГЛАГОЛЫ** КҮЧЕМЛЕ ФИГЫЛЬЛӘР Туры объектны белдергән сүз белән бәйле фигыльләр

**ПЕРИФЕРИИ** ПЕРИФЕРИЯЛӘР 1) Сүзнең төп мәгънәсеннән торган үзәк белән бергә лексик мәгънә тудыруда катнашкан мәгънәләр 2) Концептны белдерүнең ассоциацияле, образлы чаралары

**ПЕРИФЕРИЙНЫЕ ПАДЕЖИ** ПЕРИФЕРИЯ КИЛЕШЛӘРЕ Текстта, төп роль уйнаган баш яки төшем килешләреннән аермалы буларак, сирәгрәк кулланыла һәм өстәмә роль үти торган килешләр: урын-вакыт, иялек, чыгыш килешләре (Р. Якобсон)

**ПЕРИФРАСТИЧЕСКИЕ ФОРМЫ ГЛАГОЛА** ПЕРИФРАСТИК ФИГЫЛЬ ФОРМАЛАРЫ Заман мәгънәсен һәм модаль мәгънә белдерә, төп фигыльгә *бул-* ярдәмче фигыле кушылып ясала торган тасвирлама формалар

**ПЕРЛОКУТИВНЫЙ ЭФФЕКТ** ПЕРЛОКУТИВ ЭФФЕКТ Сөйләм актлары теориясендә сөйләмнең адресатка, ягъни тыңлаучыга ясаган йогынтысы, тәэсире; Дж. Остин термины

**ПЕРМУТАЦИЯ** ПЕРМУТАЦИЯ Тел берәмлегенең бер планындагы үзгәреш капма-каршы пландагы үзгәрешкә китерү күренеше (мәс., җөмләдә элементларның урыннарын алмаштыру аның эчтәлеге үзгәрүгә китерә)

**ПЕРМУТИВНЫЙ ТЕКСТ** ПЕРМУТИВ ТЕКСТ Тәртибе үзгәртелгән, шуңа күрә синтаксиста берәмлекләрнең урыны, мәсәлән, сүз тәртибе нинди роль уйнаганы ачык күренә торган текст

**ПЕРСОНИФИЦИРОВАННЫЕ ТЕКСТЫ** ПЕРСОНИФИКАЦИЯЛЕ ТЕКСТЛАР Авторларының социаль характеристикалары билгеле булган, язма яки сөйләм формасындагы теләсә нинди текстлар

**ПЕРФЕКТИВАЦИЯ** ПЕРФЕКТИВАЦИЯ Совершенный вид фигыльләре ясау

**ПЕРЦЕПТИВНАЯ ФУНКЦИЯ ФОНЕМЫ** ФОНЕМАНЫҢ ПЕРЦЕПТИВ ФУНКЦИЯСЕ Фонологиядә авазларның бер үк сүзләрне һәм морфемаларны тәңгәлләштерү хезмәтен үтәү үзлеге

**ПЕРЦЕПТИВНО СИЛЬНАЯ ПОЗИЦИЯ ФОНЕМЫ** ФОНЕМАНЫҢ ПЕРЦЕПТИВ КӨЧЛЕ ПОЗИЦИЯСЕ Фонеманың үзенең төп әйтелешендә, башка фонемаларның йогынтысы булмаган хәлдә килүе

**ПЕРЦЕПТИВНО СЛАБАЯ ПОЗИЦИЯ ФОНЕМЫ** ФОНЕМАНЫҢ ПЕРЦЕПТИВ КӨЧСЕЗ ПОЗИЦИЯСЕ Фонеманың үзенең төп билгеләрен югалткан, сөйләмдә башка авазлар белән белдерелгән очрагы

**ПИКТОГРАММА** ПИКТОГРАММА Пиктографик язуда файдаланыла торган шартлы билге яки рәсем

**ПИКТОГРАФИЧЕСКОЕ ПИСЬМО** ПИКТОГРАФИК ЯЗУ График билгеләр (рәсем яки шартлы тамгалар) тел формаларын чагылдырмыйча, сөйләмнең эчтәлеген генә белдерү өчен хезмәт иткән язу принцибы; *к.* **пиктография**

**ПИКТОГРАФИЯ** ПИКТОГРАФИЯ Пиктографик язу, кул язуы; предмет, вакыйга, эш-хәрәкәтләр шартлы билгеләр – пиктограммалар ярдәмендә белдерелә торган язу төре; элек – Америка индеецларында, кайбер Төньяк халыкларда, хәзерге вакытта юл билгеләрендә, күрсәткечләрдә, элмә такталарда һ.б.ш. кулланыла

**ПИСЬМО** ЯЗУ Аралашу, мәгълүмат тапшыру чарасы буларак файдаланыла торган график тамгалар системасы (мәс., *идеографик язу* )

**ПЛАН ВЫРАЖЕНИЯ** БЕЛДЕРҮ ПЛАНЫ Телнең тышкы ягы, белдерелә торган фикернең яңгыраштагы, язмадагы яки башка тышчасы, ягъни мәгънәне, концептны һ.б.ш. белдергән тел чаралары, мәс., сүзләр

**ПЛАН СОДЕРЖАНИЯ** ЭЧТӘЛЕК ПЛАНЫ Тел берәмлекләре ярдәмендә белдерелә торган фикер

**ПЛЕРЕМА** ПЛЕРЕМА Тел берәмлегенең эчтәлек планының инварианты

**ПЛЮСКВАМПЕРФЕКТ** ПЛЮСКВАМПЕРФЕКТ *к.* **давнопрошедшее время**

**ПОБОЧНО-ВОЗВРАТНЫЕ ГЛАГОЛЫ** ӨЛЕШЧӘ КАЙТЫМЛЫ ФИГЫЛЬЛӘР Белдерелгән эш-хәрәкәтнең объекты белән субъекты өлешчә тәңгәл килгән фигыльләр

**ПОБОЧНОЕ УДАРЕНИЕ** ӨСТӘМӘ БАСЫМ Күп иҗекле, бигрәк тә ике яки берничә сүздән торган кушма сүзләрдә, гадәттә сүз башында, барлыкка килгән өстәмә басым

**ПОБУДИТЕЛЬНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ӨНДӘҮ ҖӨМЛӘ Сөйләүченең ихтыярын: боеру, үтенү, кисәтү, янау, чакыру кебек тойгыларны белдерә торган җөмләләр төре

**ПОВЕРХНОСТНЫЕ СТРУКТУРЫ** ӨСКЕ СТРУКТУРАЛАР Генератив грамматикада: телдә тирәндәге структураларны

тәшкил иткән мәгънә элементларының грамматик класслар терминнары белән, ягъни сүз төркемнәре белән белдерелеше

**ПОВЕСТВОВАТЕЛЬНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ХИКӘЯ ҖӨМЛӘ Эчтәлеге нәрсәне дә булса раслаудан яки инкяр итүдән гыйбарәт булган, ягъни интеллектуаль мәгълүмат хәбәр итә торган җөмлә

**ПОВТОРЯЕМОСТЬ** КАБАТЛАНУЧАНЛЫК Морфеманың төп билгеләренең берсе: төрле сүзләрдә һәм сүз-формаларда кулланылу, төрле башка морфемалар белән берләшеп килү үзлеге

**ПОГОВОРКИ** ӘЙТЕМНӘР Чынбарлыктагы фактны образлы рәвештә бәяли һәм текстта конкрет бер мәгънә ала торган тотрыклы гыйбарәләр

**ПОДВИЖНОЕ УДАРЕНИЕ** КҮЧМӘ БАСЫМ Бер билгеле иҗеккә бәйле булмаган, сүз формасы үзгәргәндә иҗектән иҗеккә, морфемадан морфемага күчә торган басым

**ПОДЛЕЖАЩЕЕ** ИЯ Җөмләдә баш килеш формасында, ешрак субъектны, ягъни сүз барган нәрсәне белдереп, башка җөмлә кисәкләренә буйсынмыйча, бары хәбәр белән генә бәйләнеп килгән баш кисәк

**ПОДЧИНЕНИЕ, ДЕТЕРМИНАЦИЯ** ИЯРТҮ, ДЕТЕРМИНАЦИЯ Синтаксик мөнәсәбәтләрнең бер сүз икенчесенә буйсынудан гыйбарәт төре

**ПОДЧИНИТЕЛЬНАЯ СВЯЗЬ** ИЯРТҮЛЕ БӘЙЛӘНЕШ Җөмләдә бер сүзнең икенчесенә буйсынып, ияреп килүе

**ПОДЧИНИТЕЛЬНЫЕ СОЮЗЫ** ИЯРТҮЧЕ ТЕРКӘГЕЧЛӘР Гади җөмләдә иярүче сүзне ияртүче сүзгә буйсындыра, кушма җөмләдә иярчен җөмләне баш җөмләгә ияртә торган теркәгечләр

**ПОДЪЕМ ГЛАСНЫХ** СУЗЫКЛАРНЫҢ КҮТӘРЕЛЕШЕ Сузык авазларның әйтелү вакытында телнең аңкауга карата вертикаль юнәлештә күтәрелү дәрәҗәсенә карап билгеләнеше. Шуңа бәйле рәвештә югары, урта, түбән күтәрелеш сузыклары аерыла; түбән күтәрелешле сузыкларны шулай ук киң сузыклар дип атыйлар

**ПОЗИЦИЯ** ПОЗИЦИЯ Фонеманың сөйләм барышында кулланылыш, реализацияләнү шартлары, башка авазлар тирәлегендә булуы белән, аларның тәэсире белән бәйле шартлар: төрле позицияләрдә бер үк фонема төрлечә яңгырарга мөмкин

**ПОЗИЦИИ ФОНОЛОГИЧЕСКИЕ** ФОНОЛОГИК ПОЗИЦИЯЛӘР Фонеманың сөйләмдә кулланылышы, чагылышы шартлары. Бу яктан көчле һәм көчсез позиция аерыла

**ПОЗИЦИОННО-СТАТИСТИЧЕСКИЙ МЕТОД** ПОЗИЦИОН-СТАТИСТИК МЕТОД Борынгы язма истәлекләрне дешифровкалауда, укуда кулланыла торган, Ю.В. Кнорозов уйлап тапкан ысул

**ПОЗИЦИОННО ОБУСЛОВЛЕННОЕ ЧЕРЕДОВАНИЕ** ПОЗИЦИОН ЗАКОНЧАЛЫКЛЫ ЧИРАТЛАШУ Бер телдә чыгармалары булмаган, ягъни бер телдә һәрвакыт закончалык булып торган чиратлашу (мәс., яңгырау тартык сүз ахырында саңгырау тартык белән чиратлашу)

**ПОЗИЦИОННО ПРИКРЕПЛЕННОЕ ЧЕРЕДОВАНИЕ** ПОЗИЦИОН БЕРКЕТЕЛГӘН ЧИРАТЛАШУ Позицион чиратлашуның чыгармалары булган төре (мәс., рус телендә *-ыва/-ива* алдыннан *о//а* чиратлашуы: *отколет – откалывает*)

**ПОЗИЦИОННЫЕ ИЗМЕНЕНИЯ ЗВУКОВ** АВАЗЛАРНЫҢ ПОЗИЦИОН ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ Авазларның сүздәге урыны, нинди типтагы иҗектә булуы, басымлы яки басымсыз булуы белән бәйле үзгәрешләр

**ПОЗИЦИОННОЕ ЧЕРЕДОВАНИЕ** ПОЗИЦИОН ЧИРАТЛАШУ *к.* **позиционно прикрепленное чередование, позиционно обусловленное чередование**

**ПОЗИЦИОННЫЙ ПРИНЦИП ГРАФИКИ** ГРАФИКАНЫҢ ПОЗИЦИОН ПРИНЦИБЫ Хәрефнең фонемага туры килүен аның позициясенә карап кына билгеләргә мөмкин булган язу принцибы; *к.ш.ук* **слоговой принцип письма, буквосочетательный принцип письма**

**ПОЛИВАЛЕНТНОСТЬ ЗНАЧЕНИЯ** МӘГЪНӘНЕҢ ПОЛИВАЛЕНТЛЫГЫ, КҮПВАЛЕНТЛЫЛЫГЫ Мәгънәнең төрле

төшенчә өлкәләренә караган мәгънәләр белән бәйләнешкә керү сәләте; А.Б. Михалев термины (мәс., русчадагы *трескать* сүзенең «сугу» мәгънәсе «ашау, ярылу, бәрелү» һ.б. мәгънәләр белән кисешә)

**ПОЛИГЛОТ** ПОЛИГЛОТ Күп телләр белүче кеше

**ПОЛИГЛОТИЗМ** ПОЛИГЛОТИЗМ, ПОЛИГЛОТЛЫК Күп телләр белү күренеше

**ПОЛИЛОГ** ПОЛИЛОГ Диалогик сөйләмнең берничә зат катнашкан төре

**ПОЛИПАРАДИГМАЛЬНАЯ СТАДИЯ** ПОЛИПАРАДИГМАЛЬ СТАДИЯ, КҮП ПАРАДИГМАЛЫ ЧОР Тел белеменең үсешендә структураль тел белеменнән соң килгән, хәзерге, аерым бер юнәлешнең генә түгел, киресенчә, төрле теорияләрнең үсүе белән характерланган чор

**ПОЛИСЕМИЯ** ПОЛИСЕМИЯ, КҮПМӘГЪНӘЛЕЛЕК Сүзнең яки билгенең күпмәгънәлелеге, бер сүздә, билгедә берничә мәгънә булу күренеше

**ПОЛИСИНДЕТОН** ПОЛИСИНДЕТОН Синтаксиста: күп теркәгечле бәйләнеш

**ПОЛИСИНТЕТИЧЕСКИЕ ЯЗЫКИ** ПОЛИСИНТЕТИК ТЕЛЛӘР Аерым сүз формаларын ясауда агглютинатив телләргә караган, шул ук вакытта сүз-җөмләләр төзү өчен өстәмә формалары булган телләр (мәс., Америка индеецлары телләре)

**ПОЛИСОНОМИКА** ПОЛИСОНОМИКА Топонимиканың шәһәр исемнәрен өйрәнә торган тармагы

**ПОЛНАЯ АССИМИЛЯЦИЯ** ТУЛЫ АССИМИЛЯЦИЯ Аваз икенче аваз тәэсирендә үз билгеләрен югалтып, шул авазның билгеләрен алу күренеше

**ПОЛНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ТУЛЫ ҖӨМЛӘ Ким җөмләдән аермалы буларак, мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган кисәкләрнең барысы да булган җөмлә

**ПОЛНОЗНАЧНЫЕ СЛОВА** ТУЛЫ МӘГЪНӘЛЕ СҮЗЛӘР *к.* **знаменательные слова**

**ПОЛОЖИТЕЛЬНАЯ СТЕПЕНЬ ПРИЛАГАТЕЛЬНОГО** СЫЙФАТНЫҢ ТӨП ДӘРӘҖӘСЕ Сыйфатларның билгене башка предметның билгесе белән чагыштырмыйча бирә торган чыганак формасы (мәс., *яңа, зур* һ.б.)

**ПОЛУГЛАСНЫЕ** ЯРЫМСУЗЫКЛАР Па`нини грамматикасында тартыклар һәм сузыклар арасында торган авазларның атамасы

**ПОЛУОТКРЫТЫЙ СЛОГ** ЯРЫМАЧЫК ИҖЕК Сузык авазга башланып, тартык авазга тәмамлана торган иҗек

**ПОНЯТИЕ** ТӨШЕНЧӘ Предметның яки күренешнең иң гомуми һәм шул ук вакытта иң әһәмиятле билгеләренең гәүдәләнеше, гомумиләштерүнең иң югары формасы

**ПОРОЖДАЮЩАЯ (ГЕНЕРАТИВНАЯ) ГРАММАТИКА** ТУДЫРУЧЫ (ГЕНЕРАТИВ) ГРАММАТИКА Генератив лингвистиканың телдә сөйләшүченең билгеле берәмлекләр системасы белән билгеле кагыйдәләр нигезендә эш итү сәләтен тикшерә торган өлеше

**ПОРОЖДАЮЩАЯ (ТРАНСФОРМАЦИОННАЯ, ГЕНЕРАТИВНАЯ) ЛИНГВИСТИКА** ТУДЫРУЧЫ (ТРАНСФОРМАЦИОН, ГЕНЕРАТИВ) ЛИНГВИСТИКА Лингвистиканың Н. Хомский нигез салган, телне билгеле типтагы формаль модельләр буларак тикшерә торган формаль юнәлешләренең берсе

**ПОРОЖДАЮЩАЯ СЕМАНТИКА** ТУДЫРУЧЫ СЕМАНТИКА Генератив грамматиканың мәгънәләр белән эш итә торган өлеше

П**ОРОЖДАЮЩАЯ (ГЕНЕРАТИВНАЯ) СТРУКТУРА** ТУДЫРУЧЫ (ГЕНЕРАТИВ) СТРУКТУРА Генератив тел белемендә төрле телләр өчен якын дип исәпләнгән һәм төрле җөмләләрне оештыру эшен башкарган кагыйдәләр системасы

**ПОРЯДКОВОЕ ЧИСЛИТЕЛЬНОЕ** ТӘРТИП САНЫ Әйберләрнең саналу яки урнашу тәртибен белдерә, микъдар санына -нчы/-нче кушымчасы кушылып ясала торган сан

**ПОРЯДОК СЛОВ** СҮЗ ТӘРТИБЕ Сүзтезмә һәм җөмлә төзүнең синтаксик чараларыннан берсе: җөмләдә сүзләрнең син-

таксик һәм стилистик закончалыкларга буйсынып, билгеле бер тәртиптә килүе (мәс., татар телендә аергыч – аерылмышыннан, ия хәбәрдән алда килә)

**ПОСЛЕЛОГ** БӘЙЛЕК Җөмләдә предлогка охшаш морфологик-синтаксик функция башкарган, әмма ияргән сүзеннән соң килеп, сүзләр арасында бергәлек, чагыштыру, сәбәп һ.б.ш. мөнәсәбәтләр оештыруда катнаша торган ярдәмче сүз төркеме (*урман аркылы, синең шикелле, күрү өчен*). Кайбер телләрдә кушылып та язылырга мөмкин (лат. cum *nobiskum vobiskum*)

**ПОСЛЕЛОЖНОЕ СЛОВО** БӘЙЛЕК СҮЗ Бәйлек функцияләрен үти, урын-ара мөнәсәбәтләрен белдерә торган исем

**ПОСЛОВИЦЫ** МӘКАЛЬЛӘР Халыкның тормыш-көнкүреш тәҗрибәсен һәм бәяләмәсен чагылдырган, мөстәкыйль хөкем формасында килгән тотрыклы гыйбарәләр (мәс., *азыклы ат арымас*)

**ПОСТОЯННОЕ УДАРЕНИЕ** ДАИМИ БАСЫМ Сүзнең грамматик формалары ясалганда урыннан урынга күчми торган басым, бәйле басым (мәс., рус. *сле'д – следа'* дан аермалы буларак *в'ера – ве'ры*)

**ПОСТСТРУКТУРАЛИЗМ** ПОСТСТРУКТУРАЛИЗМ Тел белеменең структурализмнан соңгы үсеш этабында барлыкка килгән барлык агымнарның гомуми атамасы

**ПОСТФИКС** ПОСТФИКС Сүзнең иң ахырында, кушымчадан соң ялгана торган аффикс (мәс., рус -*ся,-сь*)

**ПОСТФИКСАЦИЯ** ПОСТФИКСАЦИЯ Постфикс ялгау юлы белән сүз ясау (мәс., *ниндидер, умываться, какой-то* һ.б.)

**ПОТАМОНИМЫ** ПОТАМОНИМНАР Топонимнарның бер төре: елга атамалары

**ПОТЕНЦИАЛЬНЫЕ СЕМЫ** ПОТЕНЦИАЛЬ СЕМАЛАР, ФАРАЗЫЙ СЕМАЛАР Конкрет текстта чагылырга мөмкин булган мәгънәләр

**ПОТЕНЦИАЛЬНЫЕ СЛОВА** ПОТЕНЦИАЛЬ СҮЗЛӘР Әзер морфемалардан, продуктив сүзьясалыш модельләре буенча

ясау мөмкин булган, шуңа күрә һәркемгә аңлашыла торган, әмма сүзлекләргә кертелмәгән сүзләр

**ПОТЕНЦИАЛИЗМЫ** ПОТЕНЦИАЛИЗМНАР *к.* **потенциальные слова**

**ПОТЕНЦИИ** ПОТЕНЦИЯЛӘР Сүзнең төрле контекстларда барлыкка килә торган, ачыклана торган мәгънә төсмерләре

**ПОЭТИЧЕСКАЯ ЛЕКСИКА** ПОЭТИК ЛЕКСИКА, ШИГЪРИ ЛЕКСИКА Әдәби телнең сүз байлыгының башлыча матур әдәбиятта, аерым алганда шигырьләрдә файдаланыла торган, югары, лирик, тантаналы стильгә караган катламы

**ПОЯСНИТЕЛЬНЫЕ СОЮЗЫ** АНЫКЛАУЧЫ ТЕРКӘГЕЧЛӘР Ияртүче теркәгечләрнең аныклагыч һәм аныкланмышны, кушма җөмләдә аныклагыч иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли торган төре (мәс., *а именно, то есть, ягъни, бигрәк тә* һ.б.)

**ПРАГМАЛИНГВИСТИКА** ПРАГМАЛИНГВИСТИКА Тел билгеләренең сөйләмдә кулланылышын өйрәнә торган тел белеме юнәлеше

**ПРАГМАТИЧЕСКИЕ ПРЕСУБПОЗИЦИИ** ПРАГМАТИК ПРЕСУБПОЗИЦИЯЛӘР, ГАМӘЛИ ПРЕСУБПОЗИЦИЯЛӘР Сөйләм актлары теориясендә сөйләүче, тыңлаучы һәм аларның үзара мөнәсәбәте белән бәйле гомуми белем, конкрет кешеләрнең мәгълүматлылык дәрәҗәсе, карашлары, фикерләре, мәнфәгатьләре мәсьәләсе

**ПРАКТИЧЕСКАЯ ТРАНСКРИПЦИЯ** ГАМӘЛИ ТРАНСКРИПЦИЯ Билгеле телнең язуына нигезләнгән, шул телне практик өйрәнүдә кулланыла торган транскрипция

**ПРАСЛАВЯНСКИЙ** БАБА СЛАВЯН ...Ы Беренчел гомумславян тел берлегенә караган (мәс., *баба славян теле, баба славян чоры*)

**ПРАЯЗЫК** БАБА ТЕЛ Чагыштырма-тарихи ысул белән торгызылып, кардәш телләр арасында иң борынгысы дип табылган, шул гаиләгә караган телләрнең чыганагы дип исәпләнә торган тел

**ПРЕВОСХОДНАЯ СТЕПЕНЬ, СУПЕРЛАТИВ** АРТЫКЛЫК ДӘРӘҖӘСЕ, СУПЕРЛАТИВ Бер объекттагы билгенең башка объекттагы билгегә караганда артыграк булуын белдерә торган сыйфат категориясе

**ПРЕДЕЛЬНЫЕ ГЛАГОЛЫ** ЧИКЛЕ ФИГЫЛЬЛӘР Тәгәлләнүгә, бетүгә, чиккә омтылган эш-хәрәкәтне белдергән фигыльләр

**ПРЕДЕЛЬНЫЕ ЯЗЫКОВЫЕ ЕДИНИЦЫ** ЧИКЛӘНГӘН ТЕЛ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ Состав элементларга бүлү мөмкин булган тел берәмлекләре (мәс., телдә: фонемалар, сүзләр һ.б.; сөйләмдә: аллофоннар, морфлар һ.б.)

**ПРЕДИКАТ** ПРЕДИКАТ, ХӘБӘРЛЕК Җөмләнең субъект турында нәрсә дә булса хәбәр итә торган кисәге

**ПРЕДИКАТИВНАЯ СВЯЗЬ** ПРЕДИКАТИВ БӘЙЛӘНЕШ Ия белән хәбәр арасындагы бәйләнеш

**ПРЕДИКАТИВНОСТЬ** ПРЕДИКАТИВЛЫК Җөмләдә чагылдырылган ситуациянең сөйләүче тарафыннан билгеләнә һәм белдерелә торган чынбарлыкка мөнәсәбәте

**ПРЕДИКАТИВЫ** ПРЕДИКАТИВЛАР *к.* **категория состояния**

**ПРЕДЛОГ** ПРЕДЛОГ Рус телендә һәм башка кайбер телләрдә исемне (алмашлыкны) җөмләдәге башка сүзләргә ияртү өчен кулланыла торган ярдәмлек сүз төркеме

**ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ҖӨМЛӘ 1) Сөйләүче һәм тыңлаучы тарафыннан грамматик бербөтен буларак кабул ителә, фикерләү берәмлеген сүз белән белдерү өчен хезмәт итә торган сөйләм берәмлеге, ягъни фикерне билгеләү һәм тапшыру өчен төп чара; 2) Конкрет әйтелмәләрнең чиксез санын төзү мөмкинлеге бирә торган синтаксик модель, синтаксисның төп берәмлеге

**ПРЕДЛОЖНЫЙ ПАДЕЖ** ПРЕДЛОГЛЫ КИЛЕШ Рус телендә объект, хәл, аергыч мөнәсәбәтләрен белдерә һәм предлог белән генә килә ала торган килеш (мәс., *о доме, в слезах, в восхищении*)

**ПРЕДМЕТНО-ЛИЧНЫЕ МЕСТОИМЕНИЯ** ПРЕДМЕТ-ЗАТ АЛМАШЛЫКЛАРЫ Исемнәрне алмаштырып килә һәм грамматик яктан исемнәргә якын торган алмашлыклар

**ПРЕДМЕТНЫЕ СУЩЕСТВИТЕЛЬНЫЕ** ПРЕДМЕТ ИСЕМНӘР Конкрет исемнәрнең предметларны белдерә торган төре

**ПРЕРЫВИСТЫЕ ОСНОВЫ** ӨЗЕК НИГЕЗЛӘР Морфемалары арасында өзеклек булган, ягъни нигез морфемалары арасына кушымча килеп кергән очраклар (мәс., *весели[ть]ся, бармый[сың]дыр*)

**ПРЕСКРИПТИВ** ПРЕСКРИПТИВ *к.* **юссив**

**ПРЕСТИЖ ЯЗЫКА** ТЕЛ ПРЕСТИЖЫ Җәмгыятьтә кабул ителгән кыйммәтләр иерархиясендә телнең тоткан урыны

**ПРЕФИКС** АЛКУШЫМЧА Тамырның алдына ялгана торган аффикс

**ПРЕФИКСАЛЬНО-ПОСТФИКСАЛЬНЫЙ СПОСОБ** ПРЕФИКСАЛЬ-ПОСТФИКСАЛЬ ЫСУЛ Берьюлы префикс һәм постфикс ялгап яңа сүзләр ясау ысулы (мәс., *разгуляться*)

**ПРЕФИКСАЛЬНО-СЛОЖНЫЙ СПОСОБ** ПРЕФИКСАЛЬ-КУШМА ЫСУЛ Берьюлы сүзләр кушылып һәм аларга префикс ялгап сүз ясау ысулы (мәс., *иссиня-черный*)

**ПРЕФИКСАЛЬНО-СУФФИКСАЛЬНО-СЛОЖНЫЙ СПОСОБ** ПРЕФИКСАЛЬ-СУФФИКСАЛЬ-КУШМА ЫСУЛ Берьюлы сүзләр кушылып һәм аларга префикс белән суффикс ялгап сүз ясау ысулы (мәс., *повсеместно*)

**ПРЕФИКСАЛЬНО-СУФФИКСАЛЬНЫЙ СПОСОБ** ПРЕФИКСАЛЬ-СУФФИКСАЛЬ ЫСУЛ Яңа сүзләр ясауның берьюлы префикс һәм суффикс ялгаудан гыйбарәт ысулы (мәс., *Приморье, Забайкалье*)

**ПРЕФИКСАЛЬНЫЙ СПОСОБ** ПРЕФИКСАЛЬ ЫСУЛ Сүзьясагыч чарасы – дериваторы префикс булган сүзьясалыш ысулы

**ПРЕФИКСАЦИЯ** ПРЕФИКСАЦИЯЛӘҮ, АЛКУШЫМЧА ЯЛГАУ Сүз ясаганда яки төрләндергәндә алкушымча кушу

**ПРИБЛИЗИТЕЛЬНОЕ ЧИСЛИТЕЛЬНОЕ** ЧАМА САНЫ Микъдар санына -лап/-ләп кушымчасы кушылып ясала һәм әйберләрнең санын чама белән белдерә торган сан

**ПРИВАТИВНАЯ АППОЗИЦИЯ ФОНЕМ** ФОНЕМАЛАРНЫҢ ПРИВАТИВ АППОЗИЦИЯСЕ Фонемаларны бер билгесе буенча каршы кую (мәс., *а* һәм *ә* рәт аппозициясендә)

**ПРИДАТОЧНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ Баш җөмләгә буйсынып, андагы берәр кисәкне ачыклап килә торган җөмлә

**ПРИЗНАКИ МОРФЕМЫ** МОРФЕМА БИЛГЕЛӘРЕ Теләсә кайсы морфемага хас булган үзенчәлекләр: кабатланучанлык, мәгънәлелек, абстрактлык, таркатылмаучанлык

**ПРИЗНАКОВЫЕ МЕСТОИМЕНИЯ (МЕСТОИМЕННЫЕ ПРИЛАГАТЕЛЬНЫЕ)** БИЛГЕ АЛМАШЛЫКЛАРЫ (СЫЙФАТ АЛМАШЛЫКЛАР) Сыйфатларны алмаштырып килә һәм билгене күрсәтә торган, грамматик яктан сыйфатка якын булган алмашлыклар

**ПРИКЛАДНАЯ ЛИНГВИСТИКА** ГАМӘЛИ ТЕЛ БЕЛЕМЕ Тел белеменең телне гамәли максатларда файдалану мөмкинлекләрен өйрәнә торган тармагы

**ПРИЛАГАТЕЛЬНОЕ** СЫЙФАТ Предметның билгесен, сыйфатын белдерә һәм гадәттә җөмләдә аергыч булып килә торган сүз төркеме

**ПРИЛОЖЕНИЕ** ӨСТӘЛМӘ Аерылмышта аталган предметның икенче атамасы булып торган иярчен җөмлә кисәге, сүзне ачыклап, аның белән бер үк килештә килгән исем белән белдерелгән аергыч

**ПРИНАДЛЕЖНОСТЬ** ТАРТЫМ Кайбер телләрдә, мәсәлән, төрки телләрдә, исем сүз төркеменең махсус кушымчалар ярдәмендә предметның кайсы затка (*сөйләүче, тыңлаучы, алардан читтәге зат*) каравын белдерә торган грамматик категориясе

**ПРИНЦИПЫ ГРАФИКИ** ГРАФИКА ПРИНЦИПЛАРЫ Бер телнең авазларын язуда белдерү принциплары: фонематик, позицион һ.б.

**ПРИНЦИПЫ ОРФОГРАФИИ** ОРФОГРАФИЯ ПРИНЦИПЛАРЫ Сөйләмне язуда белдерүдә бердәйлекне тәэмин итү кагыйдәләренең нигезенә салынган принциплар: фонематик, фонетик, традицион һ.б.

**ПРИСОЕДИНИТЕЛЬНЫЕ СОЮЗЫ** ҖЫЮЧЫ ТЕРКӘГЕЧЛӘР Тезүче теркәгечләрнең җыю, санап китү, теркәү функцияләрен башкара торган төркемчәсе (мәс., рус. *причём, да и, также*, тат. *һәм, янә, да/дә* һ.б.)

**ПРИТЯЖАТЕЛЬНОЕ МЕСТОИМЕНИЕ** ТАРТЫМ АЛМАШЛЫГЫ, НИСБӘТЛӘҮ АЛМАШЛЫГЫ Предметның билгеле объект белән иялек мөнәсәбәтендә булуын күрсәтә торган алмашлык (мәс., рус. *мой, свой,* тат. *сезнеке, аларныкы* һ.б.)

**ПРИТЯЖАТЕЛЬНОЕ ПРИЛАГАТЕЛЬНОЕ** ТАРТЫМ СЫЙФАТЫ, НИСБӘТЛӘҮ СЫЙФАТЫ Рус һәм башка кайбер телләрдә *кемнең?, кемнеке?* соравына җавап бирә торган сыйфатлар

**ПРИТЯЖАТЕЛЬНЫЙ АФФИКС** ИЯЛЕК АФФИКСЫ Иялек мөнәсәбәтен белдерә торган аффикс (мәс., рус. *-ин, -ий*; тат. *-ем,-ең*)

**ПРИЧАСТИЕ** СЫЙФАТ ФИГЫЛЬ Фигыль һәм сыйфат сүз төркемнәренең грамматик үзенчәлекләрен берләштергән сүз төркеме

**ПРИЯДЕРНАЯ ЗОНА** ҮЗӘК ТИРӘСЕ ЗОНАСЫ Мөһим концептны белдергән төп сүздән башка лексик берәмлекләр, аның синонимнары һ.б.

**ПРОГРЕССИВНАЯ АССИМИЛЯЦИЯ** ПРОГРЕССИВ АССИМИЛЯЦИЯ, ТУРЫ АССИМИЛЯЦИЯ Бер аваз үзеннән соң килгән авазга тәэсир итеп, аны үзенә охшашландыру күренеше

**ПРОГРЕССИВНАЯ ДЕМОТИВАЦИЯ СЛОВА (ЗНАКА)** СҮЗНЕҢ (БИЛГЕНЕҢ) ПРОГРЕССИВ ДЕМОТИВАЦИЯСЕ, СҮЗНЕҢ (БИЛГЕНЕҢ) ТУРЫ МОТИВСЫЗЛАШУЫ Ф.Ф. Буслаев фикеренчә, һәр сүз башта чынбарлыктан алынган

тәэсирне белдергән, вакыт үтү белән гомуми төшенчәнең шартлы билгесенә әверелгән, ягъни мотивын югалткан

**ПРОДУКТИВНОСТЬ АФФИКСА** АФФИКСНЫҢ ПРОДУКТИВЛЫГЫ Аффиксның яңа сүзләр ясауга сәләте

**ПРОДУКТИВНЫЙ** ПРОДУКТИВ Бер телнең сүзьясалышында нәтиҗәле рәвештә, еш, актив кулланыла торган (мәс., *сүзьясалыш ысулы, нигез, аффикс* һ.б.)

**ПРОДУКТИВНЫЙ АФФИКС** ПРОДУКТИВ КУШЫМЧА Сүз ясауда яки сүз төрләндерүдә актив кулланыла торган аффикс

**ПРОИЗВОДНАЯ ОСНОВА** ЯСАЛМА НИГЕЗ Башка нигездән ясалган, составында кушымча булган нигез

**ПРОИЗВОДНОЕ СЛОВО (ДЕРИВАТ)** ЯСАЛМА СҮЗ (ДЕРИВАТ) Икенче бер сүздән ясалган, ягъни икенче сүз белән мотивлаштырып була торган сүз

**ПРОИЗВОДЯЩЕЕ СЛОВО** ЯСАУЧЫ СҮЗ Икенче сүз ясау өчен нигез булган сүз

**ПРОИЗВОЛЬНОСТЬ ЯЗЫКОВОГО ЗНАКА** ТЕЛ БИЛГЕСЕНЕҢ ПРОИЗВОЛЬЛЕГЕ, ИРЕКЛЕЛЕГЕ Тел билгесе белән ул атаган предмет арасында чынбарлыкта бернинди мөнәсәбәт булмау, ягъни алар арасындагы бәйлелек очраклы, мотивсыз булу

**ПРОИЗНОШЕНИЕ** 1. ӘЙТЕЛЕШ, ӘЙТҮ 1) Тел берәмлегенең *(авазның, сүзнең)* җанлы сөйләмдә яңгырашы, аның артикуляция үзенчәлекләре (мәс., *йомык әйтелеш, иҗекләп әйтү*); 2) Бер телнең төрле вариантларына хас орфоэпик нормалар җыелмасы (мәс., *әдәби әйтелеш, гади сөйләм әйтелеше*). 2. СӨЙЛӘШ Конкрет сөйләүченең бер телдә сөйләшкәндәге индивидуаль фонетик үзенчәлекләре

**ПРОКЛИЗА** ПРОКЛИЗА Сүзнең мөстәкыйль басым алмыйча, басымлы сүз алдыннан проклитика булып килү күренеше

**ПРОКЛИТИКА** ПРОКЛИТИКА Басымлы сүз алдыннан килеп, шуңа ияргән, үзенең мөстәкыйль басымы булмаган, гадәттә бер иҗектән торган сүз

**ПРОКСЕМИКА** ПРОКСЕМИКА Тел белеменең сөйләмне вакытта һәм пространствода оештыру мәсьәләләрен өйрәнә торган өлкәсе (Э. Холл термины)

**ПРОПИСНАЯ БУКВА** БАШ ХӘРЕФ Бер телдә кабул ителгән билгеле орфография һәм пунктуация кагыйдәләре нигезендә кулланыла торган, калган хәрефләрдән зурлыгы, кайвакытта язылышы белән аерыла торган хәреф

**ПРОСОДИЯ** ПРОСОДИЯ Сөйләм сегментларының (иҗек, сүз, текст һ.б.) барлык катламнарында кулланыла һәм мәгънә аеру ролен үти торган фонетик чаралар системасы, ритмик-интонацион берәмлекләре: сингармонизм, сүз басымы, интонация һ.б.

**ПРОСТОЕ ВРЕМЯ** ГАДИ ЗАМАН Заман категориясен белдерүнең гади, синтетик формасы, ягъни кушымча ярдәмендә белдерелгән заман (мәс., *барды,* чаг. *барган иде*)

**ПРОСТОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ГАДИ ҖӨМЛӘ Бер генә хәбәрлеге булган җөмлә

**ПРОСТОРЕЧНАЯ ЛЕКСИКА** ГАДИ СӨЙЛӘМ ЛЕКСИКАСЫ Әдәби тел нормаларына җавап бирми торган, кимсетүле, тупас бәя бирү, экспрессив-стилистик коннотация максатларыннан файдаланыла торган гади сүзләр, тәгъбирләр, формалар

**ПРОТЕЗА** ПРОТЕЗА Берничә тартык янәшә, гадәттә алынма сүзләрнең башында, килгәндә алар алдына сузык аваз өстәлү күренеше

**ПРОТЕТИЧЕСКИЙ** ПРОТЕЗА ...Ы Протеза рәвешендәге, протеза ролендәге

**ПРОТИВИТЕЛЬНЫЕ СОЮЗЫ** КАРШЫ КУЮЧЫ ТЕРКӘГЕЧЛӘР Гади җөмлә кисәкләрен һәм тезмә кушма җөмләнең компонентларын бер-беренә каршы куя торган теркәгечләр (мәс., *әмма, фәкать, исә һ.б.*)

**ПРОФЕССИОНАЛИЗМ** ПРОФЕССИОНАЛИЗМ Профессиональ лексикага караган сүз

**ПРОФЕССИОНАЛЬНАЯ ЛЕКСИКА** ПРОФЕССИОНАЛЬ ЛЕКСИКА Бер профессиягә, бер белем тармагына караган төшенчәләрне белдерә торган сүзләр

**ПРОШЕДШЕЕ НЕОЧЕВИДНОЕ ВРЕМЯ** БИЛГЕСЕЗ ҮТКӘН ЗАМАН Сөйләүче үзе күрмәгән эш-хәлне белдергән фигыль формасы

**ПРЯМАЯ РЕЧЬ** ТУРЫ СӨЙЛӘМ Автор сөйләмендә үзгәртелмичә кулланылган чит кеше сөйләме, чит сөйләмне сүзен сүзгә тапшыру өчен төзелгән үзенчәлекле синтаксик берәмлек. Текстта бирелеше махсус кагыйдәләргә буйсына; диалог, монолог, цитата дигән төрләргә бүленә

**ПРЯМО-НОМИНАТИВНОЕ ЗНАЧЕНИЕ СЛОВА** СҮЗНЕҢ ТУРЫ НОМИНАТИВ МӘГЪНӘСЕ Сүзнең телнең хәзерге хәлендә турыдан-туры предметны, сыйфатны, хәрәкәтне һ.б.ш. белдергән мәгънәсе

**ПРЯМОЕ ДОПОЛНЕНИЕ** ТУРЫ ТӘМАМЛЫК Күчемле фигыль белән белдерелгән эш-хәрәкәтнең объектын белдерә торган тәмамлык

**ПРЯМОЕ ЗНАЧЕНИЕ СЛОВА** СҮЗНЕҢ ТУРЫ МӘГЪНӘСЕ Күчерелмә метафорик мәгънәләреннән аермалы буларак сүзнең беренчел, экспрессив-эмоциональ төсмерләр өстәлмәгән үз мәгънәсе

**ПРЯМОЙ ПАДЕЖ** ТУРЫ КИЛЕШ Исемнең төп формасы, баш килеш

**ПСИХОЛИНГВИСТИКА** ПСИХОЛИНГВИСТИКА Сөйләмнең барлыкка килүен, формалашуын һәм кабул ителүен тел системасы белән бәйле рәвештә өйрәнә торган тел белеме тармагы

**ПУБЛИЦИСТИЧЕСКАЯ ЛЕКСИКА** ПУБЛИЦИСТИК ЛЕКСИКА Әдәби телнең китап стиленә караган, массакүләм мәгълүмат чараларында актуаль иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрне яктырту өчен файдаланыла торган сүзләр (мәс., *милли үзаң, хәйрия, сайлау округы* һ.б.)

**ПУНКТУАЦИЯ** ПУНКТУАЦИЯ Тыныш билгеләре системасы һәм аларны текстта куллану кагыйдәләре

**ПУРИЗМ** ПУРИЗМ Телне үзгәрешләрдән, бигрәк тә чит телләр йогынтысыннан саклау, алынмалар кертмәү яклы караш

# Р

**РАВНОЗНАЧНЫЕ СЛОВА** МӘГЪНӘДӘШ СҮЗЛӘР *к.* **синонимы**

**РАДИКСОИДЫ** РАДИКСОИДЛАР Телдә аффикслар белән генә кулланыла торган тамырлар (мәс., *низвергнуть, отвергнуть*)

**РАЗГОВОРНАЯ ЛЕКСИКА** СӨЙЛӘМ ЛЕКСИКАСЫ Көндәлек сөйләм телендә кулланыла торган сүзләр

**РАЗГОВОРНАЯ РЕЧЬ** СӨЙЛӘМ ТЕЛЕ Әдәби сөйләм теленең көндәлек сөйләмдә кулланыла, аралашу һәм тәэсир итү функцияләрен башкара торган төре

**РАЗГОВОРНЫЙ СТИЛЬ** СӨЙЛӘМ СТИЛЕ *к.* **разговорная речь**

**РАЗДЕЛИТЕЛЬНЫЕ ЧИСЛИТЕЛЬНЫЕ** БҮЛЕМ САННАРЫ Төрдәш әйберләрнең тигез өлешләргә бүленүен белдерә торган саннар; микъдар санына -ар/-әр кушымчасы ялганып ясала (мәс., *берәр, унар, бишәр, алтышар*)

**РАЗДЕЛИТЕЛЬНЫЙ ЗНАК** АЕРУ БИЛГЕСЕ Сүзләрдә теге яки бу авазларның тоташып, кушылып китүен булдырмый торган авазны белдергән билге

**РАЗДЕЛИТЕЛЬНЫЕ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** БҮЛҮЧЕ ҖӨМЛӘЛӘР Тезмә кушма җөмләдә бүлүче теркәгечләр белән бәйләнгән һәм араларында бер-берсен кире кагу, альтернатив мөнәсәбәтләр урнашкан аерым җөмләләр

**РАЗДЕЛИТЕЛЬНЫЕ СОЮЗЫ** БҮЛҮЧЕ ТЕРКӘГЕЧЛӘР Җөмлә кисәкләре яки җөмләләр арасында альтернатив, чиратлашып килү мөнәсәбәтен (*яки, яисә*), бер-берсен инкяр итү мөнәсәбәтен (*я*), алмашынучанлык (*ни*), аңлашылмаучанлык (*әллә*) һ.б. мәгънәләрне белдереп килә торган теркәгечләр

**РАЗНОКОРНЕВЫЕ СИНОНИМЫ** ТАМЫРДАШ БУЛМАГАН СИНОНИМНАР Төрле тамырлардан ясалган сүзләр (мәс., *прозвище – кличка*)

**РАЗНОЯЗЫЧНЫЙ** ТӨРЛЕ ТЕЛЛЕ 1) Төрле теллəрдəн файдаланган; төрле теллəрдə сөйлəшə торган; 2) Төрле теллəрнең сүзлəреннəн гыйбарəт

**РАСКАТИСТЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ТИРБƏНҮЛЕ, КАЛТЫРАУЛЫ САҢГЫРАУЛАР Артикуляциялəре вакытында телнең очы күтəрелеп, һава агымы тəэсирендə калтырап торган тартыклар (мəс., [*р*])

**РАСПРОСТРАНЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ҖƏЕНКЕ ҖӨМЛƏ Баш кисəклəре дə, иярчен кисəклəре дə булган җөмлə

**РАСШИРЕНИЕ ЗНАЧЕНИЯ** МƏГЪНƏ КИҢƏЮ Сүзнең тарихи үсеш барышында киңрəк мəгънə белдерүе; *киресе*: **сужение значения**

**РЕГРЕССИВНАЯ АССИМИЛЯЦИЯ** РЕГРЕССИВ АССИМИЛЯЦИЯ Аваз үзеннəн соң əйтелгəн авазга охшашлану күренеше

**РЕГРЕССИВНАЯ АККОМОДАЦИЯ** РЕГРЕССИВ АККОМОДАЦИЯ Сүздə артта торган авазның алдагы авазга тəэсир итү күренеше

**РЕДУКЦИЯ** РЕДУКЦИЯ Басымсыз позициядə сузык авазның əйтелеше үзгəрү, үзенчəлекле билгелəре югалу күренеше

**РЕДУПЛИКАЦИЯ** РЕДУПЛИКАЦИЯ, КАБАТЛАУЛАР Төп сүзне кабатлап əйтеп, грамматик мəгънə һəм сүз ясаудан гыйбарəт фономорфологик күренеш (мəс., *кызыл-кызыл, бара-бара*)

**РЕДУЦИРОВАННЫЕ ГЛАСНЫЕ** РЕДУКЦИЯЛƏНГƏН СУЗЫКЛАР 1) Баба славян теллəреннəн килгəн урта күтəрелешле бик кыска сузыклар; 2) Басымсыз иҗеклəрдə əйтелеше тонықланган, кыскарган, билгесез сыйфатлы сузыклар

**РЕЗОНАНС** РЕЗОНАНС Бер үк ешлыкка ия башка тибрəнешлəр нəтиҗəсендə туган аваз тибрəнешлəре

**РЕЗОНАТОР** РЕЗОНАТОР Сөйлəм процессында авазларны көчəйтүче һəм өстəмə тембр бирүче куышлык: авыз, тамак һəм борын резонаторлары

**РЕКОНСТРУКЦИЯ (фактов языка)** (тел фактларын) ЯҢАДАН ТОРГЫЗУ Чагыштырма-тарихи тел белемендə: кардəш

телләрне үзара чагыштыру, телнең тарихын һәм диалектларын өйрәнү нигезендә хәзерге көндә булмаган кайбер борынгы фактларны торгызу

**РЕКУРСИЯ** РЕКУРСИЯ Авазны әйтеп бетергәннән соң сөйләм органнарының кире үз хәлләренә кайтулары; артикуляциянең соңгы этабы

**РЕЛЯТИВНЫЕ ОТНОШЕНИЯ** РЕЛЯТИВ МӨНӘСӘБӘТЛӘР Сүзтезмәнең эш яки билгене белдерә торган төп кисәге белән эшнең, билгенең сыйфатын, санын яки башка билгеләрне белдерә торган ияреп килгән кисәге арасындагы мөнәсәбәт

**РЕЛЯЦИОННЫЕ ПОСТФИКСЫ** РЕЛЯЦИОН ПОСТФИКСЛАР Кушымчалар кебек үк сүзләр, сүз формалары арасында синтаксик мөнәсәбәтләрне белдерә торган постфикслар

**РЕМА** РЕМА Җөмләнең яңалык өлеше, тема турында төп фикерне туплаган актуаль кисәге

**РЕМИНИСЦЕНЦИЯ** РЕМИНИСЦЕНЦИЯ Сөйләмгә әзер, инде булган чит тексттан бик таныш фрагментны кертүдән гыйбарәт риторик алым

**РЕТИАЛЬНАЯ КОММУНИКАЦИЯ** РЕТИАЛЬ КОММУНИКАЦИЯ Адресаты анык билгеле булмаган аралашу

**РЕТРОСПЕКЦИЯ** РЕТРОСПЕКЦИЯ Текст фрагментының алдагы өлешләрендә булган информациягә ишарәләү үзенчәлеге

**РЕФЕРЕНТ** РЕФЕРЕНТ Сүзтезмәләр, җөмләләр белән белдерелгән чынбарлык күренеше

**РЕФЕРЕНЦИЯ, РЕПРЕЗЕНТАЦИЯ** РЕФЕРЕНЦИЯ, РЕПРЕЗЕНТАЦИЯ Сөйләмгә кертелгән исем яки исем төркемнәренең яисә аларның эквивалентларының чынбарлык объектларына (референтларга, денотатларга) бәйлелеге

**РЕЦЕПТИВНЫЙ СЛОВАРЬ** РЕЦЕПТИВ СҮЗЛЕК, ПАССИВ СҮЗЛЕК 1) Психолингвистикада, сөйләм культурасы теориясендә, лингвометодикада: укыганда, чит сөйләмне тыңлаганда аңлашыла, ләкин кешенең көндәлек аралашуында, ирекле, алдан әзерләнмәгән үз сөйләмендә кулланылмый торган сүзләр җыелмасы; пассив сүзлек запасы; 2) Телнең чагыштырма-

ча сирәк кулланыла торган берәмлекләреннән торган байлыгы; пассив сүзлек составы

**РЕЧЕВАЯ АГРЕССИЯ** СӨЙЛӘМДӘГЕ АГРЕССИЯ Кешене, аерым бер төркемне хурлау, аларга зарар китерүне максат итеп куйган сөйләм; сөйләм этикасын бозу күренеше

**РЕЧЕВАЯ ГАРМОНИЯ** СӨЙЛӘМ ГАРМОНИЯСЕ Катнашучыларның һәркайсы өчен дә уңай эмоциональ яки эстетик нәтиҗәле сөйләм, аралашу

**РЕЧЕВАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ** СӨЙЛӘҮ, СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕ Сөйләм һәм аңлауның кайбер актлары җыелмасына кергән тел материалы

**РЕЧЕВАЯ ДИСГАРМОНИЯ** СӨЙЛӘМ ДИСГАРМОНИЯСЕ Аралашу процессында катнашучыларның берсе яки барысы өчен дә көтелмәгән, начар эмоциональ яки эстетик нәтиҗәле сөйләм

**РЕЧЕВАЯ КУЛЬТУРА** СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ *к.* **культура речи**

**РЕЧЕВАЯ ЭТИКА** СӨЙЛӘМ ЭТИКАСЫ *к.* **риторическая этика**

**РЕЧЕВЕДЕНИЕ** РЕЧЕВЕДЕНИЕ, СӨЙЛӘМ БЕЛЕМЕ Телнең кулланылышын, функцияләрен өйрәнү белән шөгыльләнә торган фәннәрнең (прагматика, стилистика, сөйләм культурасы, риторика, текст лингвистикасы) гомуми исеме

**РЕЧЕВОЕ ОБЩЕНИЕ** СӨЙЛӘМ ЯРДӘМЕНДӘ АРАЛАШУ Коммуникатив процесста катнашучыларның акустикага нигезләнгән аралашуы; тел ярдәмендә аралашу

**РЕЧЕВОЙ АКТ** СӨЙЛӘМ АКТЫ Билгеле бер җәмгыятьтә кабул ителгән кагыйдәләр, принциплар кысаларындагы сөйләм эшчәнлеге

**РЕЧЕВОЙ АППАРАТ** СӨЙЛӘМ АППАРАТЫ Сөйләм процессында катнаша торган органнар; *к.* **органы речи**

**РЕЧЕВОЙ РИТМ** СӨЙЛӘМ РИТМЫ Текстны барлыкка китерә, эмоциональ-экспрессив функция башкара торган охшаш сөйләм берәмлекләрен даими рәвештә кабатлау

**РЕЧЕВОЙ ТАКТ** СӨЙЛӘМ ТАКТЫ Интонация, такт басымы белән характерлана, паузалар белән аерымланмый яки паузалары фраза арасындагы паузалардан кыскарак булган берәмлек, фонетик синтагма

**РЕЧЕВОЙ ШТАМП** СӨЙЛӘМ ШТАМПЫ Стилистик бизәге булган, әмма еш кулланылуы сәбәпле универсаль берәмлек булып киткән һәм шуңа да адресатлар тарафыннан түбән бәяләнә торган, семантик-структур яктан тотрыклы әйтелмәләр (мәс., *всего хорошего, счастья в личной жизни*)

**РЕЧЕВОЙ ЭТИКЕТ** СӨЙЛӘМ ЭТИКЕТЫ Җәмгыять тарафыннан билгеләнгән, мәдәни яктан специфик булган сөйләм кагыйдәләре

**РЕЧЕВЫЕ НЕДОЧЕТЫ** СӨЙЛӘМДӘГЕ ТӨГӘЛСЕЗЛЕКЛӘР Императив булмаган тел нормаларын бозу

**РЕЧЕВЫЕ ОШИБКИ** СӨЙЛӘМ ХАТАЛАРЫ Мөһим, тиешле әдәби тел нормаларын бозу

**РЕЧЬ** СӨЙЛӘМ 1) Сөйләүченең тел чараларыннан файдаланып, башкалар белән аралашу яки үз-үзенә сөйләү эшчәнлеге; 2) Әйтелмәнең синтаксик төзелеше ягыннан төре (автор сөйләме, кыек сөйләм, туры сөйләм һ.б.)

**РЕЭТИМОЛОГИЗАЦИЯ** РЕЭТИМОЛОГИЗАЦИЯ Сүзнең яңа эчке форма алуы, мотивлашмаган булудан мотивлашканга әйләнүе

**РИТМ** РИТМ Басымлы һәм басымсыз, ачык һәм ябык иҗекләрнең чиратлашып килүе; интонациянең бер элементы

**РИТМИКА** РИТМИКА Фонетиканың сөйләмнең ритмик төзелешен өйрәнә торган бүлеге

**РИТМОМЕЛОДИКА** РИТМОМЕЛОДИКА Сөйләмнең ритмы һәм мелодикасы кушылудан гыйбарәт үзенчәлеге

**РИТОРИКА** РИТОРИКА Сәнгатьле сөйләм, ораторлык сәнгате теориясе

**РИТОРИЧЕСКАЯ ЭТИКА** РИТОРИК ЭТИКА Аралашуда үз-үзеңне тотуның этик нормалар һәм кагыйдәләр җыелмасы

**РИТОРИЧЕСКИЙ ВОПРОС** РИТОРИК СОРАУ Сорау формасындагы раслау

**РИТОРИЧЕСКОЕ ВОСКЛИЦАНИЕ** РИТОРИК ӨНДӘҮ Эмоцияләр лексик һәм синтаксик чаралар белән түгел, ә интонация ярдәмендә белдерелгән эмоциональ бизәкле җөмлә

**РИТОРИЧЕСКОЕ ОБРАЩЕНИЕ** РИТОРИК ЭНДӘШ Җөмләнең яки тагын да катлаулырак синтаксик бөтеннең грамматик яктан аңа бәйле булмаган һәм интонацион яктан аерымланган, сөйләм адресланган затны белдерә торган кисәге

**РОД** РОД Исемнәрдә алар белән ярашкан сыйфатларның һ.б.ның билгеле формаларын таләп итүдән гыйбарәт лексик-грамматик категория

**РОДИТЕЛЬНЫЙ ПАДЕЖ** ГЕНИТИВ, ИЯЛЕК КИЛЕШЕ Иялек, мөнәсәбәтлелек мәгънәләрен белдерә торган кыек килеш

**РОДНАЯ РЕЧЬ** 1) ТУГАН СӨЙЛӘМ Туган телдә яңгыраган сөйләм; 2) ТУГАН ТЕЛ *к.* **родной язык**

**РОДНОЙ ЯЗЫК** ТУГАН ТЕЛ Билгеле бер халыкның милли теле

**РОДОВАЯ ПАРА** РОДЛАП ПАРЛАУ Мужской һәм женский родларга караган, биологик җенесе белән генә аерылып торган бер үк лексик мәгънәдәге исемнәрнең капма-каршы куелган пары

**РОДСТВЕННЫЕ ЯЗЫКИ** КАРДӘШ ТЕЛЛӘР Уртак лексикасы, фонетик, грамматик төзелешләрендә даими тәңгәллекләре, уртак билгеләре булган һәм бер уртак баба телдән барлыкка килгән телләр

**РОМАНИСТ** РОМАНИСТ Роман филологиясе белгече

**РОМАНСКИЕ ЯЗЫКИ** РОМАН ТЕЛЛӘРЕ Һинд-европа телләре семьялыгының француз, прованс, испан, португал, румын, каталон, сардин, латин һ.б. телләр кергән тармагы

**РОТАЦИЗМ** РОТАЦИЗМ [*з*] авазы урынына [*р*] авазын кулланудан гыйбарәт фонетик үзенчәлек

**РОТОВАЯ ПОЛОСТЬ** АВЫЗ КУЫШЛЫГЫ Артикуляцион органнар урнашкан һәм бик күп авазлар ясала торган куышлык

**РОТОВЫЕ ЗВУКИ** АВЫЗ АВАЗЛАРЫ Йомшак аңкау күтәрелеп һәм шул сәбәпле артикуляциядә борын куышлыгы катнашмый гына ясалган авазлар

**РУНЫ** РУННАР, РУНИК ЯЗУ Борынгы язуларның VI–IX гасырларда кулланылган төре

**РУСИЗМ** РУСИЗМ Рус теленнән алынган сүз яки гыйбарә

**РУСИСТИКА** РУСИСТИКА Рус телен һәм мәдәниятен өйрәнә торган фәннәр җыелмасы

**РУССКИЙ ЯЗЫК** РУС ТЕЛЕ Көнчыгыш славян телләренең XIV–XV гасырларда борынгы рус теленнән аерылып чыккан теле; рус милләте теле

**РУЧНОЙ ЯЗЫК** КУЛ ТЕЛЕ *к.* **жестов языки**

**РЯД** РӘТ Сузык авазларны әйткәндә телнең горизонталь торышы: алгы рәт, урта рәт, арткы рәт сузыклары

**РЯДОВАЯ ГАРМОНИЯ** РӘТ ГАРМОНИЯСЕ Сузыкларның калынлыкта яки нечкәлектә, ягъни рәт буенча ярашуы; *к.* **сингармонизм**

# С

**САМОДИЙСКИЕ ЯЗЫКИ** САМОЕД ТЕЛЛӘРЕ Урал телләре гаиләсеннән фин-угор төркеменең самоед тармагына караган ненец, селькуп, нганасан һ.б. телләр

**САМОСТОЯТЕЛЬНЫЕ ГЛАГОЛЫ** МӨСТӘКЫЙЛЬ ФИГЫЛЬЛӘР Аерым лексик мәгънә белдерә торган фигыльләр

**САМОСТОЯТЕЛЬНЫЕ СЛОВА** МӨСТӘКЫЙЛЬ СҮЗЛӘР *к.* **знаменательные слова**

**САМОСТОЯТЕЛЬНЫЕ ЧАСТИ РЕЧИ** МӨСТӘКЫЙЛЬ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ Мөстәкыйль лексик мәгънә белдерә торган сүз төркемнәре: исем, сыйфат, фигыль, рәвеш, алмашлык, сан

**САНДХИ** САНДХИ Ике морфема чигендә яки ике сүз арасында (беренче сүз сузык авазга тәмамланып, икенчесе су-

зыкка башланганда) сузыклар очрашканда була торган аваз күренешләре (мәс., *килә иде – киләйде, эшлә әле – эшләле*)

**САНСКРИТ** САНСКРИТ Борынгы һинд әдәби теле

**САНСКРИТОЛОГ** САНСКРИТОЛОГ Санскрит теле һәм әдәбияты белгече

**СВИСТЯЩИЕ ЗВУКИ** СЫЗГЫРУЛЫ АВАЗЛАР *к.* **свистящие согласные**

**СВИСТЯЩИЕ СОГЛАСНЫЕ** СЫЗГЫРУЛЫ ТАРТЫКЛАР Берьюлы ике урыннан һава өрелеп чыгу нәтиҗәсендә ясалган телалды өрелмәле (фрикатив) тартыклары (*з, с* тартыклары)

**СВОБОДНЫЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** ИРЕКЛЕ СҮЗТЕЗМӘЛӘР Сөйләм барышында ясалган һәм кисәкләре арасында реаль мәгънә мөнәсәбәте югалмаган сүзтезмәләр (мәс., *әнигә багышлау, чибәрлеге өчен ярату* һ.б.)

**СВОБОДНОЕ ЛЕКСИЧЕСКОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ИРЕКЛЕ ЛЕКСИК МӘГЪНӘ Сүзнең контекстка бәйле булмаган һәм теләсә нинди сөйләм ситуациясендә саклана торган мөстәкыйль мәгънәсе

**СВОБОДНОЕ УДАРЕНИЕ** ИРЕКЛЕ БАСЫМ Төрле морфологик элементларда сүздә күчеп йөри торган, позицион беркетелмәгән басым; рус, украин, белорус, болгар телләренә хас күренеш (мәс., *голова, голову, голов*)

**СВЯЗАННОЕ УДАРЕНИЕ** БӘЙЛЕ БАСЫМ *к.* **постоянное ударение**

**СВЯЗНАЯ РЕЧЬ** ТОТАШ СӨЙЛӘМ Мәгънәсе белән мөстәкыйль тәмамланган кисәкләргә таркала ала торган билгеле бер озынлыктагы сөйләм кисәге

**СВЯЗЬ** БӘЙЛӘНЕШ Сөйләм элементлары арасындагы синтаксик бәйләнешнең төп төрләре һәм ысуллары; гадәттә ике төрле (тезүле һәм ияртүле) була

**СЕГМЕНТ** СЕГМЕНТ Эзлекле сөйләм актының бер кисәге

**СЕГМЕНТАЦИЯ** СЕГМЕНТАЦИЯ Сөйләмне аны төзегән элементларга һәм кисәкләргә бүлү

**СЕГМЕНТНЫЕ ЕДИНИЦЫ** СЕГМЕНТ БЕРӘМЛЕКЛӘР Бер-бер артлы килә торган авазлар һәм шул авазлар тезмәсеннән барлыкка килгән иҗекләр

**СЕГМЕНТНЫЕ ЭЛЕМЕНТЫ** СЕГМЕНТ ЭЛЕМЕНТЛАР Сөйләм кисәге

**СЕМА** СЕМА Сүзнең лексик мәгънәсенең – семеманың иң кечкенә компоненты

**СЕМАНТИКА** СЕМАНТИКА Морфемаларның, сүзләрнең, сүзтезмәләрнең һәм грамматик формаларның мәгънәви ягы, эчтәлеге

**СЕМАНТИКО-ФУНКЦИОНАЛЬНОЕ ПОЛЕ ГРАММАТИЧЕСКОЙ КАТЕГОРИИ** ГРАММАТИК КАТЕГОРИЯНЕҢ ФУНКЦИОНАЛЬ-СЕМАНТИК КЫРЫ Грамматик мәгънә белдерә торган, әмма морфологик яктан сүзформа буларак тулысынча калыплашмаган тел чаралары (һәртөрле аналитик форма һәм аналитик төзелмәләр, тел ярусларының төрле өлкәләренә караган тел берәмлекләре)

**СЕМАНТИЧЕСКАЯ СТРУКТУРА ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘНЕҢ СЕМАНТИК СТРУКТУРАСЫ Җөмләдәге кисәкләрнең лексик һәм грамматик мәгънәләреннән оешкан гомуми абстракт мәгънәсе

**СЕМАНТИЧЕСКАЯ ТИПОЛОГИЯ** СЕМАНТИК ТИПОЛОГИЯ Тел күренешләренең семантик яктан чыгып типларга бүленеше

**СЕМАНТИЧЕСКИЕ АРХАИЗМЫ** СЕМАНТИК АРХАИЗМНАР Бер генә мәгънәсе искергән архаизмнар (мәс., татар телендә *көн – кояш,* рус телендә *дом* – хакимлек итүче династия һ.б.)

**СЕМАНТИЧЕСКИЕ КАЛЬКИ** СЕМАНТИК КАЛЬКАЛАР Чит тел сүзенең мәгънәсен күчерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән калькалар (мәс., рус сүзләренең аерым мәгънәләрен үзләштерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән калькалар: *борын, бугаз, челтәр, сайлау, агым, җыелыш* һ.б.)

**СЕМАНТИЧЕСКИЕ ИСТОРИЗМЫ** СЕМАНТИК ТАРИХИ СҮЗЛӘР Иҗтимагый тормышта кулланыштан төшеп калган, юкка чыккан предметларны, күренешләрне, профессияләрне ата-

ган сүзләр (мәс., *Министрлар Советы*, *Чит ил эшләре коллегиясе, райком секретаре, бишьеллык* һ.б.)

**СЕМАНТИЧЕСКИЕ НЕОЛОГИЗМЫ** СЕМАНТИК НЕОЛОГИЗМНАР Иске сүзләргә яңа мәгънә өстәлеп ясалган неологизмнар (мәс., *штрих* сүзенең яңа мәгънәсе «тексттагы хаталарны төзәтү өчен кулланыла торган паста»)

**СЕМАНТИЧЕСКИЙ АНАЛИЗ** СЕМАНТИК АНАЛИЗ, МӘГЪНӘ АНАЛИЗЫ Сүзләрне һәм алар арасындагы бәйләнешләрне мәгънә ягыннан тикшерү

**СЕМАНТИЧЕСКИЙ АСПЕКТ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘНЕҢ СЕМАНТИК АСПЕКТЫ Җөмләнең билгеле бер ситуацияне белдерүе һәм аңлатуы

**СЕМАНТИЧЕСКИЙ ПРИНЦИП ЭТИМОЛОГИИ** ЭТИМОЛОГИЯНЕҢ СЕМАНТИК ПРИНЦИБЫ Сүз мәгънәләренең мөнәсәбәтләрен, семантик һәм семасиологик закончалыкларны өйрәнә торган принцип

**СЕМАНТИЧЕСКИЙ СИНТАКСИС** СЕМАНТИК СИНТАКСИС Синтаксисның лексик һәм грамматик мәгънәләрне бергә җыеп өйрәнә; җөмлә кисәкләрен аларны белдерүче сүз төркемнәре һәм аларның формалары белән һәм алар белдергән мәгънәләр (семантика) белән эш итә торган бүлеге

**СЕМАНТИЧЕСКОЕ КАЛЬКИРОВАНИЕ** СЕМАНТИК КАЛЬКАЛАШТЫРУ Чит телдәге сүзнең күчерелмә мәгънәсен кабул итү

**СЕМАСИОЛОГ** СЕМАСИОЛОГ Семасиология белгече

**СЕМАСИОЛОГИЯ** СЕМАСИОЛОГИЯ Тел гыйлемендә сүзләрнең, тәгъбирләрнең мәгънәләрен һәм шул мәгънәләрдәге үзгәрешләрне өйрәнә торган бүлек

**СЕМЕМА** СЕМЕМА Эчтәлек планының иң кечкенә берәмлеге, бер мәгънә

**СЕМИОЛОГИЯ** СЕМИОЛОГИЯ Билге системаларының гомуми үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән; *к.* **семиотика**

**СЕМИОТИКА** СЕМИОТИКА Шартлы яки шартсыз хәбәр-информация чыганагы-иясе булган, мәгънә белдергән билгеләр,

тамгалар, сигналлар, эзләр (шул исәптән аларның системалары) турындагы методологик фән; билге (мәс., сүз, сүзтезмә, җөмлә) һәм билге системаларын өйрәнә торган гомуми теория. Семиотикада теләсә нинди билге өч аспектта өйрәнелә: синтактик, семантик һәм прагматик аспектларда

**СЕМИОТИЧЕСКИЙ СИНТАКСИС** СЕМИОТИК СИНТАКСИС Синтаксисның сөйләмне һәм аның берәмлекләренең синтактикасын, семантикасын һәм парадигматикасын өйрәнә торган тармагы

**СЕМИТИЗМ** СЕМИТИЗМ Семит телләреннән алынган сүз яки тәгъбир

**СЕМИТИЧЕСКИЕ ЯЗЫКИ** СЕМИТ ТЕЛЛӘРЕ Семит-хамит телләре гаиләсенә кергән гарәп, борынгы еврей, ойсор һ.б. телләр

**СЕМИТОЛОГ** СЕМИТОЛОГ Семит телләре белгече, семитология белгече

**СЕМИТОЛОГИЯ** СЕМИТОЛОГИЯ Семит телләрен һәм мәдәниятләрен өйрәнә торган фән

**СЕМИТО-ХАМИТСКАЯ (АФРАЗИЙСКАЯ) СЕМЬЯ ЯЗЫКОВ** СЕМИТ-ХАМИТ (АФРАЗИЯ) ТЕЛЛӘРЕ СЕМЬЯЛЫГЫ Семит һәм хамит телләренең семьялыгы

**СЕМИТСКИЕ ЯЗЫКИ** СЕМИТ ТЕЛЛӘРЕ *к.* **семитические языки**

**СЕМЬЯ ЯЗЫКОВ** ТЕЛЛӘР СЕМЬЯЛЫГЫ *к.* **языковая семья**

**СЕНТЕНЦИЯ** СЕНТЕНЦИЯ Афоризмның бер төре

**СИБИЛЯНТЫ** СИБИЛЯНТЛАР *к.* **свистящие согласные**

**СИГНИФИКАТ (СИГНИФИКАТИВНОЕ ЗНАЧЕНИЕ)** СИГНИФИКАТ (СИГНИФИКАТИВ МӘГЪНӘ) Төшенчәнең эчтәлеген тәшкил итә, предметның төп билгесен күрсәтә торган мәгънә; денотатның кеше аңындагы төшенчәсе

**СИЛА (ИНТЕНСИВНОСТЬ) ЗВУКА** АВАЗНЫҢ КӨЧЕ (ИНТЕНСИВЛЫГЫ) Авазның тибрәнеш колачы (амплитудасы) басымын билгеләгән сан бәяләмәсе

**СИЛЛАБИЧЕСКИЙ** СИЛЛАБИК Иҗек санына корылган

**СИЛЛАБИЧЕСКОЕ ПИСЬМО** СИЛЛАБИК ЯЗУ Һәр хәрефе аерым иҗекне күрсәтә торган язу

**СИЛОВОЕ УДАРЕНИЕ** КӨЧЛЕ БАСЫМ *к.* **динамическое ударение**

**СИЛЬНАЯ ПОЗИЦИЯ ФОНЕМ** ФОНЕМАЛАРНЫҢ КӨЧЛЕ ПОЗИЦИЯСЕ Сөйләм агымында фонемаларның үзләренең дифференциаль билгеләрен аеруча ачык чагылдырган, дифференциаль билгеләрен югалтмаган позициясе

**СИЛЬНАЯ ФОНЕМА** КӨЧЛЕ ФОНЕМА Теләсә нинди позициядә телнең башка берәмлекләре белән тәңгәл килми торган фонема (мәс., *[у], [ә], [л], [ф]* һ.б.)

**СИМВОЛ** СИМВОЛ Тел һәм сөйләм әсәрләрендә кайбер күренеш идеяләрен гәүдәләндерә торган тамга (сүз, сәнгать образы): *төн – үлем, көн – тормыш* символы

**СИНГАРМОНИЗМ (ГАРМОНИЯ ГЛАСНЫХ)** СИНГАРМОНИЗМ (СУЗЫКЛАР ГАРМОНИЯСЕ) Сүз эчендәге сузыкларның рәт һәм иренләшү ягыннан ярашып, охшашланып килүе; рәт (барлык сузыкларның я алгы, я арткы рәттә генә булуы) һәм ирен (беренче иҗектә иренләшкән сузык булса калган иҗекләрдәге сузыкларның да иренләшүе) гармониясе дигән төрләре бар; нигездә төрки телләргә хас күренеш

**СИНГАРМОНИЧЕСКИЕ ПАРАЛЛЕЛИ** СИНГАРМОНИК ПАРАЛЛЕЛЬЛӘР Этимологик яктан бер тамырдан булган калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр: *аз – әз, акрын – әкрен, ачы – әче, багланыш – бәйләнеш, чыкылдау – чекелдәү* һ.б.

**СИНГАРМОНИЯ** СИНГАРМОНИЯ Бер авазның икенче авазга охшаш яңгырашы

**СИНДЕТИЧЕСКИЙ СПОСОБ** СИНДЕТИК ЫСУЛ Синтаксик бәйләнештә интонация һәм сүз тәртибеннән тыш, формаль белдерелгән чараның да кулланылуы

**СИНЕКДОХА** СИНЕКДОХА Күчерелмә мәгънәнең бер төре; сүз мәгънәсе бөтеннән өлешкә, өлештән бөтенгә күчүдән гыйбарәт булган стилистик алым

**СИНКОПА** СИНКОПА Сүз уртасындагы авазның төшеп калуы (мәс., *халык – халкы* һ.б.)

**СИНКОПИЧЕСКОЕ ЯВЛЕНИЕ** СИНКОПИК КҮРЕНЕШ Сүздә аваз төшеп калу күренеше

**СИНОЛОГ** СИНОЛОГ Кытай теле белгече, синология белгече

**СИНОЛОГИЯ** СИНОЛОГИЯ Кытай теле, әдәбияты, мәдәнияте турындагы фән

**СИНОНИМИКА** СИНОНИМИКА 1) Теге яки бу телдәге синонимнар җыелмасы; 2) Тел белеменең синонимнарны өйрәнә торган бүлеге; 3) *к.* **синонимия**

**СИНОНИМИЧЕСКИЕ ЗНАЧЕНИЯ СЛОВ** СҮЗЛӘРНЕҢ СИНОНИМИК МӘГЪНӘЛӘРЕ Бер-берсенә бик якын, хәтта кайчак берсен икенчесе белән алыштырып була торган мәгънәләр: *күренекле, атаклы, танылган, атказанган, мәшһүр; исбат итү, исбатлау, исбат кылу, дәлилләү, нигезләү, аргументлау* һ.б.

**СИНОНИМИЧЕСКИЕ КОНСТРУКЦИИ** СИНОНИМИК КОНСТРУКЦИЯЛӘР *к.* **синтаксические синонимы**

**СИНОНИМИЧЕСКИЕ СЛОВА** СИНОНИМИК (МӘГЪНӘДӘШ) СҮЗЛӘР *к.* **синонимы**

**СИНОНИМИЧЕСКИЙ РЯД** СИНОНИМИК РӘТ Бер үк яки якын мәгънә белдергән сүзләр (мәс., *азат, бәйсез, хөр, irекле, мөстәкыйль*)

**СИНОНИМИЯ** СИНОНИМИЯ, СИНОНИМЛЫК Морфемаларның, сүзләрнең, синтаксик конструкцияләрнең мәгънә тәңгәллеге яки якынлыгы

**СИНОНИМЫ** СИНОНИМНАР Мәгънәләре белән тәңгәл яки якын торган сүзләр

**СИНОПСИС** СИНОПСИС**,** ҖЫЕНТЫК Берәр мәсьәләгә караган мәкаләләр, материаллар җыентыгы

**СИНТАГМА** СИНТАГМА (СӨЙЛӘМ ТАКТЫ) Сөйләмнең бер-берсеннән паузалар һәм башка ритм-мелодика чаралары белән аерыла торган мәгънәле кисәге

**СИНТАГМАТИКА** СИНТАГМАТИКА Сөйләм элементларының бер сызыкта (бер вакытта) урнашуын күздә тотып өйрәнә торган фән тармагы; сүзтезмә турындагы фән тармагы

**СИНТАГМАТИЧЕСКИЕ ЗНАЧЕНИЯ ФОРМЫ** ФОРМАНЫҢ СИНТАГМАТИК МӘГЪНӘЛӘРЕ Грамматик форманың, контекстта кулланылганда, контекст тәэсирендә барлыкка килгән мәгънәләре

**СИНТАГМАТИЧЕСКИЕ КАТЕГОРИИ** СИНТАГМАТИК КАТЕГОРИЯЛӘР Җөмлә эчендәге сүзләрнең үзара мөнәсәбәтен белдергән грамматик категорияләр (мәс., исемдә – килеш, тартым, хәбәрлек, фигыльдә – зат-сан категорияләре)

**СИНТАГМАТИЧЕСКИ ОФОРМЛЯЕМЫЕ МОРФОЛОГИЧЕСКИЕ КАТЕГОРИИ** СИНТАГМАТИК ФОРМАЛАШКАН МОРФОЛОГИК КАТЕГОРИЯЛӘР Сөйләмдә сүзләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен белдерә һәм шул юл белән сүзләрне үзара бәйли торган категорияләр (килеш, тартым категорияләре, хәл фигыль, сыйфат фигыль, шарт фигыль формалары)

**СИНТАГМАТИЧЕСКОЕ (ФРАЗОВОЕ) УДАРЕНИЕ** СИНТАГМА (ФРАЗА) БАСЫМЫ Синтагмадагы берәр сүзне башкаларыннан аерып әйтүдән гыйбарәт басым

**СИНТАГМАТИЧЕСКОЕ ЧЛЕНЕНИЕ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘНЕ СИНТАГМАТИК КИСӘКЛӘРГӘ БҮЛҮ (ТАРКАТУ) Җөмләне синтагмаларга (интонацион буыннарга) бүлү (таркату)

**СИНТАКСИС** СИНТАКСИС 1) Телнең сөйләм төзелеше; 2) Тел гыйлеменең телнең лексик-грамматик берәмлекләре арасындагы бәйләнешләрне һәм шул бәйләнешләр нигезендә оеша торган төзелмәләрне өйрәнә торган тармагы; синтаксисның төп берәмлекләре: сүзтезмә, синтагма, синтаксик бөтен, җөмлә һәм текст

**СИНТАКСИС СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** СҮЗТЕЗМӘ СИНТАКСИСЫ Сүзләрнең сөйләмдә бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен өйрәнә торган синтаксис

**СИНТАКСИС ТЕКСТА** ТЕКСТ СИНТАКСИСЫ Синтаксисның текст (тоташ сөйләм) төзелешен өйрәнә торган тармагы

**СИНТАКСИЧЕСКАЯ ОМОНИМИЯ** СИНТАКСИК ОМОНИМИЯ Төрле синтаксик конструкцияләрнең аваз ягыннан тәңгәл килүләре

**СИНТАКСИЧЕСКАЯ СВЯЗЬ** СИНТАКСИК БӘЙЛӘНЕШ Ике яки аннан артык лексик-грамматик берәмлекнең билгеле бер модель һәм максат нигезендә берләшүе. Тезүле (паратаксис) һәм ияртүле (гипотаксис), беренчел һәм икенчел, тыгыз һәм йомшак һ.б. бәйләнешләр була. Синтаксик бәйләнеш ике төрле ысул белән башкарыла: асиндетик һәм синдетик ысул

**СИНТАКСИЧЕСКАЯ ФОНЕТИКА** СИНТАКСИК ФОНЕТИКА Фонетиканың сөйләмдәге басым, интонация, сөйләмнең фонетик кисәкләрен өйрәнә торган тармагы

**СИНТАКСИЧЕСКАЯ ФУНКЦИЯ** СИНТАКСИК ФУНКЦИЯ Сүзләрнең җөмләдәге вазифасы, кайсы җөмлә кисәге булып килә алу мөмкинлеге

**СИНТАКСИЧЕСКИЕ ВРЕМЕНА** СИНТАКСИК ЗАМАННАР Синтаксик хәзерге, үткән, киләчәк заманнар

**СИНТАКСИЧЕСКИЕ ЕДИНИЦЫ** СИНТАКСИК БЕРӘМЛЕКЛӘР Сүзләр, җөмлә кисәкләре, сүзтезмәләр

**СИНТАКСИЧЕСКИЕ КОНСТРУКЦИИ** СИНТАКСИК КОНСТРУКЦИЯЛӘР (ТӨЗЕЛМӘЛӘР) Грамматик кагыйдәләр буенча төзелгән, сүзләрдән, җөмләләрдән торган бербөтен (сүзтезмә, җөмлә, кушма җөмлә һ.б.)

**СИНТАКСИЧЕСКИЕ СИНОНИМЫ** СИНТАКСИК СИНОНИМНАР Мәгънәләре бердәй, формалары төрле синтаксик төзелмәләр; грамматик синонимнарның бер төре (мәс., *мин баргач,... – мин барганнан соң,... – мин бару белән,... – мин бардым, шуннан соң...* )

**СИНТАКСИЧЕСКИЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** СИНТАКСИК СҮЗТЕЗМӘЛӘР *к.* **свободные словосочетания**

**СИНТАКСИЧЕСКИЕ (СЛОВОСВЯЗЫВАЮЩИЕ) СУФФИКСЫ** СИНТАКСИК (СҮЗ БӘЙЛӘҮЧЕ) КУШЫМЧАЛАР Җөмләдә турыдан-туры сүзләрне бәйләү өчен хезмәт итә тор-

ган кушымчалар (килеш, тартым, сан, зат һәм хәбәрлек кушымчалары)

**СИНТАКСИЧЕСКИЙ АНАЛИЗ** СИНТАКСИК АНАЛИЗ Текстны җөмлә төрләре, җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерү; кушма җөмләләрдә җөмләләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, кушма җөмләнең төрен билгеләү, җөмләләр бәйләнешен күрсәткән схемалар сызу

**СИНТАКСИЧЕСКИЙ ИНДИКАТИВ** СИНТАКСИК ИНДИКАТИВ Үтәлүе реаль булган хикәяләү наклонениесе, реаль наклонение

**СИНТАКСИЧЕСКИЙ СПОСОБ ОБРАЗОВАНИЯ СЛОВ** СИНТАКСИК ЫСУЛ БЕЛӘН СҮЗ ЯСАУ, СИНТАКСИК СҮЗЬЯСАЛЫШ Аерым сүзләрнең бәйләнешләре нигезендә яңа сүзләр ясалышы; кушма, тезмә, парлы сүзләр ясау ысулы

**СИНТАКСИЧЕСКИЙ УРОВЕНЬ (ЯРУС) ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ СИНТАКСИК КАТЛАМЫ (КАТЛАВЫ) Тел системасының сүзтезмә, җөмлә, текст һ.б. лардан торган өлеше

**СИНТАКСИЧЕСКИЙ ФРАЗЕОЛОГИЗМ** СИНТАКСИК ФРАЗЕОЛОГИЗМ Сүзләр бәйләнешенең хәзерге нормаларына сыймый торган сүзтезмә яки җөмлә

**СИНТАКТИКА** СИНТАКТИКА Синтаксик билгеләр системасы формасын (мәгънәләргә һәм формаларга нисбәтсез генә билгеләрнең яраша алуын) өйрәнә; формаль синтаксис

**СИНТЕТИЧЕСКАЯ КОСВЕННАЯ РЕЧЬ** СИНТЕТИК КЫЕК СӨЙЛӘМ Туры сөйләм белән чагыштырганда бик нык үзгәргән кыек сөйләм

**СИНТЕТИЧЕСКАЯ ФОРМА** СИНТЕТИК ФОРМА Сүзләргә кушымчалар ялганып ясалган формалар (мәс., *авылга, әнинеке, бардым* һ.б.)

**СИНТЕТИЧЕСКИЕ ВИДЫ МОРФОЛОГИЧЕСКИХ ФОРМ** МОРФОЛОГИК ФОРМАЛАРНЫҢ СИНТЕТИК ТӨРЛӘРЕ Сүзформаларның сүзгә кушымчалар ялганып барлыкка килгән синтетик төрләре (мәс., аналитик форма булган *бара идем* формасыннан аермалы буларак *бардым* формасы һ.б.)

**СИНТЕТИЧЕСКИЕ ГЛАГОЛЫ** СИНТЕТИК ФИГЫЛЬЛӘР Грамматик мәгънә морфемалар белән белдерелгән гади фигыльләр; *киресе:* **аналитические глаголы**

**СИНТЕТИЧЕСКИЕ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** СИНТЕТИК ҖӨМЛӘЛӘР Синтетик чаралар ярдәмендә ияреп килгән иярчен җөмләләр; синтетик иярчен җөмләләр

**СИНТЕТИЧЕСКИЕ СРЕДСТВА** СИНТЕТИК ЧАРАЛАР Грамматик мәгънәләрне сүз эчендә белдергән грамматик чаралар (аффиксация, эчке флексия, кабатлаулар, басым, супплетивизм, инкорпорация)

**СИНТЕТИЧЕСКИЕ СЛОВА** СИНТЕТИК СҮЗЛӘР Бер тамырдан торган сүзләр

**СИНТЕТИЧЕСКИЕ ЯЗЫКИ** СИНТЕТИК ТЕЛЛӘР Грамматик мәгънәләр күп очракта синтетик чаралар (аффиксация, эчке флексия, басым, супплетивизм һ.б.) ярдәмендә сүзнең үз эчендә белдерелә торган телләр (мәс., латин, рус, алман, литва һ.б. телләр) (А. Шлейхер термины)

**СИНТЕТИЧЕСКИЙ СТРОЙ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ СИНТЕТИК ТӨЗЕЛЕШЕ *к.* **синтетические языки**

**СИНТЕТИЧЕСКОЕ ПРИДАТОЧНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** СИНТЕТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ Хәбәр составындагы хәбәр формасын тәшкил иткән чаралар (синтетик чаралар) ярдәмендә баш җөмләгә ияреп килә торган һәм формасы белән гади җөмләгә охшаган иярчен җөмлә

**СИНТЕТИЧЕСКОЕ СЛОЖНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** СИНТЕТИК КУШМА ҖӨМЛӘ Аерым җөмләләре хәбәр формасы (синтетик чара) аша бәйләнгән кушма җөмлә

**СИНТЕТИЧЕСКОЕ СЛОЖНОПОДЧИНЁННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** СИНТЕТИК ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ Иярчен җөмләсе баш җөмләгә синтетик чаралар ярдәмендә бәйләнгән иярченле кушма җөмлә

**СИНХРОНИЧЕСКАЯ АССИМИЛЯЦИЯ** СИНХРОНИК АССИМИЛЯЦИЯ Сөйләмдә авазлар охшашлануы (мәс., *унбер – умбер, тозсыз – тоссос* һ.б.)

**СИНХРОНИЧЕСКИЙ СИНТАКСИС** СИНХРОНИК СИНТАКСИС Синтаксиста телнең хәзерге хәлен өйрәнү принцибы

**СИНХРОНИЧЕСКОЕ ИЗУЧЕНИЕ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕ СИНХРОНИК ӨЙРӘНҮ Телнең үсеш процессын түгел, аерым бер үсеш чорын өйрәнү

**СИНХРОНИЯ** СИНХРОНИЯ Телнең тарихи үсеш процессында билгеле бер этаптагы хәле, торышы һәм аның шушы хәлен, торышын тарихи үзгәрешләргә игътибар итмичә тикшерү; *киресе*: **диахрония**

**СИСТЕМА** СИСТЕМА 1) Үзара тотрыклы мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән элементлар җыелмасы (мәс., сүзьясалыш системасы); 2) Билгеле бер грамматик категория барлыкка китерә торган формалар җыелмасы (мәс., килешләр системасы)

**СИСТЕМА ЯЗЫКА** ТЕЛ СИСТЕМАСЫ *к.* **языковая система**

**СИСТЕМОТОЛОГИЯ** СИСТЕМОТОЛОГИЯ Лингвистик типларның системаларын ачыклау һәм шул типларга туры килгән телләрне классларга бүлү

**СИТУАЦИЯ** СИТУАЦИЯ, ЭШ-ХӘЛ Җөмләнең экстралингвистик референты (денотаты), ягъни конкрет әйтелмәдә хәбәр ителгән реаль чынбарлыкның бер арасы (кисәге)

**СКАЗУЕМОЕ** ХӘБӘР Җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик буйсына торган икенче баш кисәге; нинди сүз төркеме белән белдерелүеннән чыгып, фигыль хәбәр һәм исем хәбәр дигән төрләре була; төзелешләре буенча гади, кушма һәм тезмә хәбәрләргә бүленәләр

**СКАЗУЕМОСТНОЕ СЛОВО** ХӘБӘРЛЕКЛЕ СҮЗ Хәбәр мәгънәсендәге, хәбәр булырлык сүз

**СКАЗУЕМОСТЬ** ХӘБӘРЛЕК Сүзнең җөмләдә хәбәр булып килү сыйфаты, үзлеге, сәләте

**СКЛОНЕНИЕ** ТӨРЛӘНЕШ Төрләнеш формалары булган сүзләрнең сүз үзгәрү парадигмалары (мәс., исемнәрнең тартым, килеш, зат, сан белән төрләнеше һ.б.)

**СКОБКА** ҖӘЯ Җәенке кереш сүзләрне, өстәмә сүз һәм ремаркаларны җөмләнең башка кисәкләреннән аеру өчен кулланыла торган дуга яки ярым квадрат формасындагы парлы тыныш билгесе; ( )

**СКРЕЩИВАНИЕ ЯЗЫКОВ** ТЕЛЛӘР КАТНАШУ Бер территориядә ике яки берничә телнең озак вакытлар тыгыз бәйләнеше нәтиҗәсендә үзара аралашканда кешеләрнең я бер телдә, я икенче телдә сөйләшүләре, бер телдән икенче телгә күчүләре; креол тел, ягъни катнаш, гибрид тел барлыкка килү (мәс., Урта диңгез буендагы сабир теле)

**СЛАБАЯ ПОЗИЦИЯ ФОНЕМ** ФОНЕМАЛАРНЫҢ КӨЧСЕЗ ПОЗИЦИЯСЕ Фонемаларның дифференциаль билгеләрен югалткан позициясе (мәс., басымсыз иҗектә сузыкларның килүе)

**СЛАБАЯ ФОНЕМА** КӨЧСЕЗ ФОНЕМА Үзләренең билгеләре буенча башка фонемалар белән тәңгәл килгән фонема (мәс., татар телендә [ы], [е] фонемалары [о], [ө] фонемалары белән тәңгәл киләләр)

**СЛАВИСТ** СЛАВИСТ Славяннарның тарихын, әдәбиятын, телен өйрәнүче белгеч

**СЛАВИСТИКА** СЛАВИСТИКА *к.* **славяноведение**

**СЛАВЯНИЗМ** СЛАВЯНИЗМ 1) Славян группасыннан булмаган берәр телгә славян телләреннән кергән сүз яки тәгъбир; 2) Рус теленә борынгы славян теленнән кергән сүз яки тәгъбир

**СЛАВЯНОВЕД** СЛАВЯНОВЕД *к.* **славист**

**СЛАВЯНОВЕДЕНИЕ** СЛАВЯНОВЕДЕНИЕ Славян телләре, әдәбияты, мәдәнияте, тарихы турындагы фән

**СЛАВЯНСКИЕ ЯЗЫКИ** СЛАВЯН ТЕЛЛӘРЕ Һинд-европа телләре семьялыгының бер төркеме; көнчыгыш (*рус, украин, белорус*), көнбатыш (*поляк, чех, словак* һ.б.), көньяк (*болгар, серб-хорват, словен, македон, иске славян*) төркемчәләре бар

**СЛАВЯНСКОЕ ПИСЬМО** СЛАВЯН ЯЗУЫ Глаголица белән кириллица формасындагы язу. Алфавит составы, авазларның урнаштырылуы һәм хәрефләрнең авазлар белән белдерелүе

буенча глаголица кириллица белән тулысынча тәңгәл килә, әмма хәрефләренең формалары буенча нык аерыла

**СЛЕНГ** СЛЕНГ Арго һәм жаргон терминнарының стилистик синонимы

**СЛИТНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ОЕШМА ҖӨМЛӘ Составында тиңдәш кисәкләр булган җәенке җөмлә

**СЛИТНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ОЕШМА ТАРТЫКЛАР Составында ике элемент булган кушык тартык авазлар; аффрикатлар (мәс., *[ч] = [т] + [ш], [ц] = [т] + [с]*)

**СЛИЯНИЕ ЯЗЫКОВ** ТЕЛЛӘР КУШЫЛУ *к.* **скрещивание языков**

**СЛОВА-ПАРАЗИТЫ** ПАРАЗИТ СҮЗЛӘР Бернинди мәгънә белдермичә генә, гадәттә, сөйләүченең сөйләм культурасы түбән булу аркасында сөйләмгә килеп керә торган сүзләр (*значит*, *инде, менә, әйе бит* һ.б.)

**СЛОВА-ПРЕДЛОЖЕНИЯ** СҮЗ ҖӨМЛӘЛӘР Башка сүзләр ияртеп җәенкеләнә алмый торган, күбесенчә хәбәрлек сүзләр белән бирелгән җөмләләр; алда әйтелгән яки уйланган фикерне раслыйлар, я инкяр итәләр, әйтелгән фикергә тыңлаучының бәясен, мөнәсәбәтен белдерәләр (*әйе, юк, ярый, түгел, шулай, яхшы, әлбәттә* һ.б.)

**СЛОВАРИК** СҮЗЛЕКЧӘ Кечкенә сүзлек

**СЛОВАРНАЯ СТАТЬЯ** СҮЗЛЕК МӘКАЛӘСЕ Тел берәмлегеннән яки берәмлекләр төркеменнән (сүз, сүзләр оясы, морфема) торган аерым текст һәм аларның лексикографик тасвирламасы

**СЛОВАРНОЕ ГНЕЗДО** СҮЗЛЕК ОЯСЫ Бер сүзлек оясына туплап бирелгән тамырдаш сүзләр төркеме

**СЛОВАРНЫЙ ЗАПАС ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ СҮЗЛЕК ЗАПАСЫ Телдә кулланыла торган барлык сүзләр

**СЛОВАРНЫЙ СОСТАВ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ СҮЗЛЕК СОСТАВЫ Стиль ягыннан нейтраль булган гомумкулланыштагы лексика

**СЛОВАРЬ** СҮЗЛЕК, ЛӨГАТЬ 1) Лексика, сүз байлыгы, (берәр телнең яки язучының) сүзлек составы; 2) Билгеле бер

тәртиптә тупланган һәм төрле аңлатмалар бирелгән сүзләр җыелмасы; тәрҗемәле (икетелле, күптелле), аңлатмалы, этимология, орфография, орфоэпия, ешлык, синонимнар, антонимнар, омонимнар һ.б. төрләре бар

**СЛОВАРЬ АНТОНИМОВ** АНТОНИМНАР СҮЗЛЕГЕ Капма-каршы мәгънәдәге сүзләр алфавит тәртибендә бирелгән сүзлек

**СЛОВАРЬ ИНОСТРАННЫХ СЛОВ** ЧИТ ТЕЛ СҮЗЛӘРЕ СҮЗЛЕГЕ Теге яки бу телгә икенче телдән кергән сүзләрне үз эченә алган сүзлек

**СЛОВАРЬ ЛИНГВИСТИЧЕСКИХ ТЕРМИНОВ** ЛИНГВИСТИК (ТЕЛ БЕЛЕМЕ) ТЕРМИННАР СҮЗЛЕГЕ Тел белеменә караган терминнарны туплаган сүзлек

**СЛОВАРЬ ЛИЧНЫХ ИМЁН** КЕШЕ ИСЕМНӘРЕ СҮЗЛЕГЕ Теге яки бу халыкның кеше исемнәрен туплап алфавит тәртибендә төзелгән сүзлек

**СЛОВАРЬ ОМОНИМОВ** ОМОНИМНАР СҮЗЛЕГЕ Телдәге аваздаш сүзләрне туплап алфавит тәртибендә төзелгән сүзлек

**СЛОВАРЬ СИНОНИМОВ** СИНОНИМНАР СҮЗЛЕГЕ Телнең синонимнар байлыгын туплап алфавит тәртибендә оялап төзелгән сүзлек

**СЛОВАРЬ СОКРАЩЕНИЙ** КЫСКАРТЫЛМАЛАР СҮЗЛЕГЕ Кыскартылма сүзләргә аңлатма биргән һәм аларның грамматик үзенчәлекләрен күрсәткән сүзлек

**СЛОВАРЬ ЯЗЫКА ПИСАТЕЛЯ** ЯЗУЧЫ ТЕЛЕ СҮЗЛЕГЕ Теге яки бу язучының тел байлыгын, аның телендә очраган сүзләрнең кулланылышын күрсәтә торган сүзлек

**СЛОВЕСНИК** ТЕЛЧЕ, ӘДӘБИЯТЧЫ Тел-әдәбият белгече; тел-әдәбият укытучысы

**СЛОВЕСНОЕ УДАРЕНИЕ** СҮЗ БАСЫМЫ 1) Берничә иҗекле сүздәге бер иҗекне фонетик чара ярдәмендә (озынлык, көч, аерым көй) башка иҗекләрдән аерып әйтү; 2) Грамматик мәгънә үзгәртә торган чараларның бер төре

**СЛОВЕСНЫЙ ЗАПРЕТ** ТЫЕЛГАН СҮЗЛӘР Кайбер халыкларда балага ата исемен, хатынга иренең исемен әйтергә ярамау, исем белән атау тыелу күренеше

**СЛОВНИК** СҮЗЛЕКЧӘ, ЛӨГАТЬЛЕК Сүзлек мәкаләләренең баш сүзләре буларак сүзлеккә кертелгән сүзләр исемлеге

**СЛОВО** СҮЗ Бер яки берничә аваздан төзелеп, мәгълүм грамматик форма алган (морфологик төзелешкә ия, сөйләмдә җөмлә кисәге яки җөмлә булып кулланыла) һәм төшенчә белдергән телнең мәгънәле төп берәмлеге

**СЛОВОИЗМЕНИТЕЛЬНЫЕ АФФИКСЫ** ТӨРЛӘНДЕРГЕЧ КУШЫМЧАЛАР Җөмлә эчендә сүзләрне бәйләү өчен хезмәт итә торган кушымчалар; сүз бәйләгеч кушымчалар (мәс., килеш, тартым, зат-сан кушымчалары)

**СЛОВОИЗМЕНИТЕЛЬНЫЕ ОКОНЧАНИЯ** ТӨРЛӘНДЕРГЕЧ КУШЫМЧАЛАР *к.* **словоизменительные аффиксы**

**СЛОВООБРАЗОВАНИЕ** СҮЗЬЯСАЛЫШЫ 1) Телнең сүз ясау чаралары нигезендә яңа сүзләр ясалышы; 2) Яңа сүзләрнең һәм типларның ясалыш законнарын һәм ысулларын өйрәнә торган лингвистик дисциплина (грамматиканың бер тармагы)

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ КАТЕГОРИЯ** СҮЗЬЯСАЛЫШ КАТЕГОРИЯСЕ Бер үк сүзьясалыш мәгънәсенә ия булган сүзьясалыш типлары төркеме

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ МОДЕЛЬ** СҮЗЬЯСАЛЫШ МОДЕЛЕ Бер үк сүз төркеменә бер үк сүзьясагыч кушымчалар кушылып ясалган сүзләр

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОМОНИМИЯ** СҮЗЬЯСАЛЫШ ОМОНИМИЯСЕ Сүзьясалыш мәгънәләре ягыннан төрле булган морфемаларның авазлар ягыннан тәңгәл килүләре

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ПАРА** СҮЗЬЯСАЛЫШ ПАРЫ Ике тамырдаш (ясаучы белән ясалма) сүз (мәс., *каен – каенлык*, *таш – ташчы*, *авыл – авылдаш* һ.б.)

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ПАРАДИГМА** СҮЗЬЯСАЛЫШ ПАРАДИГМАСЫ Сүзьясалыш оясының бер үк сүзьясалыш

баскычында урнашкан бер нигез сүздән ясалган тамырдаш дериватлар җыелмасы (мәс., *ау, аулау, аучы, аучылык*)

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ СИНОНИМИЯ** СҮЗЬЯСАЛЫШ СИНОНИМИЯСЕ Бер үк нигездән төрле сүзьясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалган бер үк мәгънәдәге ясалма сүзләр (мәс., *тотка – тоткыч, каптырма – каптыргыч*)

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ЦЕПЬ (ЦЕПОЧКА)** СҮЗЬЯСАЛЫШ ЧЫЛБЫРЫ Бер үк тамырга бер-бер артлы берничә сүзьясагыч кушымча ялганып ясалган сүзләр теземе (мәс., *абруй – абруйлы – абруйлылык, гадәт – гадәттә – гадәттәге – гадәттәгечә*)

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ ГНЕЗДО** СҮЗЬЯСАЛЫШ ОЯСЫ Бер тамырдан сүзьясагыч кушымчалар кушып ясалган сүзләр төркеме (мәс., *акыл, акыллы, акыллылану, акыллылык, акылсыз, акылсызлану, акылсызлык*)

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ (ДЕРИВАЦИОННОЕ) ЗНАЧЕНИЕ** СҮЗЬЯСАЛЫШ МӘГЪНӘСЕ (ДЕРИВАЦИОН МӘГЪНӘ) Сүзъясагыч нигез белән яңа ясалган сүз арасында барлыкка килгән гомумиләштерелгән мәгънә, ягъни яңа сүз ясаганда, тамыр мәгънәсенә өстәлә торган категориаль мәгънә; яңа сүз мәгънәсе ( мәс., -*чы*/-*че* кушымчасы белән ясалган сүзләрдә ясаучы мәгънәсе *( тамгачы),* тамыр белдергән әйбер белән эш итүче *(ташчы),* тамыр белдергән әйберне корал итүче *(уракчы)* һ.б. деривацион мәгънәләр була)

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНЫЕ (ДЕРИВАЦИОННЫЕ) СРЕДСТВА** СҮЗЬЯСАГЫЧ (ДЕРИВАЦИОН) ЧАРАЛАР Яңа лексик мәгънә барлыкка китерә торган чаралар (мәс., *-лык*/*-лек* кушымчасы корал, җайланма *(күзлек, битлек),* предметлар тупланган урын *(каенлык, юкәлек),* әйберләр куела яки саклана торган урын *(утынлык, печәнлек),* абстракт билге, төшенчә *(картлык, матурлык)* һ.б. мәгънәләрне барлыкка китерә)

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНЫЕ СЛУЖЕБНЫЕ МОРФЫ** СҮЗЬЯСАГЫЧ ЯРДӘМЛЕК МОРФЛАР Яңа сүз ясый торган ярдәмлек морфлар

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНЫЕ АФФИКСЫ** СҮЗЬЯСАГЫЧ КУШЫМЧАЛАР *к.* **словообразовательные суффиксы**

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНЫЙ ПРИНЦИП (ЭТИМОЛОГИИ)** (ЭТИМОЛОГИЯНЕҢ) СҮЗЬЯСАЛЫШ ПРИНЦИБЫ Сүзнең этимологиясен билгеләүдә телдәге сүзьясалыш типларын тикшерүгә нигезләнгән принцип

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНЫЙ СЛОВАРЬ** СҮЗЬЯСАЛЫШ СҮЗЛЕГЕ сүзьясалышы күрсәтелгән сүзлек

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНЫЕ СУФФИКСЫ** СҮЗЬЯСАГЫЧ КУШЫМЧАЛАР Тамырга яки нигезгә ялганып, яңа мәгънәле лексик берәмлек барлыкка китерә торган кушымчалар (мәс., *таш-**чы**, агач-**лык**, төр-**дәш*** һ.б.); гади һәм кушма кушымчаларга бүленәләр

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНЫЙ ТИП** СҮЗЬЯСАЛЫШ ТИБЫ Бер үк сүз төркемнәреннән бер үк сүзьясалыш чарасы ярдәмендә ясалган, бер үк сүзьясалыш мәгънәсенә ия булган сүзләр төркеме (мәс., *якташ, авылдаш, юлдаш, замандаш, яшьтәш, милләттәш, фикердәш, каләмдәш*)

**СЛОВООБРАЗОВАТЕЛЬНЫЙ СПОСОБ** СҮЗЬЯСАЛЫШ ЫСУЛЫ *к.* **способ словообразования**

**СЛОВОПОРЯДОК** СҮЗ ТӘРТИБЕ *к.* **порядок слов**

**СЛОВОПРОИЗВОДНЫЕ СУФФИКСЫ** СҮЗЬЯСАГЫЧ КУШЫМЧАЛАР, СҮЗЬЯСАГЫЧ СУФФИКСЛАР *к.* **словообразовательные суффиксы**

**СЛОВОПРОИЗВОДСТВО** СҮЗЬЯСАЛЫШЫ, СҮЗ ЯСАУ, СҮЗ ЯСАЛУ Сүз ясау чаралары нигезендә яңа сүзләр ясалышы

**СЛОВОСОЕДИНИТЕЛЬНЫЕ АФФИКСЫ** СҮЗБӘЙЛӘГЕЧ АФФИКСЛАР *к.* **соединительные аффиксы**

**СЛОВОСОЕДИНИТЕЛЬНЫЕ СРЕДСТВА** СҮЗБӘЙЛӘГЕЧ ЧАРАЛАР Сүзләрне үзара бәйләү хезмәтен үти торган чаралар: бәйлекләр (*белән, кебек, өчен, кадәр, саен* һ.б.) һәм бәйлек сүзләр (*арада, вакытта, сәбәпле, заманда* һ.б.)

**СЛОВОСОЕДИНИТЕЛЬНЫЕ СЛУЖЕБНЫЕ МОРФЫ** СҮЗБӘЙЛӘГЕЧ ЯРДӘМЛЕК МОРФЛАР Төшенчәләр арасында мөнәсәбәт белдерә торган ярдәмлек морфлар

**СЛОВОСЛОЖЕНИЕ** СҮЗЛӘР КУШУ (ЫСУЛЫ) Ике яки сирәк кенә берничә гади нигезнең бер сүз булып кушылуы

**СЛОВОСОЧЕТАНИЕ** СҮЗТЕЗМӘ Үзара ачыклаучы (берсе икенчесен ачыклау, төгәлләү, конкретлаштыру), мөнәсәбәткә кергән ике яки берничә мөстәкыйль мәгънәле сүздән торган төзелмә (мәс., *матур уй, хат язу, шуа торган тау, эштә булу, зур базар* һ.б.); бәйләнешнең тотрыклылыгына карап, ирекле һәм фразеологик сүзтезмә, составы буенча гади һәм катлаулы сүзтезмә, ияртүче кисәкнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, фигыль сүзтезмә, исем сүзтезмә, сыйфат сүзтезмә, сан сүзтезмә, алмашлык сүзтезмә, рәвеш сүзтезмә, хәбәрлек сүзтезмәгә бүленәләр

**СЛОВОТВОРЧЕСТВО** СҮЗ ИҖАТ ИТҮ, ЯҢА СҮЗЛӘР ЯСАУ Шәхеснең телдә яңа сүзләр ясау юлы белән иҗади потенциалын тормышка ашыруы

**СЛОВОУПОТРЕБЛЕНИЕ** СҮЗ КУЛЛАНЫШЫ, СҮЗЛӘРНЕ КУЛЛАНУ, СҮЗЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫШЫ Сөйләмдә сүзләрне куллану, ягъни сөйләүченең максатына һәм коммуникатив ситуациягә бәйле рәвештә сөйләмдә сүзләр тезмәсен куллануы

**СЛОВОФОРМА** СҮЗФОРМА, СҮЗ ФОРМАСЫ Морфология өйрәнә торган иң зур (морфема һәм ясалма нигездән зур) берәмлек: (мәс., *таш-чы-лар-ыбыз, кыр-лар-ым-ның, көннәр-дә* һ.б.)

**СЛОГ** ИҖЕК Бер сузык аваздан гына яки бер сузык янында килгән бер яисә берничә тартыктан торган иң кечкенә сөйләмнең берәмлеге; ачык, ябык һәм ярымачык төрләре була

**СЛОГОВОЕ ПИСЬМО** ИҖЕК ЯЗУ, ИҖЕК ЯЗУЫ Бер билге бер авазны түгел, ә аерым иҗекне белдерә торган язу, силлабик язу (мәс., хәзерге һинд язуы шушы принципка нигезләнгән)

**СЛОГОВОЕ УДАРЕНИЕ** ИҖЕК БАСЫМЫ Сүздәге бер иҗекне башкаларыннан көчлерәк итеп әйтү; иҗек басымы сүз басымы белән туры килә

**СЛОГОВОЙ АКЦЕНТ** ИҖЕК АКЦЕНТЫ Бер иҗек эчендә, дөресрәге, иҗекнең иҗек ясый торган кисәгендә тон хәрәкәте, ягъни авазның көче үзгәрүе

**СЛОГОВОЙ ПРИНЦИП ПИСЬМА** ИҖЕКЛӘП ЯЗУ ПРИНЦИБЫ *к.* **слоговое письмо**

**СЛОГОРАЗДЕЛ** ИҖЕК ЧИГЕ Иҗекләр арасындагы чын яки мөмкин булган чик

**СЛОЖЕНИЕ** КУШУ Ике яки аннан күбрәк нигезләрне бергә кушу юлы белән яңа сүз ясау (мәс., *сабантуй, аккош, билбау* һ.б.)

**СЛОЖЕНИЕ ОСНОВ** НИГЕЗЛӘРНЕ КУШУ *к.* **сложение**

**СЛОЖНАЯ ОСНОВА** КУШМА НИГЕЗ Ике яки өч тамырдан торган нигез (мәс., *башкала, төньяк* һ.б.)

**СЛОЖНОЕ ГЛАГОЛЬНОЕ СКАЗУЕМОЕ** КУШМА ФИГЫЛЬ ХӘБӘР Төрле модаль мәгънәләр, процессның үтәлү дәрәҗәсен, төрле заман мәгънәләрен белдергән, ике яки берничә фигыльдән торган аналитик хәбәр

**СЛОЖНОЕ ИМЕННОЕ СКАЗУЕМОЕ** КУШМА ИСЕМ ХӘБӘР Фигыльдән башка сүз төркеменә ярдәмче фигыль яки бәйлек яисә кисәкчә ялганып белдерелгән хәбәр

**СЛОЖНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** КУШМА ҖӨМЛӘ Ике яки берничә хәбәрлеге булган җөмлә; ул үзе гади һәм катлаулы кушма җөмлә төрләренә бүленә; ә гади кушма җөмләләр үзләре тезмә һәм иярченле кушма җөмләләргә бүленә

**СЛОЖНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ С СОЧИНЕНИЕМ И ПОДЧИНЕНИЕМ** КАТНАШ КУШМА ҖӨМЛӘ Аерым җөмләләр үзара тезү юлы белән дә, ияртү юлы белән дә бәйләнгән җөмлә

**СЛОЖНОЕ СКАЗУЕМОЕ** КУШМА ХӘБӘР Составында грамматик мәгънә белдереп килгән ярдәмлек сүзләр булган хәбәр

**СЛОЖНОЕ СЛОВО (КОМПОЗИТ)** КУШМА СҮЗ (КОМПОЗИТ) Икедән дә ким булмаган тулы мәгънәле мөстәкыйль

тамырдан яки берсе тулы мәгънәле, икенчесе тулы мәгънәле булмаган сүздән гыйбарәт сүз

**СЛОЖНОЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЕ** КАТЛАУЛЫ СҮЗТЕЗМӘ Составында икедән артык мөстәкыйль сүз булган, гади сүзтезмәләргә таркалмый торган сүзтезмә

**СЛОЖНОПОДЧИНЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ Үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган җөмлә (ияреп килгән компонент иярчен җөмлә, ияртүче компонент баш җөмлә була). Иярчен җөмлә баш җөмләгә нинди юл белән бәйләнүенә карап, ике төргә бүленә: аналитик кушма җөмлә һәм синтетик кушма җөмлә

**СЛОЖНОСОКРАЩЁННЫЕ СЛОВА** КЫСКАРТЫЛГАН КУШМА СҮЗЛӘР, КЫСКАРТЫЛМА СҮЗЛӘР, КЫСКАРТЫЛМАЛАР Сүзтезмәләрнең беренче элементларын (морфемаларын) яки сүзләрнең беренче авазларын яки хәрефләрен кушу юлы белән ясалган сүзләр; ике төркемгә бүленәләр: инициаль кыскартылма сүзләр (мәс., *АКШ*, *КДУ*, *ТӘҺСИ*); элементлары кушылып ясалган кыскартылмалар (мәс., *драмтүгәрәк*, *профхәрәкәт*, *райком*)

**СЛОЖНОСПАЯННЫЕ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** СИНТЕТИК КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР *к.* **синтетические сложноподчиненные предложения**

**СЛОЖНОСОЧИНЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘ Үзара тезү юлы белән бәйләнгән ике яки берничә җөмләдән торган кушма җөмлә; теркәгечле һәм теркәгечсез төрләре була

**СЛОЖНЫЕ ГЛАГОЛЫ** КУШМА ФИГЫЛЬЛӘР Тезүле һәм ияртүле бәйләнештәге компонентлардан торган фигыльләр (мәс., *киңәш итү, риза булу, карар кылу* һ.б.)

**СЛОЖНЫЕ МЕСТОИМЕНИЯ** КУШМА АЛМАШЛЫКЛАР Ике компонент кушылып ясалган алмашлыклар (мәс., *һәрбер, бернинди, һичкем*, *ничаклы* һ.б.)

**СЛОЖНЫЕ (МНОГОМОРФНЫЕ) СЛУЖЕБНЫЕ МОРФЫ** КУШМА (КҮПМОРФЛЫ) ЯРДӘМЛЕК МОРФЛАР Нигезгә

һәм кушымчага бүленә торган ярдәмлек морфлар (мәс., *әни аркасы-н-да, авыру сәбәп-ле* һ.б.)

**СЛОЖНЫЕ МОРФЕМЫ** КУШМА МОРФЕМАЛАР Ике яки аннан артык морфемадан торган морфемалар (мәс., *-дагы, -лыктан, -ырга, -ныкы* һ.б.)

**СЛОЖНЫЕ НАРЕЧИЯ** КУШМА РӘВЕШЛӘР Ике компоненттан торган рәвешләр (мәс., *ачлы-туклы, аз-маз, баштүбән, берсүзсез* һ.б.)

**СЛОЖНЫЕ ПРИЛАГАТЕЛЬНЫЕ** КУШМА СЫЙФАТЛАР Ике компонент кушылып ясалган сыйфатлар (мәс., *эреле-ваклы, алмачуар, сусөяр* һ.б.)

**СЛОЖНЫЕ СЛОВОФОРМЫ** КУШМА СҮЗФОРМАЛАР Ярдәмлек морфлар ярдәмендә ясалган сүзформалар

**СЛОЖНЫЕ СУФФИКСЫ** КУШМА КУШЫМЧАЛАР, КУШМА СУФФИКСЛАР Ике яки берничә берекқән кушымчадан гыйбарәт һәм бер сүзьясалыш мәгънәсе белдерә торган кушымчалар (мәс., *-чы+лык/-че+лек, -ын+кы/-ен+ке* һ.б.)

**СЛОЖНЫЕ СУЩЕСТВИТЕЛЬНЫЕ** КУШМА ИСЕМНӘР Ике компоненттан торган исемнәр: *дус-иш, билбау, каен җиләге* һ.б.

**СЛОЖНЫЕ ЧИСЛИТЕЛЬНЫЕ** КУШМА САННАР Бердән артык компоненттан торган саннар (мәс., *унбиш, туксан биш, ун мең* һ.б.)

**СЛУЖЕБНЫЕ СЛОВА** ЯРДӘМЛЕКЛӘР, ЯРДӘМЛЕК СҮЗЛӘР *к.* **служебные части речи**

**СЛУЖЕБНЫЕ МОРФЫ** ЯРДӘМЛЕК МОРФЛАР Тышкы кыяфәтләре белән аерым сүзгә охшаган, сүзгә ассимиляцияләнеп кушылып китмәгән, грамматик мәгънә белдергән морфлар; ясагыч һәм төрләндергеч төрләргә бүленәләр, төрләндергечләре бәйләүчеләргә һәм модаль мәгънә белдерүчеләргә аерыла

**СЛУЖЕБНЫЕ ЧАСТИ РЕЧИ** ЯРДӘМЛЕК СҮЗЛӘР, ЯРДӘМЛЕКЛӘР 1) Атау функциясе башкармыйча, бары мөстәкыйль сүзләрне бер-берсенә бәйләү, яки модаль мәгънәләр белдерү өчен генә хезмәт итә, мөстәкыйль җөмлә кисәге булып

килми торган сүзләр (теркәгеч, бәйлек, кисәкчә, модаль сүзләр). Үзләре бәйләгеч сүзләр (бәйлекләр – *белән, кебек, өчен, кадәр, саен* һ.б., бәйлек сүзләр – *заманда, арада, вакытта, сәбәпле* һ.б.) һәм модаль сүзләргә (*имеш, бугай, янәсе, ичмасам, әлбәттә* һ.б.) бүленәләр; 2) Грамматик мәгънә белдергән чараларның бер төре: предлоглар, послелоглар, артикльләр, кисәкчәләр һ.б.

**СМЕШАННОЕ СЛОЖНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** КАТНАШ КУШМА ҖӨМЛӘ Аерым җөмләләрнең бер төрләре үзара ияртүле юл белән бәйләнеп, икенче төрләре тезүле юл белән бәйләнеп ясалган катлаулы кушма җөмлә

**СМЫЧНО-ПРОХОДНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ЯРЫМЙОМЫК ТАРТЫКЛАР Әйткән вакытта сөйләм аппаратының бер урыны йомылып, икенче җирдән һава өрелеп ясала торган тартыклар; борын тартыкларына *([м], [н], [ң]),* ян-як тартыкларына *([л])* бүленәләр

**СМЫЧНЫЕ ЗВУКИ** ЙОМЫК АВАЗЛАР *к.* **смычные согласные**

**СМЫЧНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ЙОМЫК ТАРТЫКЛАР Сөйләм органнарының берәр урында йомылуы һәм йомылуның шартлап ачылуы нәтиҗәсендә ясала торган тартык авазлар (мәс., *[п], [т], [к]* һ.б.)

**СМЯГЧЕНИЕ** НЕЧКӘРТҮ, НЕЧКӘРҮ *к.* **палатализация**

**СОБИРАТЕЛЬНЫЕ СУЩЕСТВИТЕЛЬНЫЕ** ҖЫЙМА ИСЕМНӘР Бер төрдән булган предметларның җыелмасын атый торган сүзләр: *ташлык, каенлык, җиләклек* һ.б.

**СОБИРАТЕЛЬНЫЕ ЧИСЛИТЕЛЬНЫЕ** ҖЫЮ САННАРЫ Төрдәш әйберләрне бергә җыйнау-туплауны белдерә торган саннар, микъдар санына -*ау*/-*әү* кушымчасы ялганып ясала (мәс., *дүртәү*, *алтау*, *җидәү* һ.б.)

**СОБСТВЕННОЕ ИМЯ** ЯЛГЫЗЛЫК ИСЕМ Бер төрдән булган әйберләрнең берсенә генә бирелә торган исем (кеше исемнәре, фамилияләр, географик атамалар, газета, журнал, китап исемнәре, хайван кушаматлары һ.б.)

**СОБСТВЕННО ВОПРОСИТЕЛЬНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ЧЫН СОРАУ ҖӨМЛӘ Турыдан-туры җавап таләп итә, шунсыз сөйләмне дәвам итеп булмый торган җөмлә (мәс., *Башка сүзегез юкмы*?); татар телендә сорау җөмләләр *-мы/-ме* сорау кушымчалары, сорау алмашлыклары, сорау рәвешләре, сорау интонациясе ярдәмендә белдерелә

**СОБСТВЕННО ЛЕКСИЧЕСКИЕ ОМОНИМЫ** САФ ЛЕКСИК ОМОНИМНАР (ТАМЫР ОМОНИМНАР) Теләсә нинди фонетик, грамматик шартларда аваз составы ягыннан да, тамыр хәлендә дә бер-берсенә охшаш омонимнар (мәс., *ат* (исем) – *ат* (хайван); *корт* (бөҗәк) – *корт* (киптерелгән эремчек) һ.б.)

**СОБСТВЕННО РУССКИЕ СЛОВА** САФ РУС СҮЗЛӘРЕ *к.* **русизмы**

**СОБСТВЕННО СЛОЖНЫЕ СЛОВА** САФ КУШМА СҮЗЛӘР Үзара атрибутив, объект һәм предикатив бәйләнештәге сүзләрнең кушылуыннан барлыкка килгән кушма сүзләр (мәс., *аккош, Уразбакты, Сабантуй* һ.б.)

**СОВЕРШЕННЫЙ ВИД** СОВЕРШЕННЫЙ ВИД (ТӘМАМЛАНГАН ТӨР) Рус телендә: ниндидер момент эчендә башкарылган эш-хәрәкәтне белдерә торган фигыль категориясе; совершенный видка тәмамланганлык, кинәтлек, чикләнгәнлек мәгънәләре хас

**СОВЕТИЗМЫ** СОВЕТИЗМНАР 1917 елгы Октябрь революциясеннән соң яңа иҗтимагый тормышка бәйле рәвештә барлыкка килгән сүзләр (мәс., *кызыллар, коммуна, эшчеләр факультеты, ярлылар комитеты, кызыл гвардияче* һ.б.)

**СОГЛАСНЫЕ ЗВУКИ** ТАРТЫК АВАЗЛАР Акустик яктан бары шаудан гына яки тавыш һәм шаудан гына торган, әйткән вакытта һава агымының сөйләм аппаратында тоткарлыкларга очравы нәтиҗәсендә ясала торган авазлар (мәс., *[б], [п], [т], [җ]* һ.б.)

**СОГЛАСОВАНИЕ** ЯРАШУ Кайбер телләрдә ияртүле бәйләнешнең бер төре: грамматик мәгънә белдергәндә, иярүче сүз ияртүче сүзгә грамматик билгеләре белән охшый

**СОГЛАСОВАНИЕ ПОЛНОЕ** ТУЛЫ ЯРАШУ Затта, санда, килештә ярашу (мәс., *алар килделәр*; *безнең өйләребезнең* һ.б.)

**СОДЕРЖАНИЕ** ЭЧТӘЛЕК Текстта хикәя ителә торган нәрсә; текстның темасы һәм аның автор күзаллавы буенча җәелдерелүе

**СОЕДИНИТЕЛЬНЫЕ АФФИКСЫ** СҮЗБӘЙЛӘГЕЧ АФФИКСЛАР (КУШЫМЧАЛАР), БӘЙЛӘГЕЧЛӘР Сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйләүче аффикслар (кушымчалар) (мәс., исемнәрдә килеш һәм тартым кушымчалары, фигыльләрдә рәвеш фигыль кушымчалары)

**СОЕДИНИТЕЛЬНЫЕ МОРФЕМЫ** БӘЙЛӘГЕЧ МОРФЕМАЛАР *к.* **интерфиксы**

**СОЕДИНИТЕЛЬНЫЕ ГЛАСНЫЕ** КУШУЧЫ СУЗЫКЛАР Кушма сүзләрдә ике яки аннан артык нигезне кушучы морфемалар (мәс., *паровоз* дигәндә беренче *о* – ике сүзне кушучы сузык)

**СОЕДИНИТЕЛЬНЫЕ СОЮЗЫ** ҖЫЮЧЫ ТЕРКӘГЕЧЛӘР Җөмләдә җөмлә кисәкләрен һәм җөмләләр арасында берничә сүзне бергә тезеп, санап китү юлы белән бәйли торган теркәгечләр (мәс., *һәм, ни – ни, да-дә /та-тә, тагын, тагы, янә*)

**СОКРАЩЁННОЕ СЛОВО** КЫСКАРТЫЛМА СҮЗ *к.* **аббревиатура**

**СОЛЕЦИЗМЫ** СОЛЕЦИЗМНАР Синтаксик ялгышлар

**СОНАНТ** СОНАНТ Акустик яктан тавыш шаудан өстенлек иткән, яңгырашы белән сузык авазга якын торган тартык аваз (мәс., *[р], [м], [н], [й], [ң], [w], [л]* һ.б.)

**СОНОР** СОНОР *к.* **сонант**

**СОНОРНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** СОНОР ТАРТЫКЛАР Әйткәндә тон өстенлек итә торган авазлар (мәс., *[р], [м], [н], [й], [ң], [w], [л]*)

**СОПОДЧИНИТЕЛЬНЫЕ СЛОЖНЫЕ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ТИҢДӘШ ИЯРТҮЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘР Берничә иярчен компонент бер баш җөмләгә буйсынып килеп, аларның барысы да бер үк функция үти торган кушма җөмлә

**СОПОСТАВИТЕЛЬНАЯ ГРАММАТИКА** ЧАГЫШТЫРМА ГРАММАТИКА Төрле типтагы телләрне чагыштырма планда өйрәнә торган грамматика

**СОПОСТАВИТЕЛЬНАЯ ЛИНГВИСТИКА** ЧАГЫШТЫРМА ЛИНГВИСТИКА Лингвистиканың кардәшлеккә бәйсез рәвештә телләр арасындагы функциональ охшашлыкларны һәм аермалыкларны өйрәнә торган тармагы

**СОПОСТАВИТЕЛЬНАЯ ФОНЕТИКА** ЧАГЫШТЫРМА ФОНЕТИКА Фонетиканың төрле телләрдәге аваз төзелешен чагыштырып, алар арасындагы охшашлыкларны һәм аермалыкларны өйрәнә торган тармагы

**СОПОСТАВИТЕЛЬНО-ТИПОЛОГИЧЕСКИЙ СИНТАКСИС** ТӨРЛЕ ТИПТАГЫ ТЕЛЛӘРНЕ ЧАГЫШТЫРУ СИНТАКСИСЫ *к.* **контрастивный синтаксис**

**СОСЕДСТВО ЗВУКОВ** АВАЗЛАР ЧОЛГАНЫШЫ Сөйләмдә авазларның рәттән килүләре (мәс., *ата* дигәндә *т* авазы сузыклар чолганышында)

**СОСЕДСТВО СЛОВ** СҮЗЛӘР ЯНӘШӘ ТОРУ Кайбер тезмәләрдә сүзләрнең, бары янәшә торып кына, үзара синтаксик мөнәсәбәткә керүләре, ягъни тезмәләрдә сүзләрнең үзара янәшә тору чарасы аша бәйләнүе

**СОСЛАГАТЕЛЬНОЕ НАКЛОНЕНИЕ** ШАРТЛЫ ТЕЛӘК НАКЛОНЕНИЕСЕ, ШАРТ ФИГЫЛЬ Фигыльнең киләчәктә булуы мөмкин, булыр дип фараз кылынган эш-хәлләрне, шулай ук киләчәккә юнәлтелгән теләкне, ихтыярны белдерә торган формасы

**СОСТАВНОЕ ГЛАГОЛЬНОЕ СКАЗУЕМОЕ** ТЕЗМӘ ФИГЫЛЬ ХӘБӘР Исем, сыйфат, сан, хәбәрлек сүзләргә ярдәмче фигыльләр ялгану юлы белән ясалган тезмә сүзләр һәм фразеологизмнар белән белдерелгән фигыль хәбәр

**СОСТАВНОЕ ИМЕННОЕ СКАЗУЕМОЕ** ТЕЗМӘ ИСЕМ ХӘБӘР Фигыльдән башка сүз төркемнәреннән торган фразеологизм яки синтаксик сүзтезмә белән бирелгән хәбәр

**СОСТАВНОЕ ПОДЛЕЖАЩЕЕ** ТЕЗМӘ ИЯ Тезмә сүз, фразеологик берәмлек яки аерым кисәкләргә таркалмый торган сүзләр тезмәсе белән бирелгән ия

**СОСТАВНОЕ СКАЗУЕМОЕ** ТЕЗМӘ ХӘБӘР Фразеологик берәмлек яки аерым кисәкләргә таркалмый торган синтаксик сүзтезмә белән белдерелгән хәбәр

**СОСТАВНЫЕ ГЛАГОЛЫ** ТЕЗМӘ ФИГЫЛЬЛӘР Аерым компонентлары фигыль белән белдерелгән һәм бер лексик мәгънә белдергән фигыльләр (мәс., *укып чыгу*, *каушап төшү*, *йоклап алу* һ.б.)

**СОСТАВНЫЕ ИЛИ СМЕШАННЫЕ ЧИСЛИТЕЛЬНЫЕ** ТЕЗМӘ ЯКИ КАТНАШ САННАР Компонентлары икедән күбрәк булган саннар (мәс., *биш йөз ун, алты мең бер йөз утыз дүрт, өч йөз илле мең* һ.б.)

**СОСТАВНЫЕ СЛОВА** ТЕЗМӘ СҮЗЛӘР Компонентлары арасындагы бәйләнешләр туры мәгънәсен югалткан, лексикалашкан сүзтезмәләр; нинди сүз төркеменә каравыннан чыгып, татар телендә тезмә исемнәр (*җир җиләге, үги ана яфрагы*), тезмә сыйфатлар (*зәңгәр күзле, зифа буйлы*), тезмә саннар (*кырык биш, илле алты*), тезмә алмашлыклар (*әллә кем, әллә ни*), тезмә фигыльләр (*сабыр ит, тәэсир ит, язып бар, укып чык*), тезмә рәвешләр (*яшь көенчә*) була

**СОСТАВ СЛОВА** СҮЗ ТӨЗЕЛЕШЕ Сүзнең морфологик төзелеше (тамыр нигезле, ясалма нигезле, кушма нигезле сүзләр, аларның сүзьясагыч, төр ясагыч һәм төрләндергеч кушымчалары була)

**СОЦИОЛЕКТ** СОЦИОЛЕКТ, ИҖТИМАГЫЙ (СОЦИАЛЬ) ДИАЛЕКТ Аерым бер социаль төркем (яшь буенча, профессия һ.б.) өчен хас булган тел чаралары һәм сөйләм үзенчәлекләре

**СОЦИАЛЬНОЕ ЯЗЫКОЗНАНИЕ** ИҖТИМАГЫЙ (СОЦИАЛЬ) ТЕЛ БЕЛЕМЕ (ГЫЙЛЕМЕ) Әдәби тел турында фән (диалектология, стилистика, поэтика һ.б.ш.)

**СОЦИАЛЬНЫЙ АСПЕКТ** ИҖТИМАГЫЙ, СОЦИАЛЬ АСПЕКТ *к.* **лингвистический аспект**

**СОЦИОЛИНГВИСТИКА** СОЦИОЛИНГВИСТИКА, ИҖТИМАГЫЙ (СОЦИАЛЬ) ЛИНГВИСТИКА Лингвистика белән социология чигендә барлыкка килгән һәм телнең иҗтимагый асылын, тел үсешенә экстралингвистик факторларның йогынтысын, тел сәясәте мәсьәләләрен өйрәнә торган тел гыйлеменең бер бүлеге

**СОЦИОФОНЕТИКА** СОЦИОФОНЕТИКА, СОЦИАЛЬ ФОНЕТИКА Фонетиканың нинди дә булса бер сүзнең ни дәрәҗәдә таралышын, аның теге яки бу вариантының халыкның кайсы катламы кулланганын өйрәнә торган тармагы

**СОЧИНЕНИЕ** 1) СОЧИНЕНИЕ Укучының тел-әдәбият буенча берәр темага үз сүзләре белән язылган мөстәкыйль эше; инша; 2) ӘДӘБИ ӘСӘР Матур әдәбият әсәре; 3) ТЕЗҮЛЕ БӘЙЛӘНЕШ Ике яисә берничә бәйсез җөмләне тезү юлы белән бер җөмлә итеп кушу, төзү

**СОЧИНИТЕЛЬНАЯ СВЯЗЬ** ТЕЗҮЛЕ БӘЙЛӘНЕШ Сүзләрнең бер-берсенә буйсынмыйча, үзара тигез хокукта бәйләнеше

**СОЧИНИТЕЛЬНЫЕ СОЮЗЫ** ТЕЗҮЧЕ ТЕРКӘГЕЧЛӘР Җөмлә кисәкләре һәм җөмләләр арасында җыю, каршы кую, бүлү мәгънә бәйләнешләрен белдерә, тиңдәш кисәкләрне һәм тезмә кушма җөмләдә гади җөмләләрне бәйли торган теркәгечләр; җыючы *(һәм, вә, тагын, янә, да/дә),* каршы куючы *(ләкин, әмма, ә, бәлки, тик, фәкать)* һәм бүлүче *(я, яки, яисә, әле... әле, бер... бер)* теркәгечләргә аерылалар

**СОЧИНИТЕЛЬНЫЕ СРЕДСТВА** ТЕЗҮЛЕ МӘГЪНӘ БЕЛДЕРҮЧЕ ЧАРАЛАР, ТЕЗҮЧЕ ЧАРАЛАР Җөмләләр арасындагы тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар (санау һәм каршылык интонацияләре, тезүче теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр)

**СОЮЗ** ТЕРКӘГЕЧ Җөмлә кисәкләрен һәм кушма җөмләдә гади җөмләләрне үзара бәйли, терки һәм алар арасындагы төрле мәгънә мөнәсәбәтләрен белдерү өчен хезмәт итә торган ярдәмлек сүз төркеме

**СОЮЗНЫЕ СЛОВА** ТЕРКӘГЕЧ СҮЗЛӘР Сүзләрне үзара бәйләү өчен хезмәт итә һәм җөмлә кисәге дә булып килә торган сүзләр

**СОЮЗНОЕ СЛОЖНОСОЧИНЕННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ТЕРКӘГЕЧЛЕ ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘ Аерым җөмләләре үзара тезүче теркәгечләр белән бәйләнгән тезмә кушма җөмлә

**СПАЯННОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** БЕРЕКМӘ ҖӨМЛӘ *к.* **синтетическое сложное предложение**

**СПЕКТРАЛЬНЫЙ АНАЛИЗ** СПЕКТРАЛЬ АНАЛИЗ Экспериментал фонетикада кулланыла торган махсус аппарат (спектрограф) ярдәмендә авазларны төзегән тавыш дулкыннарын ешлыкларга таркатып караудан, авазларның спектрын (спектрограмма) төшерүдән гыйбарәт алым

**СПЕКТР ЗВУКА РЕЧИ** СӨЙЛӘМ АВАЗЛАРЫНЫҢ СПЕКТРЫ Формантлар һәм формантара өлкәләрнең җыелмасы

**СПЕЦИАЛЬНАЯ ЛЕКСИКА** МАХСУС ЛЕКСИКА Теге яки бу профессия белгечләре тарафыннан гына кулланыла торган лексика

**СПИРАНТЫ** СПИРАНТЛАР *к.* **щелевые согласные**

**СПОСОБ ОБРАЗОВАНИЯ** ЯСАЛУ ЫСУЛЫ Фонетикада тартык авазны әйткәндә, үпкәдән килә торган һава агымына тоткарлык ясалу ысулы (сөйләм органнарының йомылуы, фокус аша һава өрелү, берәр органның калтыравы). Тартык авазларны артикуляцион яктан төркемләүнең икенче нигезе: ясалу урыны. Бу яктан тартыклар ирен-ирен, ирен-теш, тел алды, тел уртасы, тел арты, кече тел, йоткылык, бугаз тартыклары дигән төркемнәргә бүленәләр

**СПОСОБ СЛОВООБРАЗОВАНИЯ** СҮЗЬЯСАЛЫШ ЫСУЛЫ Телнең материаль берәмлекләреннән, алар арасында сүзьясалыш мөнәсәбәтләре хасил итеп, яңа сүзләр ясау алымы, методы, сүзьясалыш чараларын куллану мөмкинлекләре һәм шартлары; татар телендә сүзьясалышының берничә ысулы бар: фонетик ысул, кушымчалау ысулы, сүзләр кушылу, сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе, сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә

күчүе, конверсия (лексик-грамматик ысул), лексик-семантик ысул, аббревация (кыскартылмалар ясалышы)

**СПОНТАННЫЕ ИЗМЕНЕНИЯ ЗВУКОВ** АВАЗЛАРНЫҢ ҮЗЛЕГЕННӘН ҮЗГӘРҮЛӘРЕ Тышкы тәэсир сәбәпче булмаган үзгәрешләр

**СПРЯЖЕНИЕ** ФИГЫЛЬ ТӨРЛӘНЕШЕ Фигыльнең зат, сан һәм заман белән төрләнеше

**СРАВНЕНИЕ** ЧАГЫШТЫРУ Бер предметны икенче предметка охшатуны эченә алган фраза, тәгъбир, тезмә

**СРАВНИТЕЛЬНАЯ ГРАММАТИКА** ЧАГЫШТЫРМА ГРАММАТИКА Грамматиканың кардәш телләрне чагыштырып өйрәнә торган тармагы (мәс., славян телләренең чагыштырма грамматикасы һ.б.)

**СРАВНИТЕЛЬНАЯ СТЕПЕНЬ** ЧАГЫШТЫРУ ДӘРӘҖӘСЕ *к.* **степень сравнения**

**СРАВНИТЕЛЬНАЯ ФОНЕТИКА** ЧАГЫШТЫРМА ФОНЕТИКА Фонетиканың чит телләрдәге авазларны туган телдәге авазлар белән чагыштырып өйрәнә торган тармагы

**СРАВНИТЕЛЬНО-ИСТОРИЧЕСКИЕ СЛОВАРИ** ЧАГЫШТЫРМА ТАРИХИ СҮЗЛЕКЛӘР Теге яки бу тарихи чорның кардәш телләрендәге сүзләрне чагыштырып төзелгән сүзлекләр

**СРАВНИТЕЛЬНО-ИСТОРИЧЕСКИЙ МЕТОД ЯЗЫКОЗНАНИЯ** ТЕЛ БЕЛЕМЕНЕҢ ЧАГЫШТЫРМА ТАРИХИ МЕТОДЫ, ЫСУЛЫ Кардәш телләрнең үсеш тарихын билгеләгән законнарны ачу өчен хезмәт итә торган метод, кардәш телләрдәге кардәш күренешләр җыелмасын һәм бу күренешләрдә сакланган борынгы закончалыкларны өйрәнүгә нигезләнгән метод

**СРАВНИТЕЛЬНО-ИСТОРИЧЕСКОЕ ЯЗЫКОЗНАНИЕ** ЧАГЫШТЫРМА ТАРИХИ ТЕЛ БЕЛЕМЕ (ГЫЙЛЕМЕ) Тел белеменең телләр арасындагы кардәшлекне чагыштыру юлы белән билгели һәм кардәш телләр арасындагы аерманы тарихи үзгәрешләр нәтиҗәсе дип карый торган тармагы

**СРАВНИТЕЛЬНЫЕ КОНСТИТУТИВНЫЕ ПРИЗНАКИ МОРФЕМ** МОРФЕМАЛАРНЫҢ КОНСТИТУТИВ ЧАГЫШТЫРМАЛЫ БИЛГЕЛӘРЕ Башка билгеләре бердәй булган ике генә булса да фонемада табыла торган билгеләр; дифференциаль билгеләр

**СРАВНИТЕЛЬНЫЙ МЕТОД В ЯЗЫКОЗНАНИИ** ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ (ГЫЙЛЕМЕНДӘ) ЧАГЫШТЫРУ МЕТОДЫ Кардәш телләрне чагыштырып өйрәнүгә нигезләнгән метод

**СРАЩЕНИЯ** НЫГЫМАЛАР Фразеологизмның һәр элементын аерым алганда да аңлашыла торган бер төре

**СРЕДНЕ-ВОЗВРАТНЫЙ ЗАЛОГ** КАЙТЫМ ЮНӘЛЕШЕ Субъект үз эшенең объекты да була алган, эшнең үтәүчегә кайтуын белдерә торган фигыль формасы; *-ын/-ен/-н* кушымчалары ярдәмендә ясала

**СРЕДНЕНЁБНЫЕ ЗВУКИ** АҢКАУ УРТАСЫ АВАЗЛАРЫ *к.* **среднеязычные звуки**

**СРЕДНЕНЁБНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** УРТА АҢКАУ ТАРТЫКЛАРЫ *к.* **среднеязычные согласные**

**СРЕДНЕЯЗЫЧНЫЕ ЗВУКИ** ТЕЛ УРТАСЫ АВАЗЛАРЫ *к.* **среднеязычные согласные**

**СРЕДНЕЯЗЫЧНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ТЕЛ УРТАСЫ ТАРТЫКЛАРЫ Телнең уртасы каты аңкауга тию яки якынаю юлы белән ясала торган тартыклар (*[й]* тартыгы)

**СРЕДНИЕ ГЛАСНЫЕ** УРТА КҮТӘРЕЛЕШЛЕ СУЗЫКЛАР Әйткәндә, тел дә, аскы ияк тә уртача күтәрелештә тора торган сузыклар (*[о], [е]* сузыклары)

**СРЕДНИЙ ДИАЛЕКТ** УРТА ДИАЛЕКТ Татар теленең башка диалектлардан увуляр тартыкларның әйтелүе, *[й]*не *[җ]*ләштерү, *[а]*ның иренләшүе, инфинитив формаларының күп булуы белән аерылып торган өч диалектының берсе; тау ягы, казан арты, минзәлә, бәрәңге, гайнә, камышлы һ.б. сөйләшләре керә

**СРЕДНИЙ МОМЕНТ** УРТА МОМЕНТ Фонетикада: теге яки бу авазны әйтү процессындагы бер фаза

**СРЕДНИЙ РОД** СРЕДНИЙ РОД Рус телендә *-о*/*-е* кушымчаларына тәмамланган җансыз зат исемнәренең грамматик категориясе

**СРЕДСТВА СВЯЗИ** БӘЙЛӘҮЧЕ ЧАРАЛАР Синтаксик төзелмә компонентларын берләштерү хезмәтен үти һәм алар арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләре урнаштыра торган берәмлекләр: кушымта, мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгеч сүзләр, теркәгечләр, сүзләрне кабатлау, хәбәр итү, ачыклау, аныклау, көттерү, кереш, өстәлмә, санау интонацияләре, сүз тәртибе

**СРЕДСТВА СВЯЗИ СЛОВ** СҮЗЛӘРНЕ БӘЙЛӘҮЧЕ ЧАРАЛАР Сүзләр арасындагы мәгънәви мөнәсәбәтләрне белдерә торган чаралар

**СТАРОСЛАВЯНИЗМЫ** СТАРОСЛАВЯНИЗМНАР, БОРЫНГЫ СЛАВЯНИЗМНАР Рус теленә борынгы славян теленнән кергән сүзләр яки тәгъбирләр

**СТАРОСЛАВЯНСКИЙ ЯЗЫК** БОРЫНГЫ СЛАВЯН ТЕЛЕ Славяннарның X–XI гасыр язма истәлекләрендә теркәлгән бик борынгы тел

**СТАРОТАТАРСКИЙ ЯЗЫК** ИСКЕ ТАТАР ТЕЛЕ XV гасырдан XIX гасырның беренче яртысына кадәр кулланылган татар теле

**СТАТИСТИЧЕСКАЯ МЕТОДИКА ИЗУЧЕНИЯ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕ ӨЙРӘНҮНЕҢ СТАТИСТИК АЛЫМЫ Телне өйрәнүнең ихтималлык теориясенә һәм математик статистикага нигезләнгән алымы

**СТАТИСТИЧЕСКИЕ УНИВЕРСАЛИИ** СТАТИСТИК УНИВЕРСАЛИЯЛӘР Күпчелек телләрдә очрый торган грамматик күренешләр

**СТАТИЧЕСКАЯ ФОНЕТИКА** СТАТИК ФОНЕТИКА *к.* **описательная фонетика**

**СТЕНОГРАММА** СТЕНОГРАММА Стенографик язу

**СТЕНОГРАФ** СТЕНОГРАФ Стенография белгече

**СТЕНОГРАФИЯ** СТЕНОГРАФИЯ Сөйләгәнне тиз язып бару өчен аерым билгеләр куллану юлы белән кыскартып язу ысулы

**СТЕПЕНЬ** ДӘРӘҖӘ 1) Асыл сыйфат билгеләренең дәрәҗәсен белдерә торган һәм кайбер рәвешләргә хас булган грамматик категория; төп *(кара, тиз)*, чагыштыру *(карарак, тизрәк)*, артыклык *(кап-кара, тип-тиз)*, кимлек *(карасу, кызгылт)* дәрәҗәләре була; 2) Махсус кушымчалар яки аналитик чаралар ярдәмендә эшнең үтәлү дәрәҗәсен, үтәлү характерын белдерә торган фигыльләргә хас грамматик категория (мәс., *баргалау, көлемсерәү, укып бару, карап чыгу* һ.б.)

**СТЕПЕНЬ СРАВНЕНИЯ** ЧАГЫШТЫРУ ДӘРӘҖӘСЕ Сыйфатларда бер әйбердәге билгенең шундый ук билгедән артыграк яки кимрәк булуын белдерә торган дәрәҗә (мәс., *чибәррәк, зуррак, кызурак* һ.б.)

**СТИЛЕВЫЙ СИНОНИМ** СТИЛЬ СИНОНИМЫ Аерым бер сөйләм стиле синонимы (*үлү*, *кату*, *дөмегү*, *чәнчелү* һ.б.)

**СТИЛИЗАЦИЯ** СТИЛИЗАЦИЯ, СТИЛЬЛӘШТЕРҮ Берәр төрле стильне аңлы рәвештә охшатып кабатлау; стилизацияне чит стильнең әдәби имитациясе дип тә әйтеп була

**СТИЛИСТИКА** СТИЛИСТИКА Төрле стильләрне (сөйләм стиле, фәнни стиль, поэтик стиль һ.б.) һәм әдәби тел тарихына бәйле стильләрнең эволюциясен өйрәнә торган тел гыйлеме тармагы

**СТИЛИСТИЧЕСКИЕ ИЗМЕНЕНИЯ (ФОРМЫ) МОДЕЛЕЙ ПРОСТОГО ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ГАДИ ҖӨМЛӘ МОДЕЛЬЛӘРЕНЕҢ СТИЛИСТИК ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ (ФОРМАЛАРЫ) Җөмләдә лексик берәмлекләрнең һәм контекстның үзенчәлекле кулланышына нигезләнгән үзгәрешләр

**СТИЛИСТИЧЕСКИЕ СИНОНИМЫ** СТИЛИСТИК СИНОНИМНАР Куллану стиле белән аерыла торган синонимнар

**СТИЛИСТИЧЕСКИЕ СУФФИКСЫ** СТИЛИСТИК КУШЫМЧАЛАР Сүзнең стилистик төсмерен үзгәртә торган кушымчалар (мәс., *-кай/-кәй, -чык/-чек, -кәш* – иркәләү-кечерәйтү кушымчалары)

**СТИЛИСТИЧЕСКИЙ МЕТОД** СТИЛИСТИК МЕТОД Телнең төрле стильләрен тикшергәндә кулланыла торган һәм һәр

стильнең табигатен танып белү, бер стильне башкаларыннан аера торган фонетик, грамматик һ.б. билгеләрне ачыклаудан гыйбарәт метод

**СТИЛЬ** СТИЛЬ 1) Нинди дә булса җәмгыятьтә иҗтимагый тормышның билгеле бер сферасына беркетелгән тел үзенчәлекләре (нейтраль, югары (китап), түбән (сөйләм) стиль); 2) Әдәби телнең бер төре (*әдәби, техник стильләр, газета, эш кәгазьләре стиле*); 3) Берәр сөйләм акты яки әсәр башкарылган индивидуаль ысул, манера (мәс., *Тукай шигырьләре стиле* һ.б.)

**СТРАДАТЕЛЬНАЯ ФОРМА ГЛАГОЛА** ФИГЫЛЬНЕҢ ТӨШЕМ ЮНӘЛЕШЕ *к.* **страдательный залог**

**СТРАДАТЕЛЬНЫЙ ЗАЛОГ** ТӨШЕМ ЮНӘЛЕШЕ Эшнең логик объект тарафыннан үтәлүен белдерә торган фигыль формасы; *-ыл, -ел, -л, -ын, -ен, -н* кушымчалары ярдәмендә ясала (мәс., *язылa, укыла, карала* һ.б.)

**СТРОЕВЫЕ ЕДИНИЦЫ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕ ТӨЗҮЧЕ БЕРӘМЛЕКЛӘР Номинатив һәм коммуникатив берәмлекләрне төзү өчен хезмәт итә торган чаралар (фонемалар, морфемалар)

**СТРОКА** ЮЛ Язуда хәреф һәм сүзләрдән тезелеп барган тезем

**СТРОЧНАЯ (МАЛЕНЬКАЯ) БУКВА** ЮЛ ХӘРЕФЕ (КЕЧКЕНӘ ХӘРЕФ) Баш хәрефне куллану очракларыннан тыш һәрвакытта кулланыла торган гадәттәге зурлыктагы хәреф

**СТРУКТУРА** СТРУКТУРА, ТӨЗЕЛЕШ Махсус төзелеш схемасы булган лексик-грамматик бердәмлек

**СТРУКТУРАЛИЗМ** СТРУКТУРАЛИЗМ Тел белеменең телне саф билгеләр системасы дип карый, аны синхроник өйрәнүне беренче урынга куя, телне тикшерүнең объектив методларын эзли, лингвистик тикшеренүне формальләштерә торган юнәлеше; структурализм нигезендә өч мәктәп формалашкан: Прага лингвистика мәктәбе (функциональ лингвистика), Копенгаген лингвистика мәктәбе (глоссематика), Америка лингвистика мәктәбе (дескриптив лингвистика)

**СТРУКТУРНАЯ ЛИНГВИСТИКА** СТРУКТУР ЛИНГВИСТИКА Прага лингвистика түгәрәге, глоссематика, дескриптив лингвистикаларының гомуми атамасы. Тел берәмлекләре арасындагы структур мөнәсәбәтләрне төгәл тасвирлау ысулы белән өйрәнә

**СТРУКТУРНАЯ СХЕМА ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘНЕҢ СТРУКТУР СХЕМАСЫ Җәенке булмаган (элементар, гади) җөмлә төзү өчен синтаксик үрнәк

**СТРУКТУРНОЕ ЯЗЫКОЗНАНИЕ** СТРУКТУР ТЕЛ БЕЛЕМЕ (ГЫЙЛЕМЕ) Тел белеменең фонетика, фонология, лексикология, семасиология, сүзьясалышы, морфология, синтаксис кергән өлкәсе

**СТРУКТУРНО-СЕМАНТИЧЕСКИЕ КАЛЬКИ** СТРУКТУР-СЕМАНТИК КАЛЬКАЛАР Чит тел сүзенең морфологик төзелеше сакланган калькалар: *животноводство – терлек-челек, единство – бердәм-лек, ледокол – бозваткыч, хладнокровный – салкын канлы, рукопись – кулъязма* һ.б.

**СТРУКТУРНО-СЕМАНТИЧЕСКИЙ МЕТОД** СТРУКТУР-СЕМАНТИК АЛЫМ Җөмлә модельләрен билгеләгәндә ия, хәбәр, тәмамлык, хәл, аергыч кебек кисәкләргә игътибар итмәстән, турыдан-туры аларның формалары (структуралары) һәм эчтәлекләре (семантикалары) белән эш итә торган алым

**СТРУКТУРНЫЕ ЭЛЕМЕНТЫ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ СТРУКТУР ЭЛЕМЕНТЛАРЫ Тел системасын тәшкил итә торган элементлар

**СТРУКТУРНЫЙ АСПЕКТ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘНЕҢ СТРУКТУР АСПЕКТЫ Җөмлә үз төзелешендә каралу һәм аның оешуында формаль билгеләрне ачыклану: баш кисәкләрнең белдерелүен һәм җөмләнең моделен (калыбын) билгеләү

**СТРУКТУРНЫЙ МЕТОД В ЯЗЫКОЗНАНИИ** ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ (ГЫЙЛЕМЕНДӘ) СТРУКТУР МЕТОД, АЛЫМ Телне бербөтен буларак өйрәнә, тел элементлары арасындагы мөнәсәбәтләрне, бәйләнешләрне тикшерә торган алым

**СУБОРДИНАТИВНАЯ СВЯЗЬ СЛОВ** СҮЗЛӘРНЕҢ СУБОРДИНАТИВ БӘЙЛӘНЕШЕ *к.* **подчинительная связь**

**СУБСТАНТИВ** СУБСТАНТИВ *к.* **имя существительное**

**СУБСТАНТИВАТ** СУБСТАНТИВАТ Субстантивация нәтиҗәсендә исемләшкән сүз (мәс., *көтү, сайлау, буяу, язу* һ.б.)

**СУБСТАНТИВАЦИЯ** ИСЕМЛӘШҮ Башка сүз төркемнәренә караган сүзләрнең исем сүз төркеменә күчүе

**СУБСТИТУЦИЯ ЗВУКОВ** АВАЗЛАР СУБСТИТУЦИЯСЕ, АВАЗЛАР АЛМАШУЫ, АВАЗЛАР АЛМАШТЫРЫЛУЫ Гадәттә алынма сүзләрдә чит авазның туган телдәге шуңа охшаш аваз белән алмаштырылуы (мәс., *цыган – чегән, церковь - чиркәү, хрен – керән* һ.б.)

**СУБСТРАТ** СУБСТРАТ Бер территориядә ике тел очрашканда җирле халык теленең җиңгән телгә ясаган тәэсире, шул телдә сакланган эзләре

**СУБЪЕКТ** СУБЪЕКТ Процессның үтәүчесе, җөмләнең иясе

**СУБЪЕКТ РЕЧИ** СӨЙЛӘМ СУБЪЕКТЫ (СӨЙЛӘҮЧЕ) Диалогны оештыручы һәм аның нәтиҗәсе белән кызыксынучы кеше

**СУЖЕНИЕ ЗНАЧЕНИЯ** МӘГЪНӘ ТАРАЮ Сүзнең кайбер мәгънәләре кулланыштан төшеп калу, архаиклашу

**СУПЕРСЕГМЕНТ** СУПЕРСЕГМЕНТ *к.* **просодия**

**СУПЕРСЕГМЕНТНЫЕ ЕДИНИЦЫ** СУПЕРСЕГМЕНТ БЕРӘМЛЕКЛӘР Аваз һәм иҗекләрдән зуррак булган сүз һәм фразаларны характерлый торган берәмлекләр

**СУПЕРСТРАТ** СУПЕРСТРАТ Җирле халыкның теленә кушылып, анда югалып, эреп юкка чыккан, ләкин җирле телдә элементларын саклап калган тел

**СУППЛЕТИВИЗМ** СУППЛЕТИВИЗМ Бер үк лексик мәгънәгә ия булган сүзләрнең аерым грамматик формаларын төрле тамырдан ясалган сүзләр белән белдерүдән гыйбарәт грамматик чараларның бер төре (мәс., *человек - люди*)

**СУФФИКС** СУФФИКС Сүзнең тамырыннан соң килә, яңа сүзләр яки сүзләрнең яңа төрләрен ясый торган кушымча (сүзьясагыч һәм төр ясагыч кушымчаларга бүленә)

**СУФФИКСАЛЬНОЕ СЛОВООБРАЗОВАНИЕ** КУШЫМЧАЛАУ ЫСУЛЫ БЕЛӘН СҮЗЬЯСАЛЫШЫ *к.* **суффиксальный способ**

**СУФФИКСАЛЬНЫЙ СПОСОБ** КУШЫМЧАЛАУ ЫСУЛЫ Сүзьясалыш типларына ярашлы рәвештә сүзьясагыч кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясау ысулы (мәс., *гүзәл + лек, терлек + че, каен + лык, өй + дәш* һ.б.)

**СУФФИКСАЛЬНЫЕ СЛОВА** КУШЫМЧАЛЫ СҮЗЛӘР Берәр тамыр сүздән (тамырдан) суффикслар (кушымчалар) ярдәмендә ясалып, яңа лексик мәгънә белдергән сүзләр (мәс., *эш + че, эш + чән, эш + лә, эш + лекле*)

**СУФФИКСАЦИЯ** СУФФИКСАЦИЯ, КУШЫМЧАЛАУ *к.* **суффиксальный способ**

**СУФФИКСЫ КАТЕГОРИИ СРАВНЕНИЯ** ЧАГЫШТЫРУ КУШЫМЧАЛАРЫ Предметта билгенең уртача дәрәҗәдән артыграк булуын белдергән кушымчалар

**СУЩЕСТВИТЕЛЬНОЕ** ИСЕМ Әйләнә-тирәдәге җан ияләрен, предметларны, күренешләрне, вакыйгаларны һәм төшенчәләрне белдерә торган сүз төркеме; гомуми лексик мәгънәләреннән чыгып, күмәклек *(ат, кеше, агач)* һәм ялгызлык *(Казан, Идел, Диләрә)* исемнәргә, конкрет *(өстәл, савыт, чаңгы),* җыйма *(бала-чага, савыт-саба, дус-иш)* һәм абстракт *(җәмгыять, сыйныф, эшчәнлек)* исемнәргә бүленәләр

**СХЕМЫ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘ СХЕМАЛАРЫ *к.* **модели предложения**

**СЦЕНИЧЕСКАЯ РЕЧЬ** СӘХНӘ СӨЙЛӘМЕ Актёрның сөйләм осталыгы; профессиональ эшкәртелгән сөйләм техникасы чаралары ярдәмендә сәнгать идеяләрен гәүдәләндерүе

**СЧЁТНЫЕ СЛОВА (НУМЕРАТИВЫ)** САН АЧЫКЛАГЫЧЛАРЫ (НУМЕРАТИВ СҮЗЛӘР) Сан белән исем (аергыч белән аерылмыш) арасында килә торган сүзләр (мәс., *биш <u>баш</u> сарык, өч <u>яшлек</u> кыз, ике <u>пар</u> башмак, бер <u>чакрым</u> юл, алты <u>пот</u> бодай, бер <u>саплам</u> җеп* һ.б.)

# Т

**ТАБУ** ТАБУ Төрле ышанулар, ырымнар нигезендә сөйләмдә кулланылмый яки яшереп әйтелә торган, тыелган сүзләр

**ТАВТОЛОГИЯ** ТАВТОЛОГИЯ Сөйләмдә яки язуда бер үк сүзне яки сүзтезмәне урынсыз яки стилистик максатларда махсус кабат куллану

**ТАГМЕМА** ТАГМЕМА Җөмлә дәрәҗәсендә кисәкләргә бүленүнең иң кечкенә берәмлеге

**ТАЗИС, ТАСИС** ТАЗИС, ТАСИС Яңгырашы күңелгә ятышлы булган сүз яки фразаларны кабатлау

**ТАЙНЫЕ ЯЗЫКИ** ЯШЕРЕН ТЕЛЛӘР Аерым социаль төркемнәрнең яшерен сөйләшү максатыннан булдырылган ясалма телләре

**ТАКСЕМА** ТАКСЕМА Синтаксик төзелеш берәмлеге

**ТАКСИС** ТАКСИС Эш-хәрәкәтләр арасындагы вакыт мөнәсәбәтләрен (эзлеклелек, бер вакытта булганлык, төп һәм ярдәмче эшләр) белдергән тел категориясе

**ТАКСОНОМИЯ** ТАКСОНОМИЯ Лингвистик объектларны классификацияләү принциплары һәм классификация үзе

**ТАКТ** ТАКТ Сөйләмне ритм һәм интонацион яктан аеру берәмлеге

**ТАКТОВОЕ УДАРЕНИЕ** ТАКТ БАСЫМЫ Синтагма эчендә мөһимрәк мәгънәле сүзне сөйләмдә аеру

**ТАТАРИЗМЫ** ТАТАРИЗМНАР Башка телләргә татар теленнән алынган сүзләр

**ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК** ТАТАР ТЕЛЕ Төрки телләр семьялыгының кыпчак группасына караган, өч – урта, көнчыгыш, көнбатыш диалектлары булган, Татарстан, Башкортстан һ.б. территорияләрдә таралган телләрнең берсе, татар халкының туган теле

**ТВЕРДАЯ ОСНОВА** КАЛЫН НИГЕЗ Калын тартыкка тәмамланган нигез

**ТВЁРДЫЕ СОГЛАСНЫЕ** КАЛЫН ТАРТЫКЛАР Тел авыз куышлыгының арткы өлешендә булганда барлыкка килә торган тартыклар

**ТВЕРДОНЁБНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** КАТЫ АҢКАУ ТАРТЫКЛАРЫ Йомшак әйтелешле тел алды тартыклары, палаталь тартыклар

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ ВРЕМЕНИ** ВАКЫТНЫ БЕЛДЕРГӘН ТӨШЕМ КИЛЕШЕ Эшнең үтәлү, билгенең барлыкка килү вакытын белдерә торган килеш (мәс., *утром*, *осенью*)

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ ИНСТРУМЕНТАЛЬНЫЙ** КОРАЛ КИЛЕШЕ Эшне үтәүдә кулланылган коралны белдерә торган килеш (мәс., *есть ложкой, писать ручкой*)

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ КОЛИЧЕСТВА** САН КИЛЕШЕ Эшне башкару ысулын сан ягыннан характерлый торган килеш (мәс., *раздавать конфеты горстями*)

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ ОБРАЗА И СПОСОБА ДЕЙСТВИЯ** ЭШНЕҢ ЫСУЛЫН, ҮТӘЛҮ РӘВЕШЕН БЕЛДЕРГӘН ТӨШЕМ КИЛЕШЕ Эш яки процесска сыйфат характеристикасы бирә торган килеш

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ ОБЪЕКТА** ОБЪЕКТ КИЛЕШЕ Объектка күрсәтә, шуңа ишарәли торган килеш

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ ОГРАНИЧЕНИЯ** ЧИКЛӘҮ КИЛЕШЕ Теге яки бу билгенең өлешчә чагылышын күрсәтә торган килеш

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ ПАДЕЖ** ТӨШЕМ КИЛЕШЕ Фигыль, исем, сыйфат белән яраклаша һәм субъект, объект, вакыт һ.б. мәгънәләрне белдерә торган килеш формасы

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ ПОЛУПРЕДИКАТИВНЫЙ** ЯРЫМПРЕДИКАТИВ ТӨШЕМ КИЛЕШЕ Яшь аралыгын яисә теге яки бу торышта булу вакытын белдерә торган килеш

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ ПРЕДИКАТИВНЫЙ** ПРЕДИКАТИВ ТӨШЕМ КИЛЕШЕ Тезмә хәбәрләрдә исем өлешен аңлата торган килеш

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ ПРИЗНАКА** БИЛГЕ КИЛЕШЕ Кемдер тарафыннан барлыкка китерелгән сыйфатны аңлата торган килеш

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ ПРОИЗВОДИТЕЛЯ ДЕЙСТВИЯ** ЭШНЕ БАШКАРУЧЫ ЗАТНЫ БЕЛДЕРГӘН ТӨШЕМ КИЛЕШЕ Иясез конструкцияләрдә яки төшем килешле әйләнмәләрдә субъектка күрсәтә торган килеш

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ ПУТИ** ЮЛНЫ БЕЛДЕРГӘН ТӨШЕМ КИЛЕШЕ Хәрәкәт, эш булган урынны белдерә торган килеш (мәс., *идти тропинкой*)

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ СОДЕРЖАНИЯ** ЭЧТӘЛЕКНЕ БЕЛДЕРГӘН ТӨШЕМ КИЛЕШЕ Объектка яисә эшнең таралу өлкәсенә күрсәтеп, фигыльгә төгәллек бирә торган килеш

**ТВОРИТЕЛЬНЫЙ СРАВНЕНИЯ** ЧАГЫШТЫРУ КИЛЕШЕ Эшнең үтәлү дәрәҗәсе яки характерына күрсәтә торган килеш

**ТЕЗАУРУС** ТЕЗАУРУС 1) Телдәге барлык сүзләрне туплаган сүзлек, аерым телнең тулы сүзлеге; 2) Сүзләргә төрле яклап, мөмкин булганча тулы характеристика бирә торган сүзлек

**ТЕКСТ** ТЕКСТ Сөйләмнең мәгънәви, логик, коммуникатив, структур-грамматик, интонацион яктан оешкан иң зур берәмлеге

**ТЕКСТОВАЯ КАТЕГОРИЯ** ТЕКСТ КАТЕГОРИЯСЕ Бербөтен текст мәгънәсенең билгеле бер өлешен телнең, сөйләмнең, текстның төрле чаралары ярдәмендә чагылдыру билгесе (бөтенлек, төгәлләнгәнлек, бәйләнгәнлек)

**ТЕМА I** ТЕМА Җөмләнең тыңлаучыга инде таныш төшенчәләрне белдерә торган актуаль кисәге

**ТЕМА II** ТЕМА 1) *к.* **основа**; 2) Һинд-европа тел белемендә: -о га тәмаланып, -е- белән чиратлаша торган фигыль нигез; *к.* **тематическая гласная**

**ТЕМАТИЧЕСКАЯ ГЛАСНАЯ** ТЕМАТИК СУЗЫК (АВАЗ) Тамырны инфинитив суффиксы белән тоташтыра торган сузык

**ТЕМАТИЧЕСКАЯ ГРУППА** ТЕМАТИК ТӨРКЕМ Лексик -семантик мөнәсәбәтләргә нигезләнеп түгел, предметларның, күренешләрнең үзләрен билгеле бер уртак сыйфатларыннан чыгып берләштерү, төркемләү

**ТЕМБР** ТЕМБР Өстәмә төсмерләр исәбенә тавышның үзгәрүе, сөйләмнең характерлы бизәге

**ТЕМП** ТЕМП Аерым сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең билгеле бер вакыт аралыгында тиз һәм әкрен әйтелешенең чиратлашуы

**ТЕМПОРАЛЬНОСТЬ** ТЕМПОРАЛЬЛЕК Заманга караганлык һәм заманнар системасы

**ТЕМПОРАЛЬНЫЕ ОТНОШЕНИЯ** ТЕМПОРАЛЬ МӨНӘСӘБӘТЛӘР Вакыт мөнәсәбәтләре

**ТЕОРИЯ ТРУДОВЫХ ВЫКРИКОВ** ХЕЗМӘТ ТАВЫШЛАРЫ ТЕОРИЯСЕ Фикерләү һәм эш бер-берсеннән аерылгысыз, эшләү барышында чыккан тавышлар әкренләп хезмәт процессының символына әйләнеп киткән, тел шулай барлыкка килгән дигән фикерләрне чагылдырган иҗтимагый теория

**ТЕРМИН** ТЕРМИН Фән, техника, сәнгать өлкәсенә караган төшенчәләрне төгәл, конкрет белдергән сүз яки сүзтезмә

**ТЕРМИНИРОВАННЫЙ** ТЕРМИНЛАШКАН, ТЕРМИНЛАШТЫРЫЛГАН 1) Фәнни терминнар, формулалар белән бирелгән; махсус терминнар күп булган; 2) Термин итеп кабул ителгән

**ТЕРМИНОЛОГИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ** ТЕРМИНОЛОГИК СҮЗЛЕК, ТЕРМИННАР СҮЗЛЕГЕ Теге яки бу фән, техника өлкәсенә караган махсус атамаларны туплап биргән сүзлек

**ТЕРМИНОЛОГИЧЕСКОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ТЕРМИНОЛОГИК МӘГЪНӘ Сүзнең термин буларак мәгънәсе

**ТЕРМИНОЛОГИЯ** ТЕРМИНОЛОГИЯ 1) Билгеле бер өлкәгә караган терминнар җыелмасы; 2) Терминнарны өйрәнә торган тел белеме тармагы

**ТЕХНИЦИЗМ** ТЕХНИЦИЗМ Техника өлкәсендәге махсус термин

**ТИЛЬДА** ТИЛЬДА Гадәттә сүзлекләрдә кабатланган сүзне күрсәтү өчен кулланыла торган кыска дулкынсыман диакритик билге (~)

**ТИП ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘ ТИБЫ Җөмләнең структур-семантик төре

**ТИП СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** СҮЗТЕЗМӘ ТИБЫ Сүзтезмәнең структур-семантик төре

**ТИП ЯЗЫКА** ТЕЛ ТИБЫ Аерым телләрнең структурасы һәм типологик классификациясе турында гомуми күзаллау

**ТИПОЛОГИЧЕСКАЯ КЛАССИФИКАЦИЯ ЯЗЫКОВ** ТЕЛЛӘРНЕҢ ТИПОЛОГИК КЛАССИФИКАЦИЯСЕ Телләрне аларның грамматик төзелешендәге охшашлыгы һәм аерымлыгыннан чыгып, телнең тибын билгеләү максатыннан төркемләү

**ТИПОЛОГИЧЕСКОЕ ЯЗЫКОЗНАНИЕ** ТИПОЛОГИК ТЕЛ БЕЛЕМЕ (ГЫЙЛЕМЕ) *к.* **типология 1**

**ТИПОЛОГИЯ** ТИПОЛОГИЯ 1) Тел белеменең телләрне типологик классификацияләү принципларын, ысулларын өйрәнә торган тармагы; 2) Нинди дә булса билгеләрнең уртаклыгы нигезендә тел берәмлекләрен классификацияләү

**ТИПЫ СПРЯЖЕНИЯ** СПРЯЖЕНИЕ ТИПЛАРЫ Гади хәзерге һәм киләчәк заманның зат кушымчалары белән аерылып торган төрләре

**ТИРЕ** СЫЗЫК Җөмләдә махсус очракларда куела торган тыныш билгесе (–)

**ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ** АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕК Сүзнең мәгънәләренә аңлатма бирелгән сүзлек

**ТОН** ТОН Киеренке хәлдәге тавыш ярыларының ритмлы тирбәнеш ешлыгы белән билгеләнгән авазның физик сыйфаты

**ТОНАЛЬНАЯ ТЕОРИЯ** ТОНАЛЬ ТЕОРИЯ Иҗек ясалуда тавышның (тонның) ролен иң беренче планга куйган, иҗек тонның өзелүе яки аның активлыгы кимү нәтиҗәсендә ясалган монолит сөйләм кисәге дип караган теория

**ТОНАЛЬНОЕ СОЕДИНЕНИЕ** ТОНАЛЬ КУШЫЛУ Ритмик-интонацион төркемнәрнең кушылуы

**ТОНЕМА** ТОНЕМА 1) Тон югарылыгының семасиологик релевант берәмлеге; 2) Сөйләмнең мелодик берәмлеге; 3) Акцент чиратлашу очрагы

**ТОНЕТИКА** ТОНЕТИКА Фонетиканың сөйләмнең мелодик берәмлекләрен өйрәнә торган тармагы

**ТОНИЧЕСКОЕ УДАРЕНИЕ** ТОН БАСЫМЫ Басымлы иҗекнең басымсызларыннан тон югарылыгы, аерым бер көй белән аерылып торуы

**ТОНКИЕ СОГЛАСНЫЕ** НӘЗЕК ТАРТЫКЛАР Саңгырау, әйтелеш алдыннан киң итеп сулыш алмый ясалган тартыклар; *к.* **непридыхательные согласные**

**ТОПОНИМ** ТОПОНИМ Географик объектларны белдерә торган ялгызлык исем, нинди дә булса төбәк, урын атамасы

**ТОПОНИМИКА** ТОПОНИМИКА Ономастиканың топонимнарны өйрәнә торган тармагы

**ТОПОНОМАСТИКА** ТОПОНОМАСТИКА Шул ук топонимика

**ТОЧКА** НОКТА Хикәя җөмлә, өндәү белән әйтелмәгән тойгылы җөмлә, кыскартылма сүзләр ахырында куела торган тыныш билгесе (.)

**ТОЧКА С ЗАПЯТОЙ** НОКТАЛЫ ӨТЕР Теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә, иярченле кушма җөмләдә, нык җәенкеләндерелгән тиңдәш кисәкләр арасында куела торган нокта һәм аның астына урнашкан өтердән гыйбарәт тыныш билгесе (;)

**ТОХАРСКАЯ ГРУППА ЯЗЫКОВ** ТОХАР ТЕЛЛӘРЕ ТӨРКЕМЕ Һинд-Европа телләре семьялыгының көнбатыш һәм көнчыгыш тохар телләре (икесе дә үле тел) төркеме

**ТРАДИЦИОННЫЙ ПРИНЦИП ОРФОГРАФИИ** ОРФОГРАФИЯНЕҢ ТРАДИЦИОН ПРИНЦИБЫ Сүзнең бүгенге көн яңгырашын, морфологик төзелешен аңлатып булмаган очракларда традицион язылышны саклау

**ТРАНЗИТИВНЫЕ ГЛАГОЛЫ** ТРАНЗИТИВ ФИГЫЛЬЛӘР *к.* **переходные глаголы**

**ТРАНСКРИПЦИЯ** ТРАНСКРИПЦИЯ Әйтелешне язуда тулысынча күрсәтә торган махсус язу системасы

**ТРАНСЛАТИВ** ТРАНСЛАТИВ Объектның нинди дә булса халәткә күчүен яки билгеле бер сыйфатны алуын күрсәтә торган категориаль килеш формасы

**ТРАНСЛИТЕРАЦИЯ** ТРАНСЛИТЕРАЦИЯ Чит тел сүзләрен туган тел хәрефләре белән язу

**ТРАНСПОЗИЦИОННЫЙ ТИП СЛОВООБРАЗОВАНИЯ** СҮЗЬЯСАЛЫШЫНЫҢ ТРАНСПОЗИЦИОН ТИБЫ Ясаучы һәм ясалма сүзләрнең төрле сүз төркемнәренә караган булуы (мәс., *уку* – фигыль, *укучы* – исем, *петь* – глагол, *певец* – существительное)

**ТРАНСПОЗИЦИЯ** ТРАНСПОЗИЦИЯ 1) Тел бирәмлеген билгеле синтаксик функциядә куллану; 2) Метатеза; 3) Гипотазис

**ТРАНСФОРМ** ТРАНСФОРМ Үзгәртелгән тел структурасы; *к.* **трансформация**

**ТРАНСФОРМАЦИОННЫЙ АНАЛИЗ** ТРАНСФОРМАЦИОН АНАЛИЗ Синтаксик конструкцияләрне билгеләнгән кагыйдәләр буенча үзгәртү

**ТРАНСФОРМАЦИОННЫЙ СИНТАКСИС** ТРАНСФОРМАЦИОН СИНТАКСИС *к.* **структурный синтаксис**

**ТРАНСФОРМАЦИЯ** ТРАНСФОРМАЦИЯ Төп тел моделенең законлы рәвештә икенчел тел структурасы барлыкка китереп үзгәрүе

**ТРИФТОНГ** ТРИФТОНГ Өч сузыклы иҗек

**ТРОП** ТРОП Күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүз яки сүзләр тезмәсе

**ТРЮИЗМ** ТРЮИЗМ Эчтәлеге гомум таныш булган фикер, әйтелгән сүз

**ТУНГУСО-МАНЬЧЖУРСКИЕ ЯЗЫКИ** ТУНГУС-МАНЬЧЖУР ТЕЛЛӘРЕ Алтай телләре семьялыгының эвенк, эвен, маньчжур, нанай, негидаль, удэгэ, орок, солон, ульч телләре кергән төркеме

**ТЮРКИЗМЫ** ТӨРКИ СҮЗЛӘР, ТӨРКИ ЭЛЕМЕНТЛАР Чыгышы белән төрки булган, яки төрки телләрдән алынган сүзләр яки тел элементлары

**ТЮРКОЛОГИЯ** ТЮРКОЛОГИЯ Төрки халыкларның телен, әдәбиятын, фольклорын, мәдәниятен өйрәнә торган гуманитар дисциплиналар комплексы

**ТЮРКСКИЕ ЯЗЫКИ** ТӨРКИ ТЕЛЛӘР Алтай телләренең төрки-монгол тармагына караган угыз, кыпчак һ.б. телләре элементларыннан торган семьялык (төрек, казах, кыргыз, төркмән, үзбәк, каракалпак, уйгыр, татар, башкорт, чуваш, балкар, карачай, кумык, нугай, тыва, хакас, якут, үле – хәзәр, болгар һ.б. телләр керә)

# У

**УВУЛЯРНАЯ (ЗАДНЕЯЗЫЧНАЯ) АССИМИЛЯЦИЯ** КЕЧЕ ТЕЛ (ТЕЛ АРТЫ) АССИМИЛЯЦИЯСЕ Тел арты яки кече тел тартыклары янәшәсендә [н] тартыгының [ң], [ң’] авазы белән чиратлашуы

**УВУЛЯРНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** УВУЛЯР ТАРТЫКЛАР Телнең арткы өлеше кече телгә тию яки якынаю юлы белән ясала торган тартык авазлар

**УГОРСКИЕ ЯЗЫКИ** УГОР ТЕЛЛӘРЕ Урал телләре семьялыгыннан фин-угор тармагына кергән телләр

**УГРО-ФИНСКИЕ ЯЗЫКИ** ФИН-УГОР ТЕЛЛӘРЕ Үзәк һәм Көнчыгыш Европада, шулай ук төньяк-көнбатыш Азиядә яшәүче күп кенә халыклар сөйләшә торган телләр төркеме (венгр, фин, карел, эстон, мордва, мари, удмурд, коми һ.б.)

**УДАРЕНИЕ** БАСЫМ Телнең төрле берәмлекләренә карата сөйләмдә сүздәге иҗекне яки сүзләрнең берсен башкаларыннан көчлерәк итеп әйтү; *к.* **слоговое ударение**, **фразовое ударение**, **логическое ударение**, **эмфатическое ударение**

**УЙГУРСКОЕ ПИСЬМО** УЙГУР ЯЗУЫ Уйгур каганлыгында IX йөз башында барлыкка килгән борынгы уйгур язма әдәби теленең рун алфавитыннан тыш согд һәм аның җиңелләштерелгән вариантындагы (уйгур варианты) язуы, әлифбасы

**УКАЗАТЕЛЬНОЕ МЕСТОИМЕНИЕ** КҮРСӘТҮ АЛМАШЛЫГЫ Күрсәтү, ишарә итү функциясен үти торган алмашлыклар (*бу, шул, андый* һ.б.)

**УКАЗАТЕЛЬНЫЕ ЧАСТИЦЫ** КҮРСӘТҮ КИСӘКЧӘЛӘРЕ Нәрсәгә дә булса күрсәтү, ниндидер фикерне ныгыту, хуплау мәгънәсен белдерә торган кисәкчәләр (мәс., *менә бит, әнә ул* һ.б.)

**УМЕНЬШИТЕЛЬНАЯ СТЕПЕНЬ** КИМЛЕК ДӘРӘҖӘСЕ Әйбердәге билгенең гадәттәгедән кимрәк булуын белдерә торган сыйфат төркемчәсе; грамматик күрсәткече *-сыл/-сел, -су, -гылт/-гелт, -кылт/-келт* һ.б. кушымчалары (мәс., *аксыл, карасу, кызгылт, яшькелт* һ.б.)

**УМЕНЬШИТЕЛЬНО-ЛАСКАТЕЛЬНЫЕ АФФИКСЫ** ИРКӘЛӘҮ-КЕЧЕРӘЙТҮ КУШЫМЧАЛАРЫ Рус телендә: исемнең һәм сыйфатларның иркәләп яки кечерәйтеп әйтелгән төрләрен ясый торган кушымчалар

**УНИВЕРСАЛИИ** УНИВЕРСАЛИЯЛӘР Бөтен телләрдә дә очрый торган (абсолют универсалияләр) яки күпчелек телләрдә очрый торган (статистик универсалияләр) грамматик күренешләр

**УНИВЕРСАЛЬНЫЕ (МНОГОЦЕЛЕВЫЕ) ЯЗЫКИ ПРОГРАММИРОВАНИЯ** УНИВЕРСАЛЬ (КҮП МАКСАТЛЫ) ПРОГРАММАЛАУ ТЕЛЛӘРЕ Гомумән теләсә кайсы өлкәдәге мәсьәләләрне чишү алгоритмнарын яза торган телләр (мәс., *алгол – 68, СИ, ПЛ/Л* һ.б.)

**УНИВЕРСАЛЬНЫЙ СИНТАКСИС** УНИВЕРСАЛЬ СИНТАКСИС Логик юнәлешкә өстенлек биргән синтаксис (универсаль грамматиканың бер тармагы)

**УНИВЕРСОЛОГИЯ** УНИВЕРСОЛОГИЯ Тел белеменең (гыйлеменең) лингвистик универсалияләрны өйрәнә торган тармагы

**УПОДОБИТЕЛЬНО-СРАВНИТЕЛЬНЫЕ НАРЕЧИЯ** ОХШАТУ-ЧАГЫШТЫРУ РӘВЕШЛӘРЕ Процесс, билге һәм предметны икенче процесс, билге, предмет белән чагыштырып ачыклый торган рәвешләр

**УПОДОБЛЕНИЕ** ОХШАШЛАНУ Сөйләмдә бер авазның янәшә килгән икенче авазга охшавы

**УПРАВЛЕНИЕ** БАШКАРЫЛЫШ, БАШКАРЫЛУ, БАШКАРУ Ияртүче сүз ияртүче сүзнең нинди дә булса бер килеш формасын алуын яки берәр бәйлек белән килүен таләп итә торган бәйләнеш; ияртүле бәйләнешнең бер төре

**УРАЛО-АЛТАЙСКАЯ ЯЗЫКОВАЯ ОБЩНОСТЬ** УРАЛ-АЛТАЙ ТЕЛЛӘРЕ БЕРЛЕГЕ Озак вакытлар дәвам иткән контактлар нәтиҗәсендә урал һәм алтай тел гаиләләренең типологик охшашлыклары һәм материаль якынлыклары

**УРАЛЬСКАЯ СЕМЬЯ ЯЗЫКОВ** УРАЛ ТЕЛ СЕМЬЯЛЫГЫ Фин-угор һәм самоед тармакларыннан торган телләр семьялыгы

**УСЕЧЕНИЕ ОСНОВЫ** НИГЕЗ КЫСКАРУ Нигездәге аваз яки авазлар комплексының төшеп калуыннандан гыйбарәт булган морфонологик күренеш

**УСИЛИТЕЛЬНЫЕ ЧАСТИЦЫ** КӨЧӘЙТКЕЧ КИСӘКЧӘЛӘР Сыйфатларда артыклык дәрәҗәсен ясый торган кисәкчәләр: *ап-, зәп-, кып-, сап-, өр-, күм-* һ.б. (мәс., *кып-кызыл, ап-ак, зәп-зәңгәр, сап-сары, өр-яңа, күм-күк* һ.б.)

**УСЛОВНОЕ НАКЛОНЕНИЕ** ШАРТ ФИГЫЛЬ, ШАРТ НАКЛОНЕНИЕСЕ Икенче бер эшнең үтәлүенә шарт булган эш яки хәлне белдерә торган фигыль; фигыль нигезенә *-са/-сә* кушымчасы ялганып (*барса-м, кил-сә, яз-са, бир-сә*), хикәя фигыльгә *икән* модаль сүзе (*бара икән*), үткән заман хикәя фигыльгә *-мы/-ме, исә* кисәкчәләре (*барды исә*) өстәлеп ясала

**УСЛОВНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ШАРТ ҖӨМЛӘ Баш җөмләдә белдерелгән эшнең булу-булмавының шартын белдергән иярчен җөмлә

**УСТАРЕВШИЕ СЛОВА** ИСКЕРГӘН СҮЗЛӘР Актив лексикадан төшеп калган сүзләр; ике төргә бүленәләр: архаизмнар *(утар, язмак, өслүп, шәкел)* һәм тарихи сүзләр *(ясак, алпавыт, тархан, морза, айбалта)*

**УСТНАЯ РЕЧЬ** СӨЙЛӘМ ТЕЛЕ Тавышлы сөйләм; монолог һәм диалог формасында була

**УСТОЙЧИВЫЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** ТОТРЫКЛЫ СҮЗТЕЗМӘЛӘР *к.* **фразеологические словосочетания**

**УСТУПИТЕЛЬНАЯ МОДАЛЬНОСТЬ** КИРЕ ШАРТ ФИГЫЛЬ Җөмләнең нәтиҗә өлешендә белдерелгән эш-хәлнең үтәлү-үтәлмәвенә шарт табылса да, эшнең киресе булуын белдерә торган фигыль

**УСТУПИТЕЛЬНОЕ ПРИДАТОЧНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ИЯРЧЕН КИРЕ ҖӨМЛӘ Баш җөмләнең кире хәле урынында килә яисә андагы мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән кире хәлен ачыклый торган җөмлә

**УТВЕРДИТЕЛЬНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** РАСЛАУ ҖӨМЛӘ Чынбарлыктагы күренешләрне раслый торган җөмлә; *киресе*: инкяр җөмлә

**УТВЕРДИТЕЛЬНЫЕ ЧАСТИЦЫ** РАСЛАУ КИСӘКЧӘЛӘРЕ Нәрсәне дә булса раслау-ныгытуны белдергән кисәкчәләр (мәс., *бит, ич, ла/лә, лабаса/ләбаса*)

**УЧЕНИЕ О ЯЗЫКЕ** ТЕЛ ТУРЫНДАГЫ ӨЙРӘТМӘ *к.* **лингвистика**

## Ф

**ФАЗОВЫЕ ГЛАГОЛЫ** ФАЗАЛЫ ФИГЫЛЬЛӘР Эш яки процессның нинди дә булса фазасын белдергән фигыльләр (мәс., *башлану, туктау, начать, пуститься, продолжать*)

**ФАКТИВ** ФАКТИВ *к.* **транслатив**

**ФАКУЛЬТАТИВНЫЕ ЧЛЕНЫ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘНЕҢ ФАКУЛЬТАТИВ КИСӘКЛӘРЕ Әйтелгәннәргә төгәллек биргән яки киңәйтеп җибәргән кисәкләр

**ФАМИЛЬЯРНАЯ ЛЕКСИКА** ФАМИЛЬЯР ЛЕКСИКА Интим, әдәпсез, тупас, дорфа характердагы көнкүреш лексикасы

**ФАРИНГАЛИЗАЦИЯ** ФАРИНГАЛЬЛӘШҮ 1) Йоткылык стеналарының өстәмә рәвештә кысылуы; 2) Семит, кавказ телләрендә мәгънә аеру өчен хезмәт итә торган фонетик билге

**ФАРИНГАЛЬНЫЙ СОГЛАСНЫЙ** ФАРИНГАЛЬ ТАРТЫК, ЙОТКЫЛЫК ТАРТЫГЫ Йоткылык стеналары тараеп, шуннан көчле итеп һава өреп чыгару юлы белән ясалган тартык (мәс., *h*)

**ФАТИЧЕСКАЯ ФУНКЦИЯ РЕЧИ** СӨЙЛӘМНЕҢ ФАТИК ФУНКЦИЯСЕ Сөйләмнең контакт урнаштыру, аралашуны дәвам итү функциясе

**ФАУКАЛЬНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ФАУКАЛЬ ТАРТЫКЛАР Тамакта ясала торган тартыклар; шартлаулы тартыклар

**ФЕМЕМА** ФЕМЕМА Телнең фонологик һәм морфосинтаксик катламында иң кечкенә дифференциаль берәмлек буларак фонема һәм таксеманың гомуми исеме

**ФИГУРА РЕЧИ** СӨЙЛӘМ ФИГУРАСЫ Сөйләмне образлы итә торган тел чаралары (троплар һәм башка риторик алымнар)

**ФИЗИКО-АКУСТИЧЕСКАЯ СТОРОНА ЗВУКОВ РЕЧИ** СӨЙЛӘМ АВАЗЛАРЫНЫҢ ФИЗИК-АКУСТИК ЯГЫ Сөйләм авазларының ишетелеше

**ФИКСИРОВАННОЕ УДАРЕНИЕ** БЕРКЕТЕЛГӘН БАСЫМ Сүз басымының һәрвакыт бер урында килүе; *к.* **постоянное ударение**

**ФИЛОЛОГИЯ** ФИЛОЛОГИЯ Теле һәм әдәбияты аша берәр халыкның мәдәниятен өйрәнә торган фәннәр җыелмасы

**ФИНАЛЬ** ФИНАЛЬ Иҗекнең ахыргы авазы; *чаг.*: **инициаль, медиаль**

**ФИНИТНЫЙ ГЛАГОЛ** ФИНИТ ФИГЫЛЬ *к.* **личные формы глагола**

**ФИННО-УГОРСКИЕ ЯЗЫКИ** ФИН-УГОР ТЕЛЛӘРЕ Урал телләре семьялыгының Балтика буе-фин (фин, ижора, карел, вепс, эстон, лив, вод), Идел (мари, мордва), Пермь (удмурт, коми-зырян, коми-пермяк), угор (венгр, ханты, манси), саам телләре төркеме

**ФЛЕКСИЯ** ФЛЕКСИЯ 1) Тамырга кушымчалар ялгану, тамыр һәм аффиксның кушылып бетү күренеше; 2) Сүзне төрләндергәндә аның үзгәртә торган кушымчасы

**ФЛЕКТИВНОЕ СЛОВОИЗМЕНЕНИЕ** ФЛЕКТИВ СҮЗ ТӨРЛӘНЕШЕ Сүзнең флексияләр (*2 мәгъ.*) ярдәмендә төрләнеше, бу вакытта грамматик кушымча берничә категориаль форма белдерергә мөмкин

**ФЛЕКТИВНОСТЬ** ФЛЕКТИВЛЫК Грамматик мәгънәне флексия ярдәмендә үзгәртү тенденциясе

**ФЛЕКТИВНЫЕ ЯЗЫКИ** ФЛЕКТИВ ТЕЛЛӘР Эчке һәм тышкы флексияләр файдаланыла, тамыр үзгәрә торган, морфемалар бик нык береккән, кушымчалар берьюлы берничә грамматик мәгънә белдерә торган телләр (мәс., һинд-европа һәм семит-хамит телләре)

**ФЛЕКТИВНЫЙ СТРОЙ** ФЛЕКТИВ ТӨЗЕЛЕШ Флектив морфология өстенлек иткән телләрнең грамматик системасы

**ФОКУС** ФОКУС Сөйләм аппаратында һава агымы үткән юлда тарайган урын, ярык

**ФОНА** ФОНА Сөйләмдә фонемага бәйсез рәвештә аерылып чыгарыла торган дифференциаль дәрәҗәдәге берәмлек

**ФОНАЦИОННОЕ ДЫХАНИЕ** ФОНАЦИОН СУЛЫШ Авазларны әйткәндә тын алу

**ФОНАЦИЯ** ФОНАЦИЯ 1) Аваз ясалуда катнаша торган органнарның бервакыттагы артикуляцияләренең бергә алынуы; 2) Сөйләү

**ФОНЕМА** ФОНЕМА Сүзләрне, морфемаларны төзи торган, аларны бер-берсеннән аерырга мөмкинлек биргән иң кечкенә аваз берәмлеге

**ФОНЕМОБРАЗУЮЩИЙ** ФОНЕМА ЯСЫЙ ТОРГАН Аллофоннарны мөстәкыйль фонема итә торган

**ФОНЕМАТИП** ФОНЕМАТИП Төрле телләрдә уртак артикуляцион үзенчәлекләре һәм авазларны сайлауда охшаш функцияләре булган фонемалар классы

**ФОНЕМАТИЧЕСКИЙ ПРИНЦИП ПРАВОПИСАНИЯ** ДӨРЕС ЯЗУНЫҢ ФОНЕМАТИК ПРИНЦИБЫ Орфографиянең алфавит хәрефләре белән реаль әйтелгән авазлар түгел, ә фонемалар бирелә дип уйланылган принцибы

**ФОНЕМАТИЧЕСКАЯ ТРАНСКРИПЦИЯ** ФОНЕМАТИК ТРАНСКРИПЦИЯ Фонемаларны гына чагылдырган транскрипция

**ФОНЕМНЫЙ РЯД** ФОНЕМАЛАР РӘТЕ Көчле фонеманың аңа эквивалент көчсез фонемалар белән чиратлашуы

**ФОНЕТИКА** ФОНЕТИКА Телнең аваз төзелешен, авазларның ясалу үзенчәлекләрен, аларның акустик билгеләрен, телдәге аваз үзгәрешләрен өйрәнә торган тел белеме тармагы

**ФОНЕТИЧЕСКАЯ ТРАНСКРИПЦИЯ** ФОНЕТИК ТРАНСКРИПЦИЯ Сөйләмнең яңгырашын, ягъни авазларны, аларның төп вариантларын чагылдырган транскрипция

**ФОНЕТИЧЕСКИЕ ИЗМЕНЕНИЯ** ФОНЕТИК ҮЗГӘРЕШЛӘР 1) Тел үсешенең үткән чорларындагы тенденцияләр йогынтысында аваз берәмлекләренең үзгәреше; 2) Авазларның позицион вариантлашуы

**ФОНЕТИЧЕСКИЕ КОРРЕСПОНДЕНЦИИ** ФОНЕТИК КОРРЕСПОНДЕНЦИЯЛӘР Авазларның законлы рәвештә берберсенә туры килүләре

**ФОНЕТИЧЕСКИЙ АРХАИЗМ** ФОНЕТИК АРХАИЗМ Аваз составы ягыннан искергән сүз (мәс., *үлтер* > *үтер*, *угыл* > *ул*)

**ФОНЕТИЧЕСКИЙ ПРИНЦИП** ФОНЕТИК ПРИНЦИП Орфографиянең сүзне ишетелгәнчә язуга нигезләнгән принцибы

**ФОНЕТИЧЕСКИЙ ПРИНЦИП ПРАВИЛ ПЕРЕНОСА** СҮЗНЕ ЮЛДАН-ЮЛГА КҮЧЕРҮНЕҢ ФОНЕТИК ПРИНЦИБЫ Сүзне юлдан-юлга иҗекләргә аерып күчерү

**ФОНЕТИЧЕСКИЕ ЕДИНИЦЫ РЕЧИ** СӨЙЛӘМНЕҢ ФОНЕТИК БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ Сөйләм агымының ритм һәм интонациягә бәйле өлешләре (мәс., фраза, сөйләм такты, фонетик сүз, иҗек, аваз)

**ФОНЕТИЧЕСКОЕ НАПИСАНИЕ** ФОНЕТИК ЯЗУ Сүзләрне яңгыраганча язу

**ФОНЕТИЧЕСКОЕ СЛОВО** ФОНЕТИК СҮЗ Авазлар чылбырының басымсыз ярдәмче сүзләр, кисәкчәләр һәм мөстәкыйль

сүздән торган, бер басым белән әйтелә торган өлеше (*не знал* [*н’иᵉзна′л*])

**ФОНЕТИЧЕСКОЕ СЛОВООБРАЗОВАНИЕ** ФОНЕТИК СҮЗЬЯСАЛЫШЫ Сүздәге төрле аваз үзгәрешләре нәтиҗәсендә яңа сүзләр ясалу (мәс., *хәзер – әзер, тау – дәү*)

**ФОНИКА** ФОНИКА Сөйләмнең яңгыраш ягыннан оештырылышы (тавыш язу, аппаратураны тавыш язу өчен яраклаштыру)

**ФОНОГРАФИЧЕСКАЯ СИСТЕМА ПИСЬМА** ЯЗУНЫҢ ФОНОГРАФИК СИСТЕМАСЫ Аерым бер хәреф аерым бер авазга билге булган язу системасы

**ФОНОГРАФИЯ** ФОНОГРАФИЯ, ФОНЕТИК ЯЗУ Аерым телдәге аваз берәмлекләре билгесен белдергән, яңгырашка нигезләнгән язу; я иҗеккә (иҗек язуы), я авазга (аваз язуы) тигез булган язу

**ФОНОЛОГИЧЕСКАЯ СИСТЕМА ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ ФОНОЛОГИК СИСТЕМАСЫ Телнең мәгънә аеру функциясен үти торган авазлар системасындагы тәңгәллекләр һәм аерымлыклар җыелмасы

**ФОНОЛОГИЧЕСКИЕ ПОЗИЦИИ** ФОНОЛОГИК ПОЗИЦИЯЛӘР Авазның семиологик үзлеген характерлау нигезе буларак аның урыны

**ФОНОЛОГИЯ** ФОНОЛОГИЯ Телдәге фонемалар төзелешен өйрәнә, ягъни авазларны сүзләрнең мәгънәләрен төзү һәм аеру берәмлекләре буларак карый торган тел белеме тармагы

**ФОНОЛОГИЯ СЛОВА** СҮЗ ФОНОЛОГИЯСЕ Фонологиянең тел берәмлеге буларак сүзләрне дифференциацияләү бурычын үти торган фонологик аерымлыкларны өйрәнү тармагы

**ФОНОМОРФОЛОГИЯ** ФОНОМОРФОЛОГИЯ Тел белеменең фонология һәм морфология арасындагы бәйләнешләрне өйрәнә торган тармагы

**ФОНОСЕМАНТИКА** ФОНОСЕМАНТИКА Тел белеменең авазларның символик үзенчәлекләрен өйрәнә торган тармагы

**ФОНОСТИЛИСТИКА** ФОНОСТИЛИСИКА Стилистиканың фонетик чараларның төрле стильләрдә кулланылыш закончалыкларын, сүз һәм сүзтезмәләрне әйтү вариантларында экспрессив үзлекләрне өйрәнә торган бүлеге

**ФОНОТАКТИКА** ФОНОТАКТИКА Сүз яки морфема составындагы төрле позицияләрдә фонемаларның ярашу мөмкинлеген чикли торган кагыйдәләр

**ФОРМА** ФОРМА Тел берәмлегенең материаль ягы

**ФОРМА СЛОВА** СҮЗ ФОРМАСЫ 1) *к.* **грамматическая форма слова**; 2) *к.* **словоформа**; 3) Парадигматик рәттә сүз төрләре

**ФОРМАЛЬНАЯ ГРАММАТИКА** ФОРМАЛЬ (ШӘКЛИ) ГРАММАТИКА Җөмлә эчендә формаль тәкъбирләре булган мөнәсәбәтләрне өйрәнә торган грамматика

**ФОРМАЛЬНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ФОРМАЛЬ МӘГЪНӘ Грамматик мәгънә

**ФОРМАЛЬНЫЕ СЛОВА** ФОРМАЛЬ СҮЗЛӘР Телдә мөстәкыйль кулланыла алмый торган ярдәмлек сүзләр

**ФОРМАЛЬНЫЕ ЯЗЫКИ** ФОРМАЛЬ ТЕЛЛӘР *к.* **флективные языки**

**ФОРМАНТ** ФОРМАНТ 1) Аффикс; 2) Төрләндергеч кушымча белән кушылган суффикс

**ФОРМАНТА** ФОРМАНТА Тавыш резонаторлары аша үткәндә көчәеп киткән тавыш тирбәнешләре

**ФОРМОИЗМЕНЕНИЕ** ФОРМА ТӨРЛӘНЕШЕ Билгеле бер грамматик формада килгән сүзләргә катлаулы төзелешле сүз формасын барлыкка китерә торган кушымчалар ялгану

**ФОРМОИЗМЕНЯЮЩИЕ АФФИКСЫ** ФОРМА ТӨРЛӘНДЕРГЕЧ КУШЫМЧАЛАР Турыдан-туры сүз нигезенә түгел, ә билгеле бер грамматик формада килгән сүзләргә ялганып, катлаулы төзелешле сүз формасын барлыкка китерә торган кушымчалар (мәс., фигыльдә – зат-сан, исемдә – хәбәрлек кушымчалары)

**ФОРМООБРАЗОВАНИЕ** ФОРМА ЯСАЛЫШЫ Форма ясагычлар белән грамматик категорияләр ясалу

**ФОРМООБРАЗУЮЩИЕ АФФИКСЫ** ФОРМА ЯСАГЫЧЛАР, ФОРМА ЯСАГЫЧ АФФИКСЛАР Сүз нигезенә ялганып, аңа грамматик мәгънә өсти, сүз формасы ясый торган кушымчалар (мәс., килеш, тартым, зат-сан, заман, юнәлеш, дәрәҗә һ.б.)

**ФОРМЫ СЛОВОИЗМЕНЕНИЯ** СҮЗНЕҢ ҮЗГӘРЕШ ФОРМАЛАРЫ Сүзтезмәдә, җөмләдә сүзнең башка сүзләргә мөнәсәбәтен белдерә торган формалары

**ФОРМЫ СУЩЕСТВОВАНИЯ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ ЯШӘЕШ ФОРМАЛАРЫ Уртак чыганак материалдан чыгып, табигый рәвештә төрле иерархиядәге төркемнәргә берләшә торган һәм камиллек, универсальлек, кулланыш өлкәсе буенча аерылып торган мөстәкыйль тел структуралары

**ФРАЗА** ФРАЗА Интонация ярдәмендә формалаша торган иң зур фонетик берәмлек, мәгънә ягыннан төгәлләнгән иң кечкенә мөстәкыйль сөйләм берәмлеге

**ФРАЗЕОГРАММА** ФРАЗЕОГРАММА *к.* **фразеологизм**

**ФРАЗЕОЛОГИЗАЦИЯ** ФРАЗЕОЛОГИЗАЦИЯ Сөйләм практикасында тел коллективы материалларының әзер, чагыштырмача тотрыклы тел комплекслары буларак кереп китү һәм стабильләшү процесслары

**ФРАЗЕОЛОГИЗМ** ФРАЗЕОЛОГИЗМ Бердәмлеге, таркалмавы, компонентлары арасында мәҗбүри бәйләнеш булуы, бөтенлеге, сөйләмгә әзер килеш килеп керүләре белән аерылып торган сүзтезмәләр

**ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИ СВЯЗАННОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ФРАЗЕОЛОГИК БӘЙЛЕ МӘГЪНӘ Фразеологизмның тотрыклы берәмлекләре бердәмлегендә генә барлыкка килә торган мәгънәсе

**ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКОЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЕ** ФРАЗЕОЛОГИК СҮЗТЕЗМӘ Кисәкләре арасында реаль мәгънә мөнәсәбәте югалган, компонентлары бөтенлегендә генә атау функциясен башкара торган лексикализацияләнгән сүзтезмә (мәс., *үги ана яфрагы, эт шомырты*)

**ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИЕ СРАЩЕНИЯ** ФРАЗЕОЛОГИК НЫГЫМАЛАР Компонентлары бик нык береккән, аларның мөстәкыйль мәгънәләре тулысынча югалган фразеологизмнар (мәс., *ләчтит сату, трай тибү*)

**ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИЕ ЕДИНСТВА** ФРАЗЕОЛОГИК БЕРДӘМЛЕКЛӘР Аерым компонентларының мәгънәсе аңлашыла торган, аларның туры мәгънәсе бердәмлегеннән күчерелмә мәгънә барлыкка килеп ясалган фразеологизмнар (мәс., *җилгә сарыф итү, ике агач арасында адашу*)

**ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИЕ СОЧЕТАНИЯ** ФРАЗЕОЛОГИК ТЕЗМӘЛӘР Ирекле сүзтезмәләргә якын торган, компонентларының туры мәгънәсе бердәмлегеннән күчерелмә мәгънә барлыкка килүгә нигезләнгән фразеологизмнар

**ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ** ФРАЗЕОЛОГИК СҮЗЛЕК Телдәге фразеологизмнарны туплап бирелгән сүзлек

**ФРАЗЕОЛОГИЯ** ФРАЗЕОЛОГИЯ 1) Лексикологиянең фразеологик берәмлекләрне өйрәнә торган тармагы; 2) Телдәге фразеологизмнар җыелмасы

**ФРАЗОВОЕ УДАРЕНИЕ** ФРАЗА БАСЫМЫ Сөйләмнең мәгънә ягыннан әһәмиятлерәк берәр тактын (синтагмасын) башкаларыннан аерып әйтү

**ФРАКТАЛЫ** ФРАКТАЛЛАР Масштаблы инвариантлыгы булган күплекләр

**ФРАТРИАЛЬНЫЙ** ФРАТРИАЛЬ Туганлык атамаларына караган

**ФРАТРИИ** ФРАТРИЯЛӘР Туганлык атамалары

**ФРЕЙМ** ФРЕЙМ Когнитив лингвистикада һәм лингвокультурологиядә: менталь күренешләрнең тел аңында яшәү ысулы; концептны һәм ситуацияне күзаллау моделе

**ФРИКАТИВНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ФРИКАТИВ ТАРТЫКЛАР, ӨРЕЛМӘЛЕ ТАРТЫКЛАР Сөйләм органнары бер-берсенә якын килеп, һава агымы шулар арасындагы ачыклыктан ышкылып чыгу нәтиҗәсендә барлыкка килгән тартыклар (мәс., [*в*], [*ф*], [*ш*], [*з*])

**ФУЗИЯ** ФУЗИЯ Морфемаларның фонемалар составын үзгәртеп кушылулары (мәс., *при-иду* > *приду*)

**ФУНКТИВ** ФУНКТИВ Үзара бәйлелектә булган тел элементлары

**ФУНКЦИОНАЛЬНАЯ ЛИНГВИСТИКА** ФУНКЦИОНАЛЬ ЛИНГВИСТИКА Структур лингвистика базасында барлыкка килгән һәм тел функцияләрен өйрәнүне максат итеп куйган тел белеме тармагы

**ФУНКЦИОНАЛЬНАЯ СТИЛИСТИКА** ФУНКЦИОНАЛЬ СТИЛИСТИКА Стилистиканың әдәби телнең тарихи яктан формалашып җиткән эре сөйләм төрләрен, стильләрне барлыкка китерүче факторларны, функциональ стильләрнең үзара тәэсирен, жанрлар систематикасын өйрәнә торган тармагы

**ФУНКЦИОНАЛЬНО-СЕМАНТИЧЕСКОЕ ПОЛЕ** ФУНКЦИОНАЛЬ СЕМАНТИК КЫР Билгеле бер мәгънәви функция үтәү өчен үзара бәйләнешкә кергән тел чараларының җыелмасы (мәс., фигыльдә заман кыры)

**ФУНКЦИОНАЛЬНО-СМЫСЛОВЫЕ ТИПЫ РЕЧИ** СӨЙЛӘМНЕҢ ФУНКЦИОНАЛЬ МӘГЪНӘЛЕ ТИПЛАРЫ Җөмләләрне катлаулы бербөтен сөйләм итеп оештыруның төп структур схемалары

**ФУНКЦИОНАЛЬНЫЕ СТИЛИ** ФУНКЦИОНАЛЬ СТИЛЬЛӘР Әдәби телнең эшчәнлек төренә, аралашу эчтәлегенә, шартларына, адресатына бәйле рәвештә тарихи яктан формалашкан иң эре сөйләм берәмлеге; телнең функцияләреннән чыгып бүленә торган, эшчәнлекнең теге яки бу өлкәсе белән бәйле стильләр (мәс., публицистика, көнкүреш, эш кәгазьләре стиле)

**ФУНКЦИИ ЯЗЫКА** ТЕЛНЕҢ ФУНКЦИЯЛӘРЕ Телнең кешелек җәмгыятендәге бурычлары, аралашу вакытында төп билгеләренең чагылышы

**ФУТУРУМ** ФУТУРУМ *к.* **будущее время**

# Х

**ХИАЗМ** ХИАЗМ Стилистик фигура; мәгънәне көчәйтеп бирү өчен фразаның бер үк сүзләрен урыннарын алмаштырып кабатлау (мәс., *иң зур хакимлек иткән көч – акча һәм власть, власть һәм акча*)

**ХРИЯ** ХРИЯ Үткен, хикмәтле сүз

**ХРОНОТОП** ХРОНОТОП 1) Вакыт һәм пространство бергәлеге – тел үзенчәлекләренең аерым чорын һәм географик таралышын күрсәтә торган чаралар, берәмлекләр җыелмасы, культурологиядә – концептлар, дөньяның координатлар системасы: фәлсәфә, табигать белемнәре, социология, гуманитар һәм төгәл фәннәрнең мөһим категорияләре; 2) Текст эчендә вакыт һәм пространство мәгънәләре бер-берсен алмаштыра алырлык итеп берләштереп бирелгән комплекслы категория

**ХРОНОТОПИЧЕСКАЯ СОВОКУПНОСТЬ** ХРОНОТОПИК ҖЫЕЛМА Барлыкка килгән сүзләрнең вакыт ягыннан эзлеклелеге һәм лингвогеографик таралышы җыелмасы

**ХУДОЖЕСТВЕННЫЙ СТИЛЬ** МАТУР ӘДӘБИЯТ СТИЛЕ Әдәби нормаларда язу стиле

# Ц

**ЦАМАЙ** ЦАМАЙ Кушит телләренең көньяк-көнбатыш Эфиопиядә таралган варази группасы телләренең берсе

**ЦАХУРСКИЙ ЯЗЫК** ЦАХУР ТЕЛЕ Нах-дагстан телләренең лезгин төркемчәсенә кергән телләрнең берсе

**ЦЕКАНЬЕ** ЦЕЛӘШТЕРҮ Кайбер славян телләрендә йомшак [*д*] һәм [*т*] авазлары урынында [*дзь*] һәм [*ць*] барлыкка килү күренеше (мәс., белорус телендә: *дзень, дзіва, цень, ціхі*)

**ЦЕЛЕВОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** МАКСАТ ҖӨМЛӘ Иярченле кушма җөмләләрдә иярчен максат җөмлә

**ЦЕЛЬНООФОРМЛЕННОСТЬ** БЕРГӘЛЕК, БЕРЛЕК, ТУЛЫЛЫК, ТАРКАТЫЛМАУЧАНЛЫК Сүзнең грамматик**,** фонетик, график тышчасы, формасы бер булу, ягъни кушылып әйтелү, язылу һәм төрләнү, компонентларының урынын алмаштыру (инверсия) һәм өстәмә компонент кертү мөмкин булмау белән характерлана торган төп үзенчәлеге

**ЦЕЛЬНЫЙ** ТАРКАТЫЛМЫЙ ТОРГАН Мәгънәсенә зыян китермичә кечерәк кисәкләргә таркату мөмкин булмаган (тел берәмлеге)

**ЦЕНТРАЛИ (ГЛАСНЫЕ ЦЕНТРАЛИ)** ЦЕНТРАЛЬЛӘР **(**СУЗЫК ЦЕНТРАЛЬЛӘР**)** Иҗек язулы телләрдә иҗекнең фонетик яктан иҗек ясагыч, ә функциясе ягыннан икенче – финал өлешенә караган элементы

**ЦЕПОЧКА АФФИКСОВ** АФФИКСЛАР ЧЫЛБЫРЫ Агглютинатив телләрдә сүзьясагыч һәм төрләндергеч кушымчаларның билгеле тәртиптә бер-бер артлы кушылып килүе, кушымчалар хасил иткән тезем

**ЦЕРЕБРАЛЬНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ЦЕРЕБРАЛЬ ТАРТЫКЛАР Тел сыртының алгы кырые өскә күтәрелеп ясала торган тел алды тартыклары; какуминаль авазлар

**ЦЕРКОВНОСЛАВЯНИЗМЫ** ЧИРКӘҮ СЛАВЯН СҮЗЛӘРЕ Борынгы славян теленнән рус теленә кергән, кайбер фонетик, морфологик һәм семантик үзенчәлекләре белән аерылып торган сүзләр (мәс., *перст, крест, приязнь* һ.б.)

**ЦЕРКОВНОСЛАВЯНСКИЙ ЯЗЫК** ЧИРКӘҮ СЛАВЯН ТЕЛЕ Борынгы славян теле гамәлдәге рус теле белән кушылып (X–XI гас.) барлыкка килгән һәм чиркәү теле, соңрак мәгърифәт теле, китап теле функцияләрен үтәгән тел

**ЦЕЦАУТ** ЦЕЦАУТ Төньяк Америка индеецларының на-дене семьялыгы атапаск группасына караган, хәзерге вакытта юкка чыккан теле

**ЦЗИНПО** ЦЗИНПО Тибет-бирма телләренә караган, Мьянмада һәм Юннаньда таралган тел

**ЦЗЫ** ЦЗЫ Кытай телендә мәгънә йөрткән иң кечкенә кисәк, яңгырауда – иҗеккә, язуда иероглифка туры килә, бездә «бер иҗекле гади сүз», «морфема» мәгънәсендә

**ЦИРКУМФИКСЫ** ЦИРКУМФИКСЛАР, БӘЙЛЕ АФФИКСЛАР (И.А.Мельчук термины) Кайбер телләрдә нигезне берьюлы ике урыннан катлауландырган, ягъни берьюлы ике урынга ялгана торган катлаулы морфемалар. Алар нигез алдына һәм артына, уртасына һәм артына ялганырга мөмкин. Элек алар мөстәкыйль морфемалар дип каралды (мәс., рус. *посаженик, наместник, задонщина* һ.б.)

**ЦИРКУМФЛЕКС** ЦИРКУМФЛЕКС 1) Кайбер телләргә хас булган интонация үзенчәлеге, мәс., литва, баба славян телләре һ.б.; 2) Кайбер телләргә хас булган басым төре, мәс., швед, борынгы грек һ.б.; 3) Диакритик билге төре, мәс., француз телендә озынлыкны белдерә торган билге: *pale* ‘ябылу’, *pâle* ‘төссез’

**ЦОКАНЬЕ** ЦЫЛАШТЫРУ Кайбер диалектларда [*ц*] һәм [*ч*] авазларын аермау күренеше, аларның [*ц*] фонемасы урынында тәңгәл килүе (мәс., тат. *пецән, пыцак*; рус. *курица, цисто*)

**ЦОКАНЬЕ МЯГКОЕ** ЙОМШАК ЦЫЛАШТЫРУ [*Ц*] һәм [*ч*] авазларын йомшак [*ц*] авазы белән алмаштыру күренеше (мәс., рус. *куриц'а, цисто*)

**ЦОКАНЬЕ ТВЕРДОЕ** КАТЫ ЦЫЛАШТЫРУ [*Ц*] һәм [*ч*] авазларын каты [*ц*] авазы белән алмаштыру күренеше (мәс., рус. *курица, цысто*)

**ЦЮЙ** ЦЮЙ Кытай телендә ‘җөмлә’ мәгънәсенә туры килә торган тел берәмлеге

**ЦЯН** ЦЯН Тибет-бирма телләренең көнбатыш гималай группасына караган, Һиндстанда, Непалда һ.б. таралган тел

# Ч

**ЧАСТИ РЕЧИ** СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ Лексик-грамматик мәгънәләре, морфологик билгеләре һәм синтаксик вазифалары уртаклыгына нигезләнеп төркемләнгән иң эре сүз класслары; мөстәкыйль (исем, сан, сыйфат, фигыль, рәвеш, алмашлык) һәм ярдәмлек (теркәгеч, кисәкчә, бәйлек, ымлык, модаль сүзләр) сүз төркемнәренә бүленәләр

**ЧАСТИЧНАЯ АССИМИЛЯЦИЯ** ӨЛЕШЧӘ АССИМИЛЯЦИЯ Сөйләмдә бер авазның күршесендәге икенче бер авазга нинди дә булса бер як белән охшашлануы (мәс., *унбер [умбер]* сүзен әйткәндә ясалу урыны белән охшашлану)

**ЧАСТИЧНАЯ ДИССИМИЛЯЦИЯ** ӨЛЕШЧӘ ДИССИМИЛЯЦИЯ (ОХШАШСЫЗЛАНУ) Өлешчә ассимиляциягә капма-каршы процесс

**ЧАСТИЧНАЯ РЕДУКЦИЯ** ӨЛЕШЧӘ РЕДУКЦИЯ Басымсыз позициядә сузык авазларның кыскарак әйтелүе; күләм редукциясенең бер төре

**ЧАСТИЧНОЕ ЗНАЧЕНИЕ** ӨЛЕШЧӘ МӘГЪНӘ Сүзнең билгеле очракка карата алынган конкрет мәгънәсе

**ЧАСТИЧНОЕ СОГЛАСОВАНИЕ** ӨЛЕШЧӘ ЯРАШУ Ияртүче сүз үзенең формаларын ияртүче сүз формасына карап тулысынча яраштырмау, ягъни ияртүче һәм иярүче сүз икесе дә бер үк төрле грамматик форманы алмау (мәс., *алар килде* дигән җөмләдә ия белән хәбәр затта гына ярашалар, санда ярашмыйлар)

**ЧАСТИЦА** КИСӘКЧӘ Аерым сүз яки җөмләгә мәгънә төсмере өстәп килә торган модаль сүз төркеме

**ЧАСТНАЯ ЛИНГВИСТИКА** ХОСУСЫЙ ТЕЛ БЕЛЕМЕ (ГЫЙЛЕМЕ) *к.* **частное языкознание**

**ЧАСТНАЯ ФОНЕТИКА** ХОСУСЫЙ ФОНЕТИКА Аерым бер телдәге аваз системасын тикшерә торган фән

**ЧАСТНОЕ ЯЗЫКОЗНАНИЕ** ХОСУСЫЙ ТЕЛ БЕЛЕМЕ (ГЫЙЛЕМЕ) Тел белеменең аерым телләрне (мәс., рус, инглиз, кытай һ.б.), кардәш телләр төркемнәрен (мәс., славян, роман, герман һ.б.) яки билгеле бер территориядә яшәүче телләрне (мәс., балканистика) өйрәнә торган тармагы

**ЧАСТОТА** ЕШЛЫК 1) Тел күренешләренең текстта кулланылыш саны; 2) *к.* **высота звука**

**ЧАСТОТА УПОТРЕБЛЕНИЯ** КУЛЛАНЫЛЫШ ЕШЛЫГЫ *к.* **частота (***1 мәгъ.***)**

**ЧАСТОТНЫЙ СЛОВАРЬ** ЕШЛЫК СҮЗЛЕГЕ Сүзләрнең төрле текстларда кабатлану ешлыгын исәпләп, сүзләрнең кулланылыш активлыклары кимү тәртибендә төзелгән сүзлек. Башта – иң актив, еш очрый торган сүзләр, ахырда пассив сүзләр бирелә

**ЧЕРЕДОВАНИЕ ГЛАСНЫХ** СУЗЫКЛАРНЫҢ ЧИРАТЛАШУЫ *к.* **чередование звуков**

**ЧЕРЕДОВАНИЕ ЗВУКОВ** АВАЗЛАР ЧИРАТЛАШУЫ Морфемада бер үк урында торган авазларның төрле очракларда үзара алышынулары (мәс., *ак – агам, сүк – сүгәм, китап – китабым, тап – табам* һ.б.); тарихи, грамматик, фонетик, позицион һ.б. чиратлашулар була

**ЧЕРЕДОВАНИЕ СОГЛАСНЫХ** ТАРТЫКЛАР ЧИРАТЛАШУЫ *к.* **чередование звуков**

**ЧЕРЕДОВАНИЕ ФОНЕМ** ФОНЕМАЛАР ЧИРАТЛАШУЫ Морфологик процесс вакытында бер фонеманың икенче бер фонема белән алмашынуы, чиратлашуыннан гыйбарәт морфонологик күренешләрнең бер төре

**ЧЁРТОЧКА** СЫЗЫКЧА *к.* **дефис**

**ЧИСЛИТЕЛЬНОЕ** САН Предметның санын, микъдарын, данә исәбен белдерә торган сүз төркеме; микъдар саны (*ике, алты, тугыз*), тәртип саны (*беренче, унынчы, бишенче*), бүлем саны (*бишәр, икешәр, сигезәр*), чама саны (*унлап, өч-дүрт, егермеләп*), җыю саны (*бишәү, унау, җидәү*) төркемчәләренә бүленә

**ЧИСЛИТЕЛЬНЫЕ ПРИБЛИЗИТЕЛЬНОГО СЧЁТА** ЧАМА САНЫ Предметларны якынча, чама белән белдерә торган сан (мәс., *бишләп, унсигез-унтугыз, кырыклап* һ.б.)

**ЧИСЛИТЕЛЬНЫЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** САН СҮЗТЕЗМӘЛӘР Төп (ияртүче) компонент булып сан килә торган сүзтезмәләр (мәс., *уртадан алтынчы, укучылардан бишәү, бу кыз белән ике* һ.б.)

**ЧИСЛО** САН Исем, алмашлык, фигыль сүз төркемнәренә хас булган лексик-грамматик категория; берлек һәм күплек саннар

**ЧИСТО ЛЕКСИЧЕСКИЕ ОМОНИМЫ** САФ ЛЕКСИК ОМОНИМНАР Теләсә нинди фонетик, грамматик шартларда аваз составы ягыннан да, тамыр хәлендә дә бер-берсенә охшаш омонимнар; тамыр омонимнар

**ЧИСТО РЕЛЯЦИОННЫЕ ЯЗЫКИ** САФ РЕЛЯЦИОН ТЕЛЛӘР Җөмләдә синтаксик мөнәсәбәтләр аффикслардан һәм эчке үзгәрешләрдән башка гына белдерелә торган телләр

**ЧИСТОТА РЕЧИ** СӨЙЛӘМНЕҢ САФЛЫГЫ Әдәби телдә аңа чит булган элементларның булмавы

**ЧИСТЫЕ ЗВУКИ** САФ АВАЗЛАР, АВЫЗ АВАЗЛАРЫ Борын авазларыннан башка авазлар

**ЧЛЕНЫ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘ КИСӘКЛӘРЕ Төрле синтаксик мөнәсәбәтләр белдерә һәм үзара билгеле бер синтаксик бәйләнештә тора торган мөстәкыйль сүзләр; баш (ия, хәбәр), иярчен (аергыч, тәмамлык, хәл, аныклагыч) һәм модаль (эндәш сүз, кереш сүз) кисәкләргә бүленә

**ЧЛЕНОРАЗДЕЛЬНАЯ РЕЧЬ** АҢЛАЕШЛЫ СӨЙЛӘМ Аерымачык авазлардан торган сөйләм

**ЧТЕНИЕ** УКУ Хәрефләр яки башка язу билгеләре белән язылган яисә басылган нәрсәне күз белән күреп аңлау, эчтәлеге белән танышу яки тыңлаучылар өчен кычкырып әйтеп бару; сөйләм эшчәнлегенең бер төре

**ЧУЖАЯ РЕЧЬ** ЧИТ СӨЙЛӘМ Автор сөйләменә килеп керә торган башка кеше сөйләме

# Ш

**ША** ША Нигериянең төньягында таралган Көнбатыш Чад телләренең берсе

**ШАБЛОН** ШАБЛОН Гомум кабул ителгән һәм тулысынча, үзгәртелмичә, сукырларча файдаланыла торган үрнәк, эталон

**ШАБЛОННЫЙ** ШАБЛОН Артык еш кулланылып оригинальлеге калмаган, төссезләнгән

**ШАВАНТЕ** ШАВАНТЕ Көньяк Америка индеецларының же семьялыгына караган тел

**ШАРИ-НИЛЬСКАЯ ГРУППА** ШАРИ-НИЛ ГРУППАСЫ Нил-сахара тел семьялыгына караган тел группасы

**ШВА** ШВА Һинд-европа телләрендәге сузыкларның барлыкка килүе һәм үзгәрүе турындагы ларингаль теориядә билгесез башлангыч сузык аваз

**ШЭН** ШЭН Кытай тел белемендә: иҗекнең ике өлешенең беренчесе, төп өлеше – башлангыч тартык

**ШЕПЕЛЯВЫЕ СОГЛАСНЫЕ** САКАУ ТАРТЫКЛАР Кайбер телләрдә өрелмәле тартыкларның тоныграк әйтелеш белән аерылып торган төре

**ШЕПОТНЫЕ ГЛАСНЫЕ** ПЫШЫЛДАУЛЫ СУЗЫКЛАР Тавыш катнашында ясалган сузыклардан чыгарма буларак тавышсыз ясалган сузык авазлар

**ШИЛЬХ** ШИЛЬХ Афразия семьялыгының бәрбәр-ливия тармагына караган төп телләр группасы

**ШИРА-ЮГУРСКИЙ ЯЗЫК** САРЫ УЙГУР ТЕЛЕ (ШИРА-ЮГУР ТЕЛЕ) Монгол телләренең маргиналь төркеменә караган, Кытайның кайбер провинцияләрендә таралган тел

**ШИРОКИЙ КОНТЕКСТ** КИҢ КОНТЕКСТ Сүзтезмә яки җөмлә белән генә чикләнмәгән, шулардан киңрәк контекст. Сүз (сүзтезмә) мәгънәсе абзац, бит, хәтта мәкалә яки китап тулысынча укылгач кына аңлашыла торган контекст

**ШИФТЕРЫ** ШИФТЕРЛАР Сөйләмнең әйтеп бирү акты белән, сөйләүче һәм тыңлаучы белән мөнәсәбәтен белдерә торган элементлары булган категорияләр (Р.О. Якобсон термины)

**ШКАЛА** ШКАЛА Эксперименталь лингвистикада бер күренешне (төшенчәне, сүзне һ.б.) билгеле сыйфатка ия булу-булмау ягыннан балларда бәяләү (мәс., сыйфат юк – 1 балл, сыйфат уртача күләмдә теркәлгән – 3 балл һ.б.)

**ШКАЛА ВОСПРИНИМАЕМОСТИ** КАБУЛ ИТЕЛЕШ ШКАЛАСЫ Сөйләм авазларының ишетелеш, ишетеп кабул ителеш дәрәҗәсен чагылдырган шкала

**ШКАЛА ИНТЕРВАЛЬНАЯ** ИНТЕРВАЛЛЫ ШКАЛА Тикшерену объектларының аермасын саннарда күрсәтеп, аларны үзара чагыштыру мөмкинлеге бирә, компаратив тел белемендә, психолингвистикада кулланыла торган шкала

**ШКАЛА НОМИНАТИВНАЯ (НОМИНАЛЬНАЯ)** НОМИНАТИВ (НОМИНАЛЬ) ШКАЛА Билгенең теге яки бу класска туры килүен билгели торган шкала

**ШКАЛА ОТНОСИТЕЛЬНАЯ** НИСБӘТЛЕ ШКАЛА Тикшерену объектын бәяләнә торган билгенең дәрәҗәсен пропорциональ рәвештә чагылдыра торган шкала

**ШКАЛА ПОРЯДКОВАЯ (ОРДИНАЛЬНАЯ)** ТӘРТИП ШКАЛАСЫ (ОРДИНАЛЬ ШКАЛА) Берәмлекләрне аларның теге яки бу билгесе артыграк – кимрәк булуыннан чыгып төзелгән эзлекле шкала, билгенең үсеше буенча төзелгән шкала

**ШКАЛИРОВАНИЕ** ШКАЛАЛАУ, ШКАЛАГА САЛУ Эксперимент, тәҗрибә нәтиҗәсендә табылган эмпирик мәгълүматны системалаштыру, тикшерү объектын төрле билгеләре буенча шкала белән бәяләүдән гыйбарәт эксперименталь лингвистика алымы (мәс., зурлыкны белдерә торган сүзләрнең мәгънәсен шкалага салу: *зур, дәү, гигант* һ.б.)

**ШКОЛЬНЫЙ СЛОВАРЬ** МӘКТӘП СҮЗЛЕГЕ Күләме, эчтәлеге, материалның бирелеше мәктәптә уку-укыту ихтыяҗларына җавап бирерлек итеп төзелгән сүзлек

**ШТАМПЫ** ШТАМПЛАР Семантик-структур тотрыклылык һәм бер үк формада еш кабатлану белән аерылып торган сөйләм формулалары (мәс., *иҗади уңышлар телим*)

**ШУМ** ШАУ Сөйләм органнарының ритмик булмаган, тәртипсез тирбәнешләре нәтиҗәсендә, һава агымының сөйләм аппаратында ышкылуы, шартлавы аркасында барлыкка килгән акустик эффект

**ШУМНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ШАУЛЫ ТАРТЫКЛАР Акустик яктан караганда бары тик шаудан яки, сонантлардан аермалы буларак, башлыча шаудан торган тартык авазлар (мәс., *т, ш, ф* һ.б.)

# Щ

**ЩЕЛЕВЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ӨРЕЛМӘЛЕ ТАРТЫКЛАР Сөйләм аппаратында тарайган урын (фокус) аша һава өрелеп чыгу юлы белән ясала торган тартык авазлар (мәс., [*с*], [*ш*], [*х*])

**ЩЕЛИННЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ӨРЕЛМӘЛЕ ТАРТЫКЛАР *к.* **щелевые согласные**

**ЩЕЛКАЮЩИЕ СОГЛАСНЫЕ** ЧИЕРТҮЛЕ ТАРТЫКЛАР *к.* **кликс**

# Э

**ЭВОЛЮЦИЯ ЯЗЫКА** ТЕЛ ЭВОЛЮЦИЯСЕ Телнең эчке закончалыклары һәм экстралингвистик факторлар йогынтысында үсеше

**ЭВФЕМИЗМ** ЭВФЕМИЗМ Тупас дип саналган яки тыелган сүзләрне икенче сүз белән йомшаграк, әдәплерәк итеп әйтү (мәс., чукрак – *колакка саграк*)

**ЭКВИВАЛЕНТ** ЭКВИВАЛЕНТ Берәр тел берәмлегенә тиңдәш булырлык икенче тел берәмлеге

**ЭКЗОТИЗМ** ЭКЗОТИЗМ Җирле колоритны тулырак бирү максатында бер телдә икенче бер халык теленнән алынган гореф-гадәт, кием-салым, көнкүреш әйберләренең үзенчәлекле милли атамасы

**ЭКЗОТИЧЕСКАЯ ЛЕКСИКА** ЭКЗОТИК ЛЕКСИКА Сөйләмгә җирле колорит бирә торган үзенчәлекле чит тел сүзләре; экзотизмнар

**ЭКЗОФАЗИЯ** ЭКЗОФАЗИЯ *к.* **внешяя речь**

**ЭКОЛОГИЯ ЯЗЫКА** ТЕЛ ЭКОЛОГИЯСЕ Сөйләм һәм тел культурасы өлкәсендә тел деградациясе һәм сөйләм реабилитациясе мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган юнәлеш, тармак

**ЭКСКУРСИЯ** ЭКСКУРСИЯ Авазны әйтүгә әзерлек этабы; сөйләм органнарының авазны әйтергә әзерлек торышына килүе

**ЭКСПЕРИМЕНТАЛЬНАЯ ФОНЕТИКА** ЭКСПЕРИМЕНТАЛЬ ФОНЕТИКА Фонетиканың авазларны төрле приборлар, аппаратлар кулланып, тәҗрибәләр үткәреп өйрәнә торган тармагы

**ЭКСПЕРИМЕНТАЛЬНЫЕ МЕТОДЫ** ЭКСПЕРИМЕНТАЛЬ МЕТОДЛАР Тел фактларын өйрәнгәндә тикшерүчегә аларны контрольдә тоту, идарә итү мөмкинлеге бирә торган методлар

**ЭКСПИРАТОРНОЕ УДАРЕНИЕ** ЭКСПИРАТОР БАСЫМ Сулыш басымы

**ЭКСПИРАТОРНЫЕ ЗВУКИ** ЭКСПИРАТОР АВАЗЛАР Сулышны көчле чыгару белән әйтелә торган авазлар

**ЭКСПЛОЗИВНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ЭКСПЛОЗИВ ТАРТЫКЛАР *к.* **смычные согласные, взрывные согласные**

**ЭКСПЛОЗИЯ** ЭКСПЛОЗИЯ Теге яки бу йомык тартык авазны әйткәндә һаваның шартлап чыгу моменты

**ЭКСПОЗИЦИЯ** ЭКСПОЗИЦИЯ Сөйләм органнарының авазны әйткәндә бер мизгелгә тукталып алуы

**ЭКСПРЕССИВНОЕ БЕССОЮЗИЕ** ЭКСПРЕССИВ ТЕРКӘГЕЧСЕЗЛЕК Аерым кисәкләре арасындагы теркәгечсез

бәйләнеш стилистик функция үтәгән теркәгечсез синтаксик конструкцияләр

**ЭКСПРЕССИВНОСТЬ** ЭКСПРЕССИВЛЫК Тел һәм сөйләм берәмлекләренең авторның сөйләм предметына, партнерга, коммуникатив вакыйгага мөнәсәбәтен белдерә торган үзенчәлеге, семантик-стилистик билгеләр

**ЭКСПРЕССИВНЫЕ СЛОВА** ЭКСПРЕССИВ СҮЗЛӘР Тойгылы һәм сәнгатьле сүзләр

**ЭКСПРЕССИВНЫЙ ЯЗЫК** ЭКСПРЕССИВ ТЕЛ Тойгылы һәм сәнгатьле тел

**ЭКСТЕРНАЛАЙЗЕРЫ** ЭКСТЕРНАЛАЙЗЕРЛАР Кешенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерүдә вербаль булмаган чаралар

**ЭКСТРАЛИНГВИСТИЧЕСКИЙ** ЭКСТРАЛИНГВИСТИК Тел яши торган реаль чынбарлыкка караган

**ЭЛИЗИЯ** ЭЛИЗИЯ Бер сүз ахыры белән икенче сүз башында бер төрле сузыклар очрашканда, аларның берсе төшеп калу күренеше (мәс., *бара алмадым – баралмадым*)

**ЭЛЛИПС(ИС)** ЭЛЛИПС(ИС) Җөмләнең җиңел аңлашыла торган кисәген төшереп калдырудан гыйбарәт стилистик фигура

**ЭЛЛИПТИЧЕСКОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ** ЭЛЛИПТИК ҖӨМЛӘ Туры килердәй төгәл вариантлары булмаган, фигыле контекстта «торгызылмас» дәрәҗәдә кыскартылган, төшереп калдырылган җөмлә

**ЭЛЯТИВ** ЭЛЯТИВ Сыйфатның артыклык дәрәҗәсендәге синоним формасы (мәс., *крупнейший деятель, чистейшая ложь*)

**ЭМОТИВНАЯ ФУНКЦИЯ** ЭМОТИВ ФУНКЦИЯ Эмоцияләрне, хисләрне, кичерешләрне, субъектив мөнәсәбәтне белдерү функциясе

**ЭМОТИВНОСТЬ** ЭМОТИВЛЫК *к.* **эмоциональность**

**ЭМОЦИОНАЛЬНАЯ ЛЕКСИКА** ЭМОЦИОНАЛЬ ЛЕКСИКА Төп семантикасы хисләрне белдергән, телдә даими эмоциональ бизәкле дип саналган сүзләр (мәс., тиргәү сүзләре, ымлыклар)

**ЭМОЦИОНАЛЬНАЯ ОКРАСКА** ЭМОЦИОНАЛЬ БИЗӘК Төп семантикадан тыш хисне белдергән өстәмә мәгънә төсмере, бизәк

**ЭМОЦИОНАЛЬНО-СТИЛИСТИЧЕСКАЯ ОКРАСКА** ЭМОЦИОНАЛЬ-СТИЛИСТИК БИЗӘК Тойгыны белдергән, эмоциональ төсмер биргән чара

**ЭМОЦИОНАЛЬНОСТЬ** ЭМОЦИОНАЛЬЛЕК Экспрессивлык категориясенең бер компоненты; телнең, тел берәмлекләренең хис-кичерешләрне адресатка җиткерү, аңлату сыйфаты

**ЭМОЦИОНАЛЬНО-ЭКСПРЕССИВНАЯ ЛЕКСИКА** ЭМОЦИОНАЛЬ-ЭКСПРЕССИВ ЛЕКСИКА Хисләргә, тойгыларга бай булган сүзләр, эмоциональлекне көчәйтә торган чаралар (мәс., *җан кисәгем, алтыным*)

**ЭМОЦИОНАЛЬНЫЕ МЕЖДОМЕТИЯ** ЭМОЦИОНАЛЬ ЫМЛЫКЛАР Сөйләүченең хис-тойгыларын турыдан-туры белдергән ымлыклар (мәс., *ах, ай-яй-яй, эх*)

**ЭМФАЗА** ЭМФАЗА Сөйләмгә экспрессивлык бирү өчен сөйләмнең мәгънәви яктан мөһим кисәген (сүзләр төркемен, сүзне, сүзнең бер өлешен) аерып әйтү

**ЭМФАТИЧЕСКАЯ РЕЧЬ** ЭМФАТИК СӨЙЛӘМ Киеренке рух белән сөйләнгән сәнгатьле сөйләм

**ЭМФАТИЧЕСКОЕ УДАРЕНИЕ** ЭМФАТИК БАСЫМ Берәр сүзне эмоциональ яктан аеру өчен аның интонацион билгесен (озынлыгын, көчен, тембрын) үзгәртү (мәс., *Әй-бә-ә-әт!?*)

**ЭНАНТИОСЕМИЯ** ЭНАНТИОСЕМИЯ Сүзнең бер үк вакытта капма-каршы мәгънәләрне белдерә алу сәләте (мәс., *исле* сүзендә *хуш ис* һәм *яман ис* мәгънәләре бар)

**ЭНКЛИЗА** ЭНКЛИЗА Басымсыз сүзнең басымлы сүзгә ияреп килүе (мәс., *при' смерти*)

**ЭНКЛИТИКА** ЭНКЛИТИКА Үзеннән алдагы сүз исәбенә басымын югалткан тагылма сүз яки кисәкчә (мәс., *барга'ч ук, килгә'ч үк*)

**ЭНЦИКЛОПЕДИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ** ЭНЦИКЛОПЕДИК СҮЗЛЕК Алфавит тәртибендә китерелгән төшенчәләргә һәръяклы тулы мәгълүмат бирелгән сүзлек

**ЭПЕНТЕЗА** ЭПЕНТЕЗА Алынма сүзләрнең башында ике тартык янәшә килгәндә, аларның арасына сузык өстәлү (мәс., *смола – сумала*)

**ЭПЕНТЕТИЧЕСКИЙ ЗВУК** ЭПЕНТЕТИК АВАЗ Генетик яктан ул сүздә булмаган, әмма икенче бер телдә шул сүз эченә кертелгән аваз

**ЭПИГРАФИКА** ЭПИГРАФИКА Кабер ташларындагы язмаларны өйрәнә торган фән

**ЭПИСЕМЕМА** ЭПИСЕМЕМА Синтаксик мәгънәнең иң кечкенә структур берәмлеге

**ЭПИТЕЗА** ЭПИТЕЗА Алынма сүзләрдә, әгәр аның ахырында ике янәшә тартык булса, ахырына сузык аваз өстәлү (мәс., *танк – танк**ы**, Омск – Омск**и***)

**ЭПИТАФИЯ** ЭПИТАФИЯ Кабер ташы язмасы

**ЭПОНИМ** ЭПОНИМ Исеменнән халык, авыл һ.б.ш. атамасы барлыкка килгән зат

**ЭРГАТИВНАЯ ТИПОЛОГИЯ** ЭРГАТИВ ТИПОЛОГИЯ Агентив (эшне тудыручы) белән фактитивны (эшне йөртүче) семантик яктан капма-каршы куюга нигезләнгән телләр типологиясе

**ЭРГАТИВНЫЙ СТРОЙ ПРЕДЛОЖЕНИЯ** ҖӨМЛӘНЕҢ ЭРГАТИВ ТӨЗЕЛЕШЕ Кыек килешнең җөмләдә актив килеш булуы

**ЭСКИМОССКО-АЛЕУТСКИЕ ЯЗЫКИ** ЭСКИМОС-АЛЕУТ ТЕЛЛӘРЕ Шартлы рәвештә палеоазиат телләренә кертелгән, генетик яктан аерымланган, изоляцияләнгән алеут һәм эскимос телләре семьялыгы

**ЭСПЕРАНТО** ЭСПЕРАНТО Л.Л. Заменгоф уйлап тапкан һәм интернациональ лексикага нигезләнгән, тел берәмлекләрен ясауда сүзьясагыч аффикслар зур роль уйнаган халыкара ясалма тел

**ЭСПЕРАНТОЛОГИЯ** ЭСПЕРАНТОЛОГИЯ Интерлингвистиканың эсперанто телен өйрәнә торган тармагы

**ЭТАЛОН** ЭТАЛОН Лингвокультурологиядә: дөньяның образлы үлчәнеше; предметлар, күренешләр, объектларның сыйфатларын һәм билгеләрен үлчи, күрсәтә торган өлге

**ЭТИКЕТНЫЕ МЕЖДОМЕТИЯ** ЭТИКЕТ ЫМЛЫКЛАРЫ Сөйләм этикетында гомумкабул ителгән формулалар (мәс., *очрашканга кадәр, не стоит, спасибо*)

**ЭТИМОЛОГ** ЭТИМОЛОГ Сүзнең килеп чыгышын, үсешен тикшерүче белгеч

**ЭТИМОЛОГИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ** ЭТИМОЛОГИК СҮЗЛЕК Сүзнең тарихы, килеп чыгышы турында мәгълүматлар, төрле фаразлар китерелгән сүзлек

**ЭТИМОЛОГИЯ** ЭТИМОЛОГИЯ 1) Тел гыйлеменең сүзләрнең, морфемаларның килеп чыгу тарихын өйрәнә торган тармагы; 2) Сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнә, билгели торган алымнар җыелмасы; 3) Сүз яки морфеманың килеп чыгышы, тарихы

**ЭТИМОН** ЭТИМОН Сүзнең инде югалган, ләкин махсус ачыклана торган эчке формасы

**ЭТНОГРАФИЗМ** ЭТНОГРАФИЗМ Билгеле бер төбәкнең тормыш-көнкүреш предметларын, гореф-гадәтләрен белдергән диалекталь сүз

**ЭТНОКУЛЬТУРНАЯ ЛЕКСИКА** ЭТНОМӘДӘНИ ЛЕКСИКА Телнең үзенә генә хас дөнья күренешен «барлыкка китергән» лексик берәмлекләр; үзкыйммәтләр доминантасын һәм менталитет үзенчәлекләрен чагылдырган төп сүзләр

**ЭТНОЛИНГВИСТИКА** ЭТНОЛИНГВИСТИКА Тел белеменең төрле халыкларның көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә һ.б. караган тел чараларын, телнең халык мәдәнияте формалашудагы һәм яшәвендәге конструктив ролен, йогынтысын өйрәнә торган тармагы

**ЭТНОНИМ** ЭТНОНИМ Берәр халык, милләт, кабилә, ыруг, милли берләшмәләрнең исеме

**ЭТНОНИМИКА** ЭТНОНИМИКА Ономастиканың этнонимнарның килеп чыгышын, төзелешен, кулланылышын өйрәнә торган бүлеге

**ЭФФЕКТИВНОСТЬ РЕЧИ** СӨЙЛӘМНЕҢ ЭФФЕКТИВЛЫГЫ Сөйләмнең аны барлыкка китергәндә куелган максатларга ни дәрәҗәдә ирешкәнлеге турындагы интеграль үзенчәлеге

# Ю

**ЮАН** ЮАН Тай телләренең көньяк-көнбатыш группасына караган, Кытайның көньягында таралган тел

**ЮГСКИЙ (СЫМСКИЙ) ЯЗЫК** ЮГ ТЕЛЕ Элек кет теленең сым диалекты саналган, енисей телләреннән хәзерге вакытта исән калган берничә телнең бик аз кеше генә сөйләшә торган берсе

**ЮЖНОСЛАВЯНСКИЕ ЯЗЫКИ** КӨНЬЯК СЛАВЯН ТЕЛЛӘРЕ Болгар, серб-хорват, македон, словен телләрен берләштергән, башлыча Балкан ярымутравында таралган славян телләре группасы

**ЮЖНОСУЛАВЕСИЙСКИЕ ЯЗЫКИ** КӨНЬЯК СУЛАВЕСИ ТЕЛЛӘРЕ Австронезия телләренең Индонезиядә, башлыча Сулавеси утравында таралган телләр группасы

**ЮИТСКИЕ ЯЗЫКИ** ЮИТ ТЕЛЛӘРЕ Эскимос семьялыгына караган, Аляска, Нунивак ярымутравында, Св. Лаврентий утравында таралган тел группасы

**ЮКАГИРСКИЙ ЯЗЫК** ЮКАГИР ТЕЛЕ Юкагир-чува семьялыгыннан сакланып калган бердәнбер тел, Якутия һәм Магадан өлкәсендә таралган

**ЮКИ** ЮКИ Төньяк Америка индеецлары телләренең Калифорниядә таралган бер группасы

**ЮМА** ЮМА Төньяк Америка индеецлары телләренең Калифорния һәм Аризонада таралган бер группасы

**ЮНГУР** ЮНГУР Нигер-конго семьялыгының адамава-убанги төркеменә караган тел

**ЮНЬ** ЮНЬ Кытай тел белемендә: иҗекнең ике өлешенең икенче, төп өлешенә – башлангыч тартыкка өстәмә буларак килгән өлеше, рифма

**ЮПИК** ЮПИК *к.* **юитские языки**

**ЮРОК** ЮРОК Төньяк Америка индеецлары телләренең бер группасы

**ЮТО-АЦТЕКСКИЕ ЯЗЫКИ** ЮТА-АЦТЕК ТЕЛЛӘРЕ Төньяк Америка индеецларының АКШта һәм Мексикада таралган телләр семьялыгы

**ЮССИВ** ЮССИВ Рөхсәт итү, юл кую кебек модаль мәгънәләрне белдерә торган фигыль формасы. Татар телендә йөкләтү юнәлеше белән белдерелә

**ЮССИВ-КОГОРТАТИВ** ЮССИВ-КОГОРТАТИВ Фигыльнең кайбер телләргә хас өндәү-үгетләү формасы (мәс., Эфиопиядәге сахо телендә)

# Я

**ЯЗЫК** ТЕЛ 1) Фикерләр, хисләр, теләкләр белдерә торган фонетик, лексик, грамматик чаралар җыелмасы; кешеләрнең иң мөһим аралашу чарасы булган иҗтимагый күренеш; 2) Сөйләмнең стилистик билгеләре белән аерылган бер төре (мәс., сөйләм теле, фәнни тел, шигъри тел һ.б.); 3) Авазларны әйтүдә иң актив катнаша торган сөйләм органы

**ЯЗЫК ЖЕСТОВ** ЫМНАР ТЕЛЕ Кул хәрәкәтләре һәм мимикага нигезләнгән аралашу системасы, ымнар белән аралашу теле; нигездә телсез-чукрак кешеләр куллана; Төньяк Америка, Австралия аборигеннарында кайбер очракларда (траур, аугa бару һ.б.) нормаль сөйләшүчеләр дә кулланалар

**ЯЗЫКИ МИРА** ДӨНЬЯ ТЕЛЛӘРЕ Җир шарында яшәүче һәм кайчандыр яшәгән халыкларның телләре

**ЯЗЫК И МЫШЛЕНИЕ** ТЕЛ ҺӘМ ФИКЕРЛӘҮ Тел фикерләүнең чарасы һәм коралы, фикерләүне формалаштыру

коралы; тел фикерләүдән башка, фикерләү телдән башка була алмый

**ЯЗЫКИ ПРОГРАММИРОВАНИЯ** ПРОГРАММАЛАУ ТЕЛЛӘРЕ Мәгълүматны һәм хисаплау машиналарында аларны эшкәртү алгоритмын (программасын) тасвирлый торган формаль (ясалма) телләр классы. Программалау телләре нигезен алгоритмик телләр (кобол – икътисади мәгълүматларны эшкәртә, фортран – инженерлык һәм фәнни исәпләүләр башкара, алгол-60 – программалауга өйрәтү) тәшкил итә; шулай ук универсаль телләр һәм персональ компьютерлар өчен (бейсик, паскаль) программалау телләре бар

**ЯЗЫК И РЕЧЬ** ТЕЛ ҺӘМ СӨЙЛӘМ Тел үзенең билгеле күләмдәге сүзлек байлыгы, фонетик составы һәм грамматик кагыйдәләре, калыплары белән аралашу өчен әзер корал булып тора. Шул корал (тел) хәрәкәткә килгәч, ягъни ул телдә сөйли башлагач, сөйләм барлыкка килә. Сөйләм – телнең кулланышы

**ЯЗЫК-ИСТОЧНИК** ЧЫГАНАК ТЕЛ 1) Алынма алынган тел; 2) Тәрҗемә ителә торган тел; оригинал теле

**ЯЗЫК КАК ОБЩЕСТВЕННОЕ ЯВЛЕНИЕ** ИҖТИМАГЫЙ КҮРЕНЕШ БУЛАРАК ТЕЛ Тел җәмгыятьтә генә, билгеле бер коллективта гына барлыкка килеп яши ала һәм кешеләр аралашуында иң әһәмиятле чара булып тора; тел җәмгыятькә бәйле, һәм, киресенчә җәмгыять үсеше телгә бәйле

**ЯЗЫК КАК СИСТЕМА** СИСТЕМА БУЛАРАК ТЕЛ Тел системасы – телдә булган билгеләр, мөмкинлекләр, тел нормалары, сөйләмнең чагылышы. Тел – бердәм бербөтен, бер система

**ЯЗЫК КАК СИСТЕМА ЗНАКОВ** ТАМГАЛАР, БИЛГЕЛӘР СИСТЕМАСЫ БУЛАРАК ТЕЛ Билгеле бер рәвештә оешкан, үзара бәйләнештә торган тел берәмлекләренең (элементларының) аерым тамгалар, билгеләр (авазлар, морфемалар, сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләр һ.б.) буларак бер бөтене, системасы

**ЯЗЫКОВАЯ ГЛУХОТА** ТЕЛ САҢГЫРАУЛЫГЫ Башкалар сөйләмен ишетмәү күренеше

**ЯЗЫКОВАЯ КАРТИНА МИРА** ДӨНЬЯНЫҢ ТЕЛ КАРТИНАСЫ Киң таралган фәнни метафора; чынбарлыкны төшенчәләрдә категорияләштерү һәм шулай ук төшенчә булып әверелмәгән эчтәлек, дөньяның этнос өчен мөһим булган өлешләренә игътибар юнәлтү һәм аларны аерып күрсәтүдәге үзенчәлекләр, чынбарлыкны кыйммәт буларак (аксиологик) тамгалау. Дөньяның тел картинасы бер яктан – тел универсалияләре ярдәмендә чагылдырыла торган тел чаралары белән, икенче яктан теге яки бу халыкның дөньяны күрү-аңлавы үзенчәлекләрен беркетүче тел чаралары белән формалаштырыла

**ЯЗЫКОВАЯ ЛИЧНОСТЬ** ТЕЛДӘ ФИКЕРЛӘҮЧЕ ҺӘМ СӨЙЛӘШҮЧЕ ШӘХЕС Үзе сөйләшкән тел анализына нигезләнеп характерланучы, бәяләнүче шәхес

**ЯЗЫКОВАЯ МЕТАФОРА** ТЕЛ МЕТАФОРАСЫ Телдә системалы рәвештә кулланыла торган социаль тәҗрибәне чагылдырган метафоралар (мәс., *зеленый юнец – тәҗрибәсез үсмер* һ.б.)

**ЯЗЫКОВАЯ МОДА** ТЕЛ МОДАСЫ, СӨЙЛӘМ МОДАСЫ Сөйләм зәвыгы белән чиктән тыш кызыксынуга нигезләнгән мода

**ЯЗЫКОВАЯ ПОДГРУППА** ТЕЛЛӘР ТӨРКЕМЧЕГЕ Телләр төркеме эчендә үзара тагын да тыгызрак бәйләнгән төркемчек

**ЯЗЫКОВАЯ ПОЛИТИКА** ТЕЛ СӘЯСӘТЕ Дәүләт сәясәтенең шул дәүләт телен саклау, укыту, пропагандалауга юнәлдерелгән бер юнәлеше

**ЯЗЫКОВАЯ СЕМЬЯ** ТЕЛ СЕМЬЯЛЫГЫ Бөтен кардәш телләрне үзенә берләштергән кардәш телләр берләшмәсе

**ЯЗЫКОВАЯ СИСТЕМА** ТЕЛ СИСТЕМАСЫ Бер табигый телнең үзара тыгыз бәйләнештә һәм төрле мөнәсәбәтләрдә торган тел элементлары җыелмасы; системаның һәр компоненты аерым-аерым түгел, ә системадагы башка компонентларга капма-каршы куелган хәлдә генә яши

**ЯЗЫКОВАЯ СИТУАЦИЯ** ТЕЛ СИТУАЦИЯСЕ Билгеле бер этник төркемдә яки административ территориядәге телләр һәм шул телләрнең вариантлары

**ЯЗЫКОВЕД** ТЕЛ БЕЛГЕЧЕ, ТЕЛ ГАЛИМЕ, ТЕЛЧЕ Аерым телне (телләрне) яки гомумән тел мәсьәләләрен тикшерүче белгеч

**ЯЗЫКОВЕДЕНИЕ** ТЕЛ БЕЛЕМЕ (ГЫЙЛЕМЕ), ЛИНГВИСТИКА *к.* **языкознание**

**ЯЗЫКОВОЕ РОДСТВО** ТЕЛЛӘР КАРДӘШЛЕГЕ Бер уртак телдән килеп чыккан ике яки берничә телнең материаль охшашлыгы, уртаклыгы, якынлыгы (мәс., *тамырлар охшашлыгы*, *уртаклыгы*)

**ЯЗЫКОВОЕ СООБЩЕСТВО** ТЕЛЛӘР БЕРГӘЛЕГЕ Тел белән беррәттән, икътисад һәм мәдәният уртаклыгыннан чыгып берләшкән кешеләр бергәлеге

**ЯЗЫКОВОЙ ВКУС** ТЕЛ ЗӘВЫГЫ, СӨЙЛӘМ ЗӘВЫГЫ Телдә чор үзенчәлекләренә җавап бирә торган сүзләргә өстенлек бирүдән гыйбарәт булган сөйләм культурасы

**ЯЗЫКОВОЙ КОЛЛЕКТИВ** ТЕЛ КОЛЛЕКТИВЫ Бер милләт халкы тәшкил иткән тел коллективы (мәс., рус халкы бер тел коллективы, татар халкы икенче бер тел коллективы хасил итә)

**ЯЗЫКОВОЙ МАТЕРИАЛ** ТЕЛ МАТЕРИАЛЫ Нинди дә булса бер җәмгыять яшәешенең билгеле бер чорындагы сөйләнгәннәрнең һәм аңлашылганнарның җыелмасы

**ЯЗЫКОВОЙ СОЮЗ** ТЕЛЛӘР БЕРЛЕГЕ Бер территориядә озак еллар яшәп кардәш һәм кардәш булмаган телләрнең озак еллар дәвамындагы контакты нәтиҗәсендә лексикада, фонетикада, грамматикада уртак үзлеккә ия булган телләр төркеме (мәс., балкан телләр берлеге, балтик телләр берлеге һ.б.ш.)

**ЯЗЫКОВОЙ СУБСТРАТ** ТЕЛ СУБСТРАТЫ *к.* **субстрат**

**ЯЗЫКОВЫЕ ЕДИНИЦЫ** ТЕЛ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ Эчтәлек белән мәгънә берлеген тәшкил иткән сөйләмнең бер кисәге;

фонетик, морфологик, синтаксик, лексик, фразеологик һ.б. берәмлекләр була

**ЯЗЫКОВЫЕ КОНТАКТЫ** ТЕЛ КОНТАКТЛАРЫ Төрле телдә сөйләшүчеләрнең аралашуы нәтиҗәсендә шул телләрнең бер-берсенә тәэсире, йогынтысы

**ЯЗЫКОВЫЕ НЕОЛОГИЗМЫ** ТЕЛ НЕОЛОГИЗМНАРЫ Еш кына продуктив ысул белән ясалган, сүзлекләрдә теркәлгән, авторы билгесез булган неологизмнар

**ЯЗЫКОВЫЕ СРЕДСТВА НОМИНАЦИИ** НОМИНАЦИЯЛӘҮНЕҢ ТЕЛ ЧАРАЛАРЫ Яңа мәгънә белдерү өчен файдаланыла торган электән билгеле булган тел чаралары

**ЯЗЫКОВЫЕ УНИВЕРСАЛИИ** ТЕЛ УНИВЕРСАЛИЯЛӘРЕ *к.* **универсалии**

**ЯЗЫКОВЫЕ ЭЛЕМЕНТЫ** ТЕЛ ЭЛЕМЕНТЛАРЫ *к.* **языковые единицы**

**ЯЗЫКОЗНАНИЕ** ТЕЛ БЕЛЕМЕ (ГЫЙЛЕМЕ), ЛИНГВИСТИКА Кешеләрнең аралашу чарасы булган телне, андагы күренешләрне һәм законнарны өйрәнә һәм берничә тармактан (фонетика, морфология, синтаксис, лексикология, стилистика, грамматика, орфография, орфоэпия һ.б.) торган фән; хосусый һәм гомуми тел гыйлеме төрләре бар

**ЯЗЫК-ОСНОВА (ОСНОВАНИЕ)** НИГЕЗ ТЕЛ, БАБА ТЕЛ *к.* **праязык**

**ЯЗЫК-ПОСРЕДНИК** АРАДАШЧЫ ТЕЛ 1) Милләтара аралашу теле; 2) Бер телдән икенчесенә алынмалар кергәндә арадашчы ролен үти торган тел

**ЯЗЫК-ЭТАЛОН** ЭТАЛОН ТЕЛ Эталон тел буларак теләсә нинди тел кулланыла (мәс., гадәттә чит тел дәреслекләрендә чит телне тасвирлаганда тел эталоны булып туган тел алына)

**ЯЗЫЧКОВЫЕ СОГЛАСНЫЕ** КЕЧЕ ТЕЛ ТАРТЫКЛАРЫ *к.* **увулярные согласные**

**ЯЗЫЧНЫЕ СОГЛАСНЫЕ** ТЕЛ ТАРТЫКЛАРЫ Тел алды, тел уртасы, тел арты тартыклары

**ЯЗЫЧОК** КЕЧЕ ТЕЛ, УВУЛА Йомшак аңкауның тәмамланган өлеше; кече тел тартыклары (*[к], [г]* һ.б.) артикуляциясендә катнаша торган актив сөйләм органы

**ЯПОНИСТИКА** ЯПОНИСТИКА Япон теле, әдәбияты, мәдәнияте турындагы фән

**ЯПОНСКОЕ ПИСЬМО** ЯПОН ЯЗУЫ Иероглифлар һәм иҗек язуы билгеләреннән торган катнаш язу; идеографик-силлабик язу (япон телендә текстлар язганда кулланыла)

**ЯРЛЫК** ЯРЛЫК Җәмгыять аңында шәхеснең дәрәҗәсен, абруен төшергән, тискәре бәяли торган сыйфатлама (мәс., *экстремист*, *фундаменталист*, *сепаратист, ваһабчы, мөҗәһит, исламчы* һ.б.)

# АЛФАВИТНЫЙ УКАЗАТЕЛЬ ТЕРМИНОВ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

**А**
Аббревиатура а, 9
Аббревиация а, 9
Абессив а, 9
Абзац а, 9
Аблатив а, 9
Аблаут а, 9
Абсолют аергыч а, 9
Абсолют вакыт а, 9
Абсолют проклитика һәм энклитика а, 10
Абсолют синонимнар а, 10
Абсорбция а, 10
Абстракт җөмлә а, 10
Абстракт исемнәр а, 116
Абстракт лексика а, 10
Аваз з, 51
Авазның график билгесе г, 39
Аваз ияртемнәре з, 51
Аваз ияртемнәре теориясе о, 111
Авазлар алмашуы с, 179
Авазлар алмаштырылуы с, 179
Авазлар когеренциясе к, 66
Авазлар конвергенциясе к, 71
Авазларны әйтү органнары о, 114
Авазларның законлы чиратлашуы з, 50
Авазларның комбинатор үзгәрешләре к, 68
Авазларның позицион үзгәрешләре п, 126
Авазларның тарихи чиратлашуы и, 61
Авазларның үзлегеннән үзгәрүләре с, 173
Авазлар системасы з, 51
Авазлар субституциясе с, 179
Авазлар чиратлашуы ч, 204
Авазлар чолганышы с, 169
Авазның көче (интенсивлыгы) с, 148
Аваз тезмәләре з, 52
Аваз тибы з, 51
Аваз төшеп калу в, 31
Аваз үзгәрешләре з, 51
Аваз югарылыгы в, 31
Австроазия телләре семьялыгы а, 10
Австронезия телләре семьялыгы а, 10
Автология а, 10
Автоматик тәрҗемә а, 10
Автоматлаштырылган элемент а, 10
Автоном сүзләр а, 10
Автор неологизмнары а, 57
Автор пунктуациясе а, 11
Автор сөйләме а, 11
Автор сүзләре а, 11
Автосемантик а, 11
Авыз авазлары р, 144
Авыз куышлыгы р, 143
Агглютинатив телләр а, 11
Агглютинация а, 11
Агенс а, 11
Агентив мәгънә а, 11
Адвербиализация а, 11
Адверсатив мәгънә а, 11
Адессив а, 11
Адитив а, 11
Адмератив а, 12
Адстрат а, 12
Адъектив а, 12
Адъективлашу а, 12
Аергыч о, 112
Аергыч мәгънәсе а, 113
Аеру билгесе р, 138
Аеру килеше о, 116
Аерылмыш о, 113
Аерымланган аергычлар о, 103
Аерымланган кисәкләр о, 103
Аерымланган өстәмә сүзләр о, 103
Аерымланган тәмамлыклар о, 103
Аерымланган хәлләр о, 103
Аерымлану о, 103
Аккомодация а, 12
Аккузатив а, 12
Акроним а, 12
Аксионал а, 12
Аксиональ коммуникация а, 12
Актантлар а, 12

Актив лексика а, 12
Актив органнар а, 13
Актив сүзлек а, 13
Актуаль кисәкләр а, 13
Актуаль кисәкләргә бүленеш а, 13
Актуальләшү а, 13
Актум а, 13
Акустик аспект а, 13
Акустик ассимиляция а, 13
Акустик фонетика а, 13
Акцент а, 13
Акцентология а, 14
Алаштыру а, 12
Алгы рәт п, 122
Алгы рәт сузыклары г, 36
Алкушымча п, 132
Аллатив а, 14
Аллегория а, 14
Аллитерация а, 14
Аллолекса а, 14
Аллолог а, 14
Алломорфлар а, 14
Аллосема а, 14
Аллофон а, 14
Алмашлык м, 88
Алмашлык сүзтезмә м, 88
Алогизм а, 14
Алтай телләре а, 14
Алфавит а, 14
Алынма сүзләр з, 50
Альвеола а, 14
Альвеоляр тартыклар а, 14
Альтернация а, 14
Амальгамалаучы телләр а, 15
Американизмнар а, 15
Аморф җөмлә а, 15
Аморф сүзләр а, 15
Аморф телләр а, 15
Амплитуда а, 15
Амплификация а, 15
Амредита а, 15
Амфиболия а, 15
Анаграмма а, 15
Анаколуф а, 15
Аналитик иярченле кушма җөмлә а, 16
Аналитиклык а, 15
Аналитик сүз а, 16
Аналитик телләр а, 16
Аналитик фигыльләр а, 16
Аналитик форма а, 16
Аналитик чаралар а, 16
Аналогик телләр а, 16
Аналогия а, 16
Анатолия телләре группасы а, 16
Анафора а, 16
Англицизм а, 16
Андроним а, 16
Антевокаль а, 17
Антитеза а, 17
Антоним а, 17
Антонимия а, 17
Антонимнар сүзлеге с, 158
Анторопонимнар а, 17
Антропологик лингвистика а, 17
Антропонимика а, 17
Антропоцентрик парадигма а, 17
Аныклаучы кисәкчәләр а, 113
Аныклаучы теркәгечләр п, 130
Аңкау н, 97
Аңкау алды тартыклары п, 121
Аңкау гармониясе н, 97
Аңкау уртасы авазлары с, 174
Аңлаешлы сөйләм ч, 205
Аңлатмалы родительный о, 107
Аңлатмалы сүзлек т, 185
Аорист а, 17
Апеллятив, уртаклык исем а, 17
Апикаль тартыклар а, 17
Аподозис а, 17
Апокойну а, 17
Апокопия а, 17
Апостроф а, 17
Аппликация а, 18
Аппозитив мөнәсәбәт а, 18
Арадаш ассимиляция н, 100
Арадашчы тел я, 219
Аралашуда сүздән гайре чаралар н, 97
Арго а, 18
Арготизмнар а, 18
Ареал а, 18
Ареаль лингвистика а, 18
Артикль а, 18

Артикуляцион база а, 18
Артикуляцион күнекмәләр а, 18
Артикуляцион фонетика а, 18
Артикуляция а, 19
Артикуляция базасы а, 18
Арткы рәт сузыклар г, 35
Артыклык дәрәҗәсе, суперлатив п, 131
Артык сүзләр л, 85
Архаизм а, 19
Архетип а, 19
Архисемема а, 19
Архифонема а, 19
Асемантик а, 19
Асемантик фонема ялгану в, 30
Асиндетон а, 19
Аспектлы сүзлекләр а, 19
Аспиратлар, аспират тартыклар а, 19
Ассимиляция а, 19
Ассонанс а, 19
Астронимика а, 20
Асылма дефис в, 26
Асыл сыйфат к, 64
Атау җөмлә н, 95
Атау функциясе н, 95
Атрибутив мөнәсәбәт а, 20
Атрибутив һәм предикатив а, 20
Аттракция а, 20
Аугмент а, 20
Аудирование а, 20
Афеза а, 20
Аффектив лексика а, 20
Аффикс а, 20
Аффиксаль дериватлар а, 20
Аффиксация а, 21
Аффикслар чылбыры ц, 201
Аффиксның продуктивлыгы п, 135
Аффиксоид а, 21
Аффилиация а, 21
Аффриката а, 21
Ахлаут а, 21
Ачкыч лексема, төп сүз к, 66
Ачык иҗек о, 116
Ачык структуралар о, 116

**Ә**

Әдәби әсәр с, 171
Әдәби булмаган лексика в, 27
Әдәби тел л, 84
Әдәбиятчы с, 158
Әйтелеш алдыннан киң итеп сулыш алынмаган тартыклар н, 100
Әйтелеш, әйтү п, 135
Әйтелми торган тартыклар н, 100
Әйтемнәр п, 125
Әлифба а, 12; а, 14

**Б**

Баба славян п, 130
Баба тел п, 130; я, 219
Балканизм б, 21
Балканистика б, 21
Балкан телләре берлеге (балкан телләре) 21
Балтика телләре б, 21
Балтика телләре берлеге б, 21
Балтистика б, 22
Банту телләре б, 22
Басым у, 188
Басым көчү законы з, 50
Басымның кульминатив функциясе к, 77
Басымсыз сузыкларның күләм үзенчәлекләре к, 68
Басымсыз сузыкларның сыйфат үзенчәлекләре к, 64
Баш җөмлә г, 34
Башкарылыш, башкарылу, башкару у, 190
Баш килеш и, 54; о, 115
Баш хәреф п, 136
Баш хәрефләр з, 50
Бәйләгеч морфемалар с, 168
Бәйләнеш с, 145
Бәйләүче чаралар с, 175
Бәйле басым с, 145
Бәйлек п, 129
Бәйлек сүз п, 129
Белдерү планы п, 124
Бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә м, 90
Бер видлы фигыльләр о, 108
Бергәлек, берлек, тулылык, таркатылмаучанлык ц, 201
Берекмә җөмлә с, 172

Бер иҗекле сүз о, 109
Беркетелгән басым ф, 192
Бер кисәкле иярченле кушма җөмлә о, 109
Берлек сан е, 48
Бермәгънәлелек о, 108
Берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмлә м, 90
Бер составлы җөмлә о, 109
Бер тамырлы сүзләр о, 108
Бер тапкырлы подвид о, 108
Бертеллелек о, 109
Бер телле сүзлек о, 109
Бер фокуслы о, 109
Бер яклы икетеллелек о, 109
Бизәк о, 110
Билге алмашлыклары (сыйфат алмашлыклар) п, 133
Билге килеше т, 182
Билгеләнүче о, 103
Билгеләү о, 103
Билгеләү алмашлыклары о, 113
Билгеләүче о, 103
Билгеле (категорик) киләчәк заман о, 112
Билгеле (категорик) үткән заман о, 113
Билгеле кисәк о, 113
Билгеле үтәүчеле җөмлә о, 113
Билге рәвешләре н, 96; о, 113
Билгесез киләчәк заман б, 23; н, 99
Билгесезлек алмашлыклары н, 99
Билгесез үтәүчеле җөмлә н, 99
Билгесез үткән заман п, 137
Билингв б, 22
Билингвизм б, 22; д, 41
Борынгы славян теле с, 175
Борынлашу н, 95
Борын тартыклар н, 101
Борын тартыклары н, 95
Бугаз тартыклары г, 37
Бүлем саннары р, 138
Бүленми торган җөмлә н, 101
Бүлүче җөмләләр р, 138
Бүлүче теркәгечләр р, 138

**В**

Вакытны белдергән төшем килеше т, 182
Вакыт рәвешләре н, 96
Вакыт хәле о, 105
Валентлык в, 24
Варваризм в, 24
Вариантлар в, 24
Велярлашу в, 26
Вербоидлар в, 26
Версия в, 26
Вибрантлар в, 26
Видлар конкуренциясе к, 71
Вокабула в, 27
Вокал в, 27
Вокализация в, 27
Вокализм в, 27
Вокатив в, 28
Вокатив җөмлә в, 28
Вульгаризм в, 30
Вульгар тел в, 31

**Г**

Гадәти тел е, 48
Гади җөмлә п, 136
Гади җөмлә модельләренең стилистик үзгәрешләре (формалары) с, 176
Гади заман п, 136
Гади сөйләм лексикасы п, 136
Газета-публицистика стиле г, 32
Гамәли тел белеме п, 133
Гамәли транскрипция п, 130
Гаплология г, 32
Гармония, ярашу г, 32
Генератив лингвистика г, 32
Генератив синтаксис г, 33
Генетик парадигма г, 33
Генитив г, 33
Генитив, иялек килеше г, 143
Географик лингвистика г, 33
Германизм г, 33
Германистика г, 33
Герман телләре г, 33
Герундий г, 33
Герц г, 33
Гидроним г, 33
Гидронимия г, 33
Гипер-гипонимик (гомум-төр) парадигма г, 33
Гипердиалектизм г, 33

Гипероним г, 34
Гиперсема г, 34
Гиперурбанизм г, 34
Гипоним г, 34
Гипонимия г, 34
Гипосема г, 34
Гипостазис г, 34
Гипотаксис г, 34
Глаголица г, 35
Глосса г, 36
Глоссарий г, 36
Глоссемантика г, 36
Глоттохронология г, 36
Гомумдәүләт теле о, 106
Гомуми инкяр җөмлә о, 106
Гомуми кулланылыштагы стильара лексика о, 106
Гомумиләштерүче сүзләр о, 102
Гомуми лингвистика о, 105
Гомуми риторика о, 105
Гомуми тел в, 29
Гомуми тел белеме о, 106
Гомуми үтәүчеле алмашлык о, 102
Гомуми үтәүчеле җөмлә о, 103
Гомуми фонетика о, 105
Гомумкайтымлы фигыльләр о, 106
Гомумлингвистик о, 106
Гомумпоэтик метафора о, 106
Гомумславян лексикасы о, 106
Гомумтөрки лексика о, 106
Гомумхалык лексикасы о, 106
Гомумхалык теле о, 107
Грамматика г, 37
Грамматик абстракция г, 37
Грамматик аналогия г, 37
Грамматик берәмлекләр г, 38
Грамматик категория г, 37
Грамматик категорияләрнең классификацион типлары к, 65
Грамматик категориянең функциональ-семантик кыры с, 146
Грамматик мәгънә г, 38
Грамматик омонимнар г, 38
Грамматик синонимнар г, 38
Грамматик стилистика г, 38
Грамматик чара г, 38
Грамматик элемент г, 38
Граммема г, 38
Графема г, 38
Графика г, 39
Графиканың позицион принцибы п, 126
Графика принциплары п, 133
График принцип г, 39
Группа, төркем г, 39

**Д**

Даими басым п, 129
Даль законы д, 40
Датив д, 40
Дәрәҗә с, 176
Дәүләт теле г, 37
Двандва д, 40
Деванагари д, 41
Дейксис д, 41
Дейктик алмашлык д, 41
Делабиализация д, 42
Делатив д, 42
Демаркация д, 42
Деминутив д, 42
Денотат, денотатив мәгънә д, 42
Денотация д, 42
Дентализация д, 42
Дериват д, 42
Дериватор д, 42
Деривацион мәгънә д, 42
Деривацион морфемалар д, 43
Деривация д, 43
Десемантизация д, 43
Десигнат д, 43
Дескриптив лингвистика д, 43
Детерминант д, 43
Детерминатив д, 43
Детерминация д, 43; п, 125
Дефис, сызыкча д, 44
Децибел д, 44
Дешифровка д, 44
Деэтимологизация д, 44
Диакритик тамга д, 44
Диалект д, 44
Диалекталь, диалектларга караган д, 44
Диалектизм д, 44
Диалектологик атлас д, 44

Диалектология д, 44
Диалог д, 45
Диалогизм д, 45
Диапазон д, 45
Диафора д, 45
Диахрония д, 45
Дивергентлар д, 45
Дивергенция д, 45
Диглоссия д, 45
Диереза д, 45
Динамика д, 45
Динамик басым д, 45
